
PRESSA.RU

1926–1991 ЕЛЛАРДА **АЗАТ ХАТЫН**



2017 **ИЮНЬ № 6**

сөембикә

ISSN 0869-1398

БЕЗ ӘЛЕ ЯШИБЕЗ

ана күңеле – сизгерләрдән-сизгер

ЯҢА УЕНЧЫК

алыргамы, юкмы

УЧАКТА ПЕШКӘН ЧАХОХБИЛИ

Булат Бәйрәмов белән Ләйсән Гыймаева сыйлый

Диләрә МУСИНА:

«ҮЗЕҢ ТАПКАН БӘХЕТ КАДЕРЛЕ!»





И-и ямьле туган ягым!



Әхәт ГАФФАР
Фото:
Вазыйх ФАТЫЙХОВ

Балык Бистәсенең Олы Әшнәк авылына инде 880 ел. Бабаларыбыз бу җирләргә күченеп, 1236 елда нигез салган. Монда Болгар шәһәрчеге булган. Зиратыбыздагы кабер ташы, чал кылганнар шаһит шуңа. Ерак та түгел, Бирге Ялпы, Аргы Ялпы таулары арасында – Атау Эче дигән киң болыныбыз. Шундый шигырь юлларым да бар: Атау Эченә кергәндә, мәңгелеккә кергән кебек / Бала чакны гына түгел, бар җиһанны күргән кебек... Аргы Ялпы, Бирге Ялпы болынның тәхете кебек... Болын түрендә, аның йөзек кашы булып, Кәрәкә күле җәйрәп ята. Ул яшел хәтфәдә яткан көмеш тәңкәне хәтерләтә. Камышлар арасында, утлы шар яисә тәгәрмәчкә әйләнеп, куркыныч зур еланнар яшәгән, имеш... Күл буенда йокларга кушмыйлар: тән авырая, тора алмавың ихтимал. Бала чагымда, черем итеп алганнан соң авырып саташканда, зиһен иңләмәстәй биек киңлектән Җир шарын күрсәткәннәр иде. Бу тирәләр аномаль көчкә ия. Кече Әшнәк белән Олы Әшнәк арасында төннәрен адаштыра. Чөнки түбәндә – калын торф катламы, астарак – нефть ятмасы. Күрәсең, күкерт, метан газы аңны шулай томалыйдыр...

Равил ФӘЙЗУЛЛИН

Йолдызлы күк-гөмбәз астында

Чистайларның уты күренә, диләр,
Аюкүл түбәләреннән карасаң...
(Җырдан)

Алатай чишмәсе, Тәпәнлек үзәне...
Таубашы мәйданы, Әчебаш урманы...

Нибары –
бер меңләп кешегә газиз бу исемнәр.

Энҗеле-йолдызлы күк-гөмбәз астында
Җир кебек борыннан яши бит алар да!
Үзәннәр,
инешләр,
аланнар...

Авылдашлар өчен алар –
үзләре дә ишетмәгән –
Килиманджаро,
Кояшлы сукмаклар,
Ниагаралар.

Бу бәләкәй бөек кешеләрнең
күккә сыймас шатлыкларын,
дөнья кадәр хәсрәтләрен
үзләрендә саклый алар
буыннан буынга,
дәвердән дәвергә.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2017

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты.
1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде.
Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән.
Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Фото: Ксения Богданова

Җитәкче-баш мөхәррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны	222-09-77
Җитәкче урынбасары	
Рәмзия Кашапова	222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары	
Гөлнур Хәсәншина	222-09-78
Җаваплы сәркатип	
Лариса Маликова	

Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Диләрә Мусина
Фото: Ксения Богданова

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225х290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 6.06.2017 ел.
Заказ А-1368.
Тираж 5740.

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.


Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002



PRESSA.RU





Ләйсән КӘШФИ

Җәй кадере

Быел җәйләр шундый яшел, әйеме,
Үләннәре сусыл, ширбәтле.
Июнь юмарт булды, күпме яңгыр
Яфракларны сөйде, тирбәтте.

Печәннәре калын, җиләк эре –
Гүя балачакның җәйләре.
Гомер узган саен вакыт газиз,
Кыйммәт икәнлеген шәйләдем.

Ничек кадерләргә бу җәйләрне,
Бар ширбәтен эчеп калырга?
Әллә кырлар буйлап йөгерергә,
Әллә карурманнар ярырга?

Егылырлык булып арырга да,
И эчәргә урман чишмәсен!
Мондый ләззәт, мондый хозурлыктан
Яшәрмичә йөрәк нишләсен?

Без бит гади авыл балалары,
Авыл киңлегенә сусаган.
Тар шәһәрдә яшәп шәрә күңел
Шундый бөлгән, шундый сусаган.

Җәй кадерен белми асфальт урам,
Таба кебек кыза таш кала.
Бу тәмугта башка чыдый алмам,
Авыл җәе, безне ташлама!



Фото: Газинур Хафизов

Роберт ӘХМӘТҖАНОВ

Яшел тупылга мәдхия

А, йөзьяшәр тупыл, миллион яфрак –
җиләс йортым, яшел июнем!
Кояр идем сине туграм итеп, –
Шулдыр сиңа кайнар сөюем!
Яшел генератор!
Җирдән бәргән
моң фонтаны, яшел моң шавы!
Кемгә тиңлим сине?
Шау яшьлекнең
мөмкин бары сиңа охшавы!..

Яфракларың, шаулы туйда кайнап,
алкышлыйлар сыман галәмне.
Туфрагыма буең аша уза
йолдызларның ерак сәламе!..

Баш очыңа килеп куера да
тынып тора гашыйк яшь болыт...
Яшел кочагыңа сыенып, Җирдә
калыр идем мәңге яшь булып!

А, яшел җил... яшел яктылык!



PRESSA.RU



БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА







12
«БЕЗНЕҢ ӘНИ МЕҢ АЛТЫН!»
А. Юнысова

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ





8
КЫЗЧЫГЫМ
М. Авзалова



22
«ЧӘЙ ЭЧӘРГӘ ФИЛ КИЛСЕН»
Л. Әбүдәрова



18
«ТУМЫШЫМ БЕЛӘН... БАЛАЧАКТАН»
М. Авзалова

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ





26
ХӘЗРӘТ БЕЛӘН АБЫСТАЙ
Г. Сафиуллина

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 

40


РОЛЬЛӘР ҺӘМ ТРОЛЛЬЛӘР
С. Гаффарова

ЯШӘЕШ 



44
ЗӘҢГӘР ҖӘЙЛӘР ЕРАК ДИСӘҢ ДӘ...
К. Булатова

52


ЯНГЫНЛЫ БИЛБАУ ИЛЕНДӘ
А. Камал

ШУЛАЙ УК: 

34
КУНАК МАЛАЙ
(хикәя)
Л. Әбүдәрова

46
ВАКЫТ БИЗМӘНЕ
А. Юнысова

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 

58


УЧАКТА ПЕШКӘН ЧАХОХБИЛИ

КИЛӘСЕ САННАРЫБЫЗДА: 

БЕР ГАИЛӘГӘ 17 БАЛА: АЗМЫ КҮПМЕ? КАЙСЫГЫЗНЫҢ КУЛЫ ҖЫЛЫ

ҖИРӘНЧӘЧ. ВЕНЕРА МӘҖИТОВА. ХИКӘЯ.

КӨНДЕЗ – СЫЕР САВУЧЫ, КИЧ – ТОРТ ПЕШЕРҮЧЕ. ЗАМАНДАШ.

ЧУАР ТАШЛАР – ДИҢГЕЗ ХАТИРӘСЕ. МАСТЕР-КЛАСС.



PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Җиңү бәйрәме шатлыклы бәйрәм. Әмма ул сугыш вакытында күргәннәрне искә төшереп, сагышка күмә.

Чутай авылында (Балтач районы) туып-үсеп, Сасна авылында гомер иткән мәрхүмә Флера Рәхмәтуллинаның сугыш вакытында күргән михнәтләрен эт тә күрмәгәндер. Әтисе сугышка чыгып киткәндә аңа 5-6 яшь була. Сәкедән дә тора алмаган хаста әнисе белән алар кечкенә бер иске мунчада яшәп калалар. Ягарга утын юк, ашарга ризык юк, киярге кием юк... Кышны хәер сорашып, күршеләр булышлыгы белән көч-хәл чыгалар. Яз җитүен бик зарыгып көтә алар. Ашамаган бер генә үлән дә калмый. Хәтта бәрәңге сабаклары да ярап куя. Аны пешереп, Флера башта үзе чәйни, аннары әнисенә каптыра, чөнки әнисе хәтта үзе чәйни дә алмый торган хаста була. Шулай ашатып, әнисен 20 ел тәрбияли ул. Тилмереп яшәүләре генә җитмәгән, көннәрдән бер көнне яши торган мунчалары да янып китә. Флера үзе дә бик нык пешеп, бөтен тәне гомерлек җөйләр белән капланып кала.

Яшәүләре ничек кенә авыр булса да, Флера бирешми. Көн дә 10 чакрымдагы күрше авылга йөреп, урта мәктәпне тәмамлый. Мәктәптән соң педагогика институтында укып, Сасна авылына укытучы булып кайта. Гомере буе шунда завуч булып эшләп, пенсиягә чыга.

Аның баштан кичкәннәре буенча «Адәм баласы ниләр күрми» дигән роман язарга булыр иде. Үзе күргәннәрне сөйли башласа, күзгә яшь тула, тыныч кына тыңлап та булмый торган иде. Шундый тормышта: ачлык-ялангачлык, ятимлек белән үсеп тә, югары белем алып, үз теләгенә ирешүен мин бик зур батырлык дип бәялим.

Бер ялгызы яшәде ул. Янгыннан соң тәнендә калган җөйләрдән кыенсынып, кияүгә дә чыкмады.

Бөтен халык Бөек Җиңүне бәйрәм иткәндә кечкенә генә кызның күргән михнәтләре күз алдыма килә. Ничек түзгән ул – башыма сыймый. Мондый авырлыкларны башкаларга күрергә язмасын иде.

Лимуза ГАРИПОВА.
Тукай районы, Нефтебаза бистәсе.



Татарстанның атказанган артисты Флера Хөрмәтова диюгә, күз алдыма ап-ак хромка гармунын кочаклап, зәвык белән киенгән, чибәр һәм мөлаем, кайчан карасаң да гел яшь (тьфү-тьфү, күз тимәсен) ханым килеп баса.

Әгерҗе районының Мукшур авылында җиде балалы гаиләдә төпчек кыз булып дөньяга килгән, сугышка киткән әтисенең буйсынын күрмәгән, белмәгән, әти дип әйтер кешесе булмаган Флера ханым үзенең ничек гармунчы булып киткәнен хәтерендә яңартканда, дүрт абыемның икесе гармунда бик яхшы уйный иде, дип искә ала. Башта Лениногорск шәһәрендәге музыка училищесын, аннан Казан дәүләт мәдәният институтында дирижерлык буенча белем алган кыз Чаллы шәһәренә килеп чыгуын болай аңлата: «Училищены бетергәч, Казанда халык иҗаты йорты каршындагы тугыз айлык курсларда баян буенча укыттым, югары белем алып йөргәндә дә бу эшемне өч ел дәвам иттем әле. Институтны тәмамлагач, юллама буенча Чаллы шәһәренә җибәрделәр. 1974 елны укуны тәмамлап кайткач, 35 ел хезмәт гомеремне халык уен кораллары оркестрында үткәрдем».

Флера Хөрмәтованың бию көйләреннән торган 5 альбомы бар. Без барыбыз да ул көйләргә бик рәхәтләнеп биибез. Бүгенге көндә нәрсә белән мәшгуль, нинди планнар белән яши икән ул үзе? «Иҗат кешесе һәрвакыт нәрсә дә булса эшләргә омтыла. Хыялым – онытылмас җәүһәрләребез – халык көйләрен туплап, бер альбом итеп чыгару», – ди Флера ханым. Ә теге ак хромка гармун хакында сүз чыгып, тузмадымы әле, һәм, гомумән, күңелегезгә нинди уен коралы якын, дигән соравыма: «Күбесенчә хромкада уйныйм, ул инде күптәнге, моннан бик күп еллар элек гармун остасы Салих Шәйдуллиннан алган идем мин аны. Иң беренче ясаган хезмәт җимеше иде ул, бик матур булуы белән күңелемне җәлеп итте. Гомумән, гармун халык җанына якынрактыр, синтезатор дигәннәре халык көйләрен бераз бозды дисәм дә, арттыру булмас. Үземә килгәндә, үлгәнче гармунга хыянәт итмәячәкмен, чөнки балачактан абыйлардан качапоса гармун уйнап үстем, аның телләре, көйләре кечкенәдән каныма сеңгән. Чаллыга кайткач, күп гармунчылар белән эшләргә туры килде. Шуларның берсе – Хәниф Әхмәдуллин иде. Кызганычка, го-

мере иртә өзелде аның. Таһир Якупов, Зифа Басыйрова, Флера Сөләйманова кебек мәшһүр җырчыларны уйнап җырлатканым булды», – дип җавап бирде гармунчы ханым.

Хатын-кыз гармунчылар сирәк. Кайберәүләрдән, гармун уйнау ир-ат эше, дигән сүзне дә ишетергә туры килә. Әгәр дә гармунчы булып китмәгән булса, Флера Хөрмәтова кем булыр иде икән? «Әлбәттә, ир-ат эше, – дип, ул үзе дә минем фикерне куәтли. – Чөнки бу уен коралы авыр, күтәреп йөрергә, уйнарга көч кирәк. Абыйларымнан күрмәгән, аларга кызыкмаган булсам, мин спорт буенча киткән булыр идем, чөнки спортны бик яратам».

Флера ханымның әлегәчә зифа сакланган буй-сынының сере менә нидә икән бит!

«Син минем фикерләрне укыйсың кебек, – дип көлә ул үзе дә. – Иртәм физик күнегүләр ясау белән башлана. Сәхнә кешесе формада булырга тиеш дигән шигарь белән яшәдем. Ә тегә, гармунчы булу ни өчен ир-ат эше, дигәнгә әйләнеп кайтсак, аларга күпкә җиңел, чөнки алар физик яктан хатын-кызга караганда көчле. Элек мин дә сәхнәдә гел басып уйный идем, хәзер исә утырып уйныйм... Әгәр кешенең теләге көчле икән, ул бернигә дә карамыйча гармунчы булачак. Әмма теләүчеләр бик аз. Сәбәбе – баян белән чагыштырганда, гармунның мөмкинлекләре чиклерәк булуда, күрәсең. Шуңадыр, гармунга игътибар бик бирмиләр, гармун белән җырлаучылар юк дәрәҗәсендә. Моңлана белүчеләр генә бу уен коралына җаны-тәне белән тартыла дияр идем».

Тормышын гармуннан башка күз алдына китерә алмаган танылган артистка табигатькә мөкиббән – урманда йөрергә ярата. «Җиләк, гөмбә кирәк булганга түгел, ә рәхәтлек эзләп, күңелем кушканга барам. Үзем гөмбә дә ашамыйм, ә җыярга яратам. Кешеләргә бирер өчен җыям мин аны», – ди ул бу мавыгуы турында.

Берничә ел элек Казанга күченеп яшәү турында хыялланганын беләм. Аның бу уе чынга ашмады, ахрысы. «Әйе, – дип көрсенә Флера ханым. – Тормышка ашмаган нинди хыялың калды, дип сорасалар, Казанга күчү, дияр идем. Иҗат кешесе өчен Казанның казанында кайнап яшәү мәслихәт. Чаллыда татарча көйләр яздыру студияләре дә юк диярлек. Бу хыялым уйналмыйча калган көемә бәрабәр...»

Илзирә ВӘЛИУЛЛИНА-ШАҺИЕВА.
Казан.



Әни сүзен әйтә алган, әниле үскән кеше дөньяның иң бәхетлесе. Әни булганда көннәр якты, төннәр йолдызлы. Авыр чакларыбызда да, шатлыклы минутларыбызда да әниләребезнең җылы кочагына сыенабыз. Әниләрнең йөрәк җылысы, «Балам!» дип эндәшкән ягымлы сүзләре яшәргә көч бирә. Әнә шундый тылсымлы, бөек көчкә ия ул ана дигән изге зат.

Балык Бистәсе районы Олы Солтан авылында туып-үскән җырчыбыз Илназ Минвәлиевнең әнисе Разия апага «әни» сүзен әйтү бәхете насыйп булмый. Разия апа әле күкрәк баласы чагында ук аның әнисе авырып дөнья куя. Әтисе кулына калган ике нәни кызга авырлыкны күп күрергә туры килә...

Разия Зыятдин кызы 1952 елның 14 маенда башкалабыз Казанда аваз сала. Сугыштан соң илебезнең таушалган, яшәп китәргә күп көч кирәк чагы. Әтнә ягына күчеп киткән әтиләре Зыятдин абый кызларына яхшы тәрбия бирә. Яши-яши, язмыш җилләре үги әниле итә кызларны. Барысы бергәләшеп дөнья йөген тарту кызлар җилкәсенә дә төшә. Матурлыгы, җыр-моңга осталыгы белән бар авылны таң калдырган Разия апа бик тырыш кыз булып үсә. Бер эштән дә калмый, фермада да эшли, читтән торып белем дә ала.

19 яшендә Рәшит исемле егет белән таныша, гаилә корып яши башлыйлар. Мәхәббәтләренең көче 46 ел буена аз гына да кимеми. Тупырдап торган дүрт бала алып кайта Разия апа. Өч ул, кечеләре – кыз. Тормышларының түгәрәк булуларына куанышып гомер кичерәләр. Балаларының һәрберсе игелекле, тәрбияле. Аларны тәрбияләп кеше итү – әти-әнинең төп бурычы. Разия апа балаларына әни мәхәббәтен, күңел җылысын кызганмый бирә. Эш арасында тәмле-тәмле ризыклары белән сыйлый, җылы оекбашлар бәйли, догалары белән аларга иман нуры сеңдерә. Уллары Илһам, Ренат, Илназ, кызлары – Гөлназ иманлы, ярдәмчел, тырыш булып үсәләр. Балачак – шук чак, диләр. Балаларының төрле чаклары булгандыр, Разия апаның сабырлыгын, уңганлыгын Рәшит абый көннән-көн ныграк бәяли.

Разия апа белән сөйләшеп утыру үзе бер гомер, тавышы искиткеч матур, моңлы. «Илназ улыгыз каян шундый моңлы?» – дигәнемә: «Үзем моңлы идем, миңа охшап, барысы да җыр-моңга осталар, – диде. – Бүгенге көнебезнең зур байлыгы – тугыз оныгыбыз, Илназыбызның булуы, халкыбызга файдасы тиюе», – дип сөйләвендә зур мәгънә ята. Балаларын аерып мактарга яратмый Разия апа. «Иң мөһиме: барыбызның да исәнлеге», – ди.

Искиткеч гадилек, кайгыртучанлык ята Разия апаның күңелендә. Шушы 65 яшьлек юбилеенда аңа сәламәтлек, бәхетле киләчәк, Рәшит абый янәшәсендә балаларының, кияү-киленнәренең, онык-туганнарының яхшы хәбәрләренә сөенеп яшәргә язсын. Улың Илназ Минвәлиев оештырган юбилей кичәң котлы булсын, Разия апа!

Альбина ШАЙГАРДАНОВА.
Чаллы шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU



КЫЗЧЫГЫМ



Мәдинә АВЗАЛОВА

МИНЕМ ӨЧЕН ИҢ АВЫРЫ – КИЛЕШҮ. ДҮРТ ПАПКАГА ҖЫЕЛГАН НӘТИҖӘЛӘР, ТАБИБЛАР КУЙГАН КУРКЫНЫЧ ДИАГНОЗ БЕЛӘН КИЛЕШҮ.

Барысы да әйбәт башланган иде. Ике еллап очрашып йөргәннән соң, егет белән кызга гөрләтеп никах туе ясадылар. Туган-тумачалар, дус-ишләр, танышлар җыелды. Карап туйгысыз яшь парга бәхет, тигез тормыш теләделәр. «Күп итеп балалар алып кайтыгыз, кайгыда да, шатлыкта да бергә булыгыз!» – диештеләр. Кыскасы, туйда нинди сүзләр әйтелергә тиеш, шуларның барысы да әйтелде шикелле.

Әйе, барысы да әйбәт башланган иде. Озак көттермичә дөньяга килгән нәни кызчыкка исем куштылар. Самира өч айга кадәр тын гына йоклады да, йоклады. Ә көннәрдән бер көнне баланы көзән җыера башлады. Айсу, нәниен кочаклап, 8 нче неврология хастаханәсенә чапты. Невропатолог кызчыкны җентекләп карады, анализлар да алынды. Һәм менә диагноз... өметсез, рәхимсез, куркыныч диагноз: «Балагызда Веста синдромы, – диде табиб. – Яшәсә, өч ел яшәр...»

Өенә ничек кайтып җиткәнен ул хәтерләми. Ә менә бу хәбәрне иренә әйткәч, ни ишеткәнен әле дә исеннән чыгара алмый: «Синең гарип балаң миңа кирәкми. Үзең кара...» Шулай итеп, яшь хатын үлемгә хөкем ителгән чирле баласы белән берьялгызы утырып кала...

Ата күке китә һәм баласы, хатыны барлыгын мәңгегә оныта. Ул, никахлары рәсми теркәлмәгәч, сабыена алимент та түләми, хәл-әхвәлен дә белешми. Тормышыннан сызып ташлый.

Ярый да шул чагында үзе дә әле бала гына булган Айсу янында аның яраткан әнисе-әтисе, абыйсы Адель була. Әнисе Рузалия ханым кызын: «Борчылма, бергә булырбыз», – дип юатса да, диагнозның нидән гыйбарәт булуын белгәч, түзми, кычкырып елап җибәрә. Ләкин бу әле сынауларның башы гына. Бала бер яшенә җиткәнче, бөтен белгечләрне йөреп чыгалар. Балалар республика клиник хастаханәсендә кызчыкның күзләрен карыйлар да, диагноз куя алмагач, Мәскәүгә –

Гельмгольц хастаханәсенә барырга киңәш итәләр. Айсу, бәләкәчен алып, әтисе белән Мәскәүгә юл ала. «Күзләрендә яман шеш, операция ясамыйча булмый», – ди табиблар. Балага ике күзсез калу куркынычы яный. Юк, юк, Айсу кызын якты дөньяны күрү бәхетеннән мәхрүм итә алмый. Ул әле башка табиблар белән киңәшләшер. Сабыен күкрәгенә кысып, хастаханәдән чыгып качканда, нинди адымга баруын, баласының язмышы бары аның кулында булуын яхшы аңлый ул.

Язманы нәни кызчыкның кыл өстендә эленеп торган гомерен үлемнән саклап кала алу өчен барын да эшләгән, чарасызлыктан сынып төшмәгән, авырлыкта югалып калмаган яшь әнинең инстаграмга куелган кичерешләрен, уй-фикерләрен күзаллап дәвам итәргә булдык. Физик мөмкинлеге чикле бала тәрбияләгән әниләргә, бигрәк тә әтиләргә гыйбрәт, сабак булсын дип, шулай эшләдек.



Куркыныч диагноз белән килешеп яшәү – тәмуг уты. Баламның соңгы сәгате, соңгы минутлары турында уйлый башласаммы... Уйламыйм гына. Ниһаять, ниһаять, мине акылдан язар дәрәҗәгә җиткергән диагнозларның берсен табиблар кире какты. «Яман шеш авыруы юк» (рака нет) – минем шигарем иде. Табибларның: «Икесендә дә күзендә яман шеш, күзләрен алырга кирәк», – дигәнен ишеткәч, табиблар белән ачуланыштым. «Алар әйткәнне тыңла», – дип торган әти белән кычкырыштым. Беркемне тыңламадым. Юк, дидем, баланы күзсез калдырмыйм. Мин һаман эзләнүдә. Инде кемгә мөрәҗәгать итәргә, кая барырга? Уйладым-уйладым да Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгына киттем. Анда миңа Күзләр микрохирургиясенә юллама бирделәр. Һәм менә без... янә Мәскәүдә. Элгәре куелган диагноз белән дүрт ел көрәшкәннән соң, бетмәс-төкәнмәс караңгылык артында яктылык сирпелә башлады. Биредә безнең белән күренекле табиблар Татьяна Ушакова һәм Андрей Яровой шөгыльләнде. Аларга эләгү үзе бер бәхет бит. Диагнозны дөрес куелмаган дип таптылар. «Башта баланың тормышын саклап калабыз, аннары – күзләрен», – диделәр. Бу юлы мин алар белән килештем. Хәлемә керүчеләрнең барысына да зур рәхмәт.# Мин сезнең барыгызны да яратам!

Казан белән Мәскәү арасы хәзер Айсу Мингалиевага ике авыл арасы кебек кенә. Ул әледән-әле Самираны табибларга күрсәтеп кайта да, биредә – Республика онкология хастаханәсендә дәвалый. Ни дисәң дә, акча ягын да уйларга кирәк. Ә бездә ул бушлай. Алар дүрт химиотерапия курсы, күзгә биш мәртәбә лазер терапиясе алырга өлгергәннәр инде. Һәм барысы да юкка. Химиотерапия ысулы белән дәвалану файда бирми. Баланың имммунитетын гына зәгыйфьләндерә.



Кызым, сиңа рәхмәт! Син чирләреңнән исән калырга, ничек тә яшәргә тырышкан көчле һәм мәрхәмәтле кешем минем! Мин яратам сине, кызкаем!

...Бер табибтан икенчесенә йөрүләребез дәвам итә. Әле күптән түгел генә Балалар республика клиник хастаханәсендә МРТ үттек. Бала ике сәгать ярым наркоз астында ятты. Баш миен, ике күз чокырын, муен тирәсен карадылар. Бөтенесе 19.900 сумга төште. Түләүлегә бардык. Югыйсә чират җиткәнне яртышар ел көтәргә кирәк. Ә безнең моңа вакыт юк. Аның каравы, нәтиҗәне шул ук көнне кулга тоттырдылар. Наркоздан чыгу балага елдан-ел кыенлаша.

Табиблар Веста синдромы (эпилептик синдром – сирәк очрый торган, дәвалауга бирешми торган чир) белән 4 яшен тутырган Самирага гаҗәпләнә. Тагын әнисе баланы алып Мәскәүгә юнәлә. Баксаң, сабыйда бернинди дә Веста синдромы түгел, анда генетик авыру икән. Мәскәү табиблары аңа «туберозный склероз» дигән диагноз куеп җибәрә. Һәм ни өчен әни кешенең моңа кадәр балага инвалидлыкны рәсмиләштермәве белән кызыксына. Чыннан да, ни өчен? Инде хәзер Айсуга тагын бер бюрократик баскычны үтәргә, дистәләгән ишекләрне ачарга кирәк...

«Бирешмәскә, көрәшергә!» Яшәү шигаребез шундый хәзер.



Шулай итеп, без гематология бүлегендә тикшеренү узабыз. Кан тапшырдык, ЭКГ үттек, эчке органнарга УЗИ ясадылар. Иртәгә менә рентген, аннары тагын анализлар. Уникаль очрак дип, кызымны медицина институты студентларына, поликлиника табибларына күрсәтмәкчеләр. Янәсе нәрсәгә игътибар итәргә, мондый балалар белән ничек эшләргә? Ничек, ничек, иң мөһиме: безне җәмгыять кабул итсен. Баламнан йогышлы чирдән качкандай качмасыннар. Башка, сәламәт балалар белән аралашырлык мөмкинлекләр, шартлар тудырсыннар! Менә ничек! Кәеф, кем әйтмешли, «боевой», үземдә көннән-көн ышаныч арта баруын сизәм. Ә бу бер дә аз түгел.

Быел табибларның кызымның чиренә игътибары кискен көчәеп китте. Безне (кызым белән мине) дүрт комиссиягә чакырдылар. Аңлыйм мин аларны. Алар юраганча, 3 яшькә чаклы гына яшәргә тиешле кызчыгым бишенче яше белән бара бит. Ләкин бу баруда мин бернинди дә яңалык ишетмәдем. Анысына да риза. Тик начары гына булмасын. Без алга таба да эпилепсия өянәге белән көрәшәчәкбез. Логопедка йөрербез... һәм иң мөһиме: шул чирләр бәйләме белән матур итеп яшәргә өйрәнербез. Әле менә Мәскәүдә бер бик шәп табиб барлыгын, аңа эләгү өчен бер ел алдан язылып куярга кирәклеген һәм аңа бер күренү хәтта ки 15.000 сум торганын белдем. Әмма бусын киләсе елга калдырмый булмый. Быел йөреп арыдык инде...

Кызым мине көннән-көн үзенең холкы, теләгенә ирешә белүе белән хәйран калдыра. Ата-аналарга теләгем: балаларыгызга ышаныгыз. Самира белән бергә мин дә үсәм, сабыр булырга, үземне тулаем аңа багышларга өйрәнәм. Балалар бездән бары яхшысын гына алсын иде#Самира#Барыгызны да яратам!

Фото Мингалиевларның шәхси архивыннан алынды

PRESSA.RU

Веста синдромы диагнозын «туберозный склероз» диагнозына үзгәрткән Мәскәү табиблары: «Генетиклар ни караган?» – дип гаҗәпкә кала. Ә Казанда генетиклар бармак белән генә санарлык. Самираның анализ нәтиҗәләре белән шыплап тутырылган папкасын табиб өстәл тартмасына салып куя да оныта. Ачып та карамый. Ә инде бу хакта кызыксына башлагач, анализларның инде искерүе, яңасын әзерләргә кирәклеге турында әйтә. Ә анализ тапшыру, гафу итәсез, 32 мең сум тора...

Әкрен генә узган көннәр белән бергә Самираның үсеш буенча, яшьтәшләреннән артта калуы да нык сизелә башлый. Үзе кебек бала-чага белән аралашу аңа авырдан бирелә. Шул сәбәпле, баланы гадәти балалар бакчасына алудан баш тарталар. Хәер, баланың үзенә дә логопеды, психологы булган бакча кирәк.

«Бөтен теләгәнем – җәмгыять мөмкинлекләре чикле балаларны үз итсен, кире какмасын иде».



Соңгы вакытта миңа гел бер сорау бирәләр: «Балаң кайсы балалар бакчасына йөри. Мин 155 нче коррекцион бакчага дигәч, тагын сорау: «Нәрсә, нормальныена барырга ярамадымы?» Күрәсең, башларыбызда һаман да әле СССР заманнарыннан килгән «нормальный» сүзе бөтерелә. Әлеге бакча интеллекты ягыннан артта калган балаларны тернәкләндерү һәм тормышка яраклаштыруга көйләнгән. Күпләребезне менә шушы соңгы фраза – интеллекты ягыннан артта калган, ягъни мәсәлән, аң-үсешенә зыян килгән дигән сүз куркыта, андый балалардан читләшергә этәрә дә инде. Дөрес тәрбия биргәндә, укуларын тиешле оештырганда сезнең һәм сезнең балалар өчен алар һич тә куркыныч түгел, әти-әниләр. Алар йогышлы түгел, алар – зарарсыз һәм юаш бер зат. Самирага сезнең балагыз зур ярдәм күрсәтә алыр иде. Гадирәк булыгыз инде, зинһар.

...Медкомиссия үтәргә җыенабыз: колак һәм тамак авырулары табибында, логопедта, психологта, невропатологта, офтальмологта, терапевтта, хирургта, ортопедта булдык. Кыскасы, күренмәгән белгечебез калмады. Анализлар тапшырылды, кирәкле бөтен документлар да җыелды. Комиссия бюросының карарын көтәсе генә калды. Ни дияргә? Мондый юлны без ел саен узабыз. Тернәкләндерү үзәгенә, санаторийга бушлай юллама бирмәсләрме дип тә өметләнәбез. Өч ел инде безгә аның берсе дә тәтеми.#Дөньяны яратам

Санаторийга юллама мәсьәләсендә Казан шәһәре Совет районының иминлек фондына шалтыратып, инвалид балаларга санаторийга юллама алу өчен ниләр кирәклеге белән кызыксынабыз. «Әллә ни кирәкми, – ди «кайнар линия»дә утыручы хезмәткәр. – Гариза, медицина белешмәсе, баланың туу турындагы таныклыгы, баланың әтисенең йә әнисенең паспорты». «Күпме көтәргә?» дигән соравыбызга ул: «Дөресен әйтергәме? Өч ел...» – ди дә трубканы ташлый. Өч ел?! Авыру бала ич ул. Үлеп китәргә дә мөмкин. Тик иминлек сагында торучылар мине ишетми. Казандагы «Апрель» тернәкләндерү үзәгенә шалтыратабыз. «Чиратны без билгеләмибез, социаль яклау бүлеге хезмәткәрләре белән сөйләшегез», – диләр алар. Ә Совет районының социаль яклау бүлегендә: «Бу эшләр белән шөгыльләнүче белгечебез эштән китте. Гариза калдырып китегез, карарбыз», – дигән җавап ишеттек. Әниләрнең еллар буе чирле баласын үзәккә китерә алмый тилмерүе сәбәбе аңлашыла болай булгач.



Медик-педагогик комиссия көне – 5 апрель дә килеп җитте. Уемда ничек тә кызыма ортопедик аяк киеме (аякларын чалшайтып йөри) алу... Вазгыятькә гел уңай гына карарга тырышам. Гел шулай барып чыкмаса да, тырышам... Ур-ра, табибтан табибка ике атна җәфаланып йөрүләребез юкка китмәде. Кызыма инвалидлыкны 18 яшькәчә озайттылар. Шатлануларымны күрсәгез. Бер хастаханәдән икенчесенә чабулар, очсыз-кырыйсыз чиратларда басып торулар бетте болай булгач. Димәк, димәк, безнең кулыбызда инвалид булуыбыз турында белешмә. Хәзер инде элеккечә пенсия фондына да барырга кирәкми. Пенсия автомат рәвештә күчәчәк. Ортопедик аяк киемен ала алмадык менә... Аны хәзер церебраль параличлы балаларга гына бирәләр икән. Кызганыч, югыйсә без дә аңа бик мохтаҗ идек.

Кызчыгыма 6 яшь тулды. Гомеренең шушы бәләкәй генә өлешендә ул кемдер гомер буе күрмәгәнне күрде. Исегездә тотыгыз: авырлыктан чыгу юлы, бик теләгәндә, һәрвакыт табыла, бар ул!#мәхәббәт телим!

«Балачактан инвалид» дигән сүз бүген инде гадәтигә әйләнеп бара. Без моңа күнектек, ахрысы. Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгыннан алынган мәгълүматларга караганда, илдә ел саен 50 меңләп инвалид бала туа. Бер бездә генә түгел, башка илләрдә дә шулай. Җир шарында инвалидларның саны барлык халыкның 5 процентын тәшкил итә. Һәм бу сан үзгәрми диярлек. Димәк, 5 процент хатынкызның, милләтенә, диненә, матди һәм социаль хәленә карамый, «үзенчәлекле, үзенә бертөрле» бала тудыру ихтималы бар дигәнне аңлата. Кайбер ата-ана андый бәхетсезләрдән баш тарта. Бала мондый очракта үзенең бетмәс-төкәнмәс проблемалары белән япа-ялгыз кала. Бу яктан Самира бик бәхетле. Аның өзелеп яратучы әнисе, дәү әнисе, дәү әтисе, абыйсы бар. Аннан күп тә соралмый, әнисе Айсу әйткәнчә, сөйләшергә өйрәнсә, үз-үзен карар хәлгә килсә... шунысы да бик җиткән. Инвалид баланы гомерлек бәйлелеккә куйган мондый чирләр каян килеп чыга соң? Әлбәттә инде, экология, генетика гаепле, дибез. Һәм әлбәттә инде, алкоголизм, наркомания, даруларны белмичә, кирәгеннән артык куллану... Бусы да бер бәла.



Бүгенге рекламалар кешенең баш миен теләсә кайсы якка борып куярга сәләтле. Әйе, әйе, аптека бүген кибет шикелле. Анда ни генә юк: конфеттан башлап, памперс һәм косметикага чаклы. Нигә болай дисезме?

Минемчә, бу өлкә инде күптән сәламәтлек саклау системасыннан читләшеп, коммерцияле проектка әверелде. Аптекага кергәнче башта уйларга кирәк. Үзеңне үзең дәваламаска, фармацевт киңәшен тыңлап, теләсә нинди дару капмаска өйрәнергә кирәк безгә! Ата-ананың игътибарын тагын бер җитди проблемага юнәтәсе килә: июль аеннан бирле табиб билгеләгән даруның нәтиҗәләре белән көрәшәм. Эпилептолог аны безгә көзән җыерганнан дип биргән иде. Бу «дару»ны эчкәннән соң, баланың үз-үзен тотышында үзгәрешләр башланды. Тәнендәге җәрәхәтләр төзәлмичә интектерде. Баланың гел йоклыйсы килде. Чираттагы биохимияне тапшырганан соң, тромбоцитларның нормадан өч мәртәбә түбән булуы ачыкланды. Табибка әләгү үзе бер проблема булгач (ике атнадан соң гына күренә алдык), дару бирүне туктаттым. Бер атнадан кызымның учлап-учлап чәче коела башлады. Йөзе ап-ак... Тизрәк гематологка йөгердек. Нәтиҗәдә, без янә хастаханә һәм очсыз-кырыйсыз тикшеренүләр боҗрасында калдык. XXI гасырда яшибез ләбаса. Бала өстеннән эксперимент үткәрмәсәгез... Болай ук димәс идем, табибларның авыруларга препарат билгеләү тәртибе бик сәер. «Эчеп карасын әле, ярамаса, карарбыз», – ди алар. Хастаханәгә ятар өчен неврологка баргач, бала эчкән даруның исемен ишетүгә аның ахылдавын күрсәгез. «Сез нәрсә? Без бит аны хуш, якты дөнья, дип атыйбыз», – ди. Димәк, бу препаратның тәэсирен барысы да белә. Шуңа да карамастан, аны билгеләвен дәвам итә. Эксперимент булмыйча нәрсә булсын инде бу? Мин ул дару турында күп белешмә җыйдым: ул кайсы балага килешә, кайсына юк. Тик килешкәне дә социаль активлыкны югалта. Әйтерсең, тормыштан төшеп кала. Әниләр! Балаларыгызны саклагыз! Мөстәкыйль карар кабул итүдән курыкмагыз! Берничә табиб белән киңәшләшмичә дәвалауга алынмагыз, бернинди кәгазьгә дә кул куймагыз!#Мин сезнең барыгызны да яратам!

Без табибларның абруе, компетентлыгы турында күп яздык. Белемсез яисә белеме җитәрлек булмаган табибтан да куркынычы юк. Чөнки ул кеше тормышы белән шаяра. Аның кулында шундый кадерле чимал. Ак халатлы шәфкать ияләренең белдексезлеге, хатасы аркасында үлем-китемнәрнең арта баруы да факт. Шуңа да без (бу очракта пациентлар – *авт.*) икеләтә игътибарлы, хәтта, әйтер идем, күпмедер дәрәҗәдә белемле, чиребез хакында мәгълүматлы булырга тиеш.



Соңгы өч ел мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә эләгү өчен көрәшкә багышланды. 2012–2013 елларда без «Тема» дип аталган балалар клубына йөрдек. Бушлай түгел, акча түләп. Анда күп нәрсәгә өйрәндек. Аннары, бакча сорап, РОНОга киттек. Анда безне: «Кирәклесен (ә безгә логопеды, дефектологы, психологы булган бакча кирәк) үзегез эзләп табыгыз», – диделәр. Берсенә бардык: «Безнең клиент түгел», – диделәр. Икенчесендә: «Балагыз безнең шартларда алга китә алмас», – диделәр. Өченчесендә: «Нигә безгә җибәргәннәр инде? Без бит 5 яшьтән алабыз», – дип кайтардылар. Бу узган ел булды. Быел исә безне 155 нче коррекцион бакчага җибәрделәр. Бакча мөдире безне алырга булды. Әмма елның ике ае тернәкләндерү үзәгендә үтәргә тиеш. Монысы – үзенә күрә бер шарт. Бик үтәр идек тә. «Апрель» үзәгендә чират өстендә чират. Кешеләр анда эләгү өчен ике ел алдан язылып куя. «Здравушка»быз бар иде, аны да кыскарттылар. Ә үзләре: «Барысы да инвалид балалар өчен!» – дип сөрән салалар. Дүрт ел санаторий күргән юк. РОНО кайда нинди балалар бакчасы эшләвен дә белми. Белмим нишләргә, кая барып бәрелергә, кемгә мөрәҗәгать итәргә? Психологлар балагызны һичшиксез бакчага бирегез. Ул яшьтәшләренә күнегергә, алар белән аралашырга тиеш, диләр. Ә безне беркайда алмыйлар. Чөнки без барып чыккан псих та, даун да, аутист та түгел. Теге якка да, бу якка да юк, кыскасы. Безнең ишеләргә урын каралмаган. Баланы бу битарафлык белән йөзгә-йөз очраштырмас өчен акча җыярга кирәк. Барын да акча хәл итә бу дөньяда.

«Бернигә карамый, мин бәхетле!»

Акча дигәннән... Өйдә бала карап утырырга мәҗбүр булган Айсуның кулына аена 17 мең сумга якын акча керә. Балага 10 мең сум тирәсе һәм калганы үзенә – инвалид бала тәрбияләгән өчен. Түләүле тикшеренүләр узарга, бер МРТга гына 20 шәр мең акча киткәндә, гаиләнең матди хәлен күз алдына китерүе кыен булмас. Өстәвенә, ортопедик аяк киеменең кыйммәтлеге тагын. Елына 20 мең сум шуңа гына тотыла. «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль закон бар барын. Анда пенсия күләме дә, коммуналь хезмәт күрсәтүгә 50 процент ташлама булуы, инвалид балаларга айлык акчалата түләү кертелүе (быелның 1 февраленнән ул 2527,06 сум тәшкил итә), азык-төлек алуга льготалар булуы (1048,97 сумлык) хакында да әйтелә. Моннан тыш, инвалид бала караучы әниләргә (448 сумга төшә) һәм балаларга (271 сум тәшкил итә) транспортта йөрү картасы да бирелә. Монысы – саннар. Ә менә көндәлектә, чынбарлыкта баласын дөньяга чыгарырга, һичьюгы үзен карарлык хәлгә китерергә йөргән, юк, алай гына дип әйтү дөрес булмас, батырларча көрәшкән ананың үз хәле хәл, әнә. Нигә Айсу шикелле әниләргә бирмиләр икән ул «Герой-ана» исемен?! Ун баланы караганнан да авыррак бит аның хәле. Ләкин ул зарланмый. Аның: «Мин дөньяда иң бәхетле кеше», дигәнен дә икеләнебрәк, ышанмыйчарак тыңлыйм. Үз юлын үзе сайлаган, кирәк чагында «юк» дип әйтә дә белгән, берсеннән-берсе җитди карарларны, бигрәк тә сабыена кагылышлысын бары үзе кабул итә белгән Айсу кебек кешеләр, бәлкем, бәхетледер дә.

Ниһаять, Айсуга да яшьтән яратып йөргән егете белән кушылу шатлыгы елмайган. «Без Марат белән туйны Һиндстанда үткәрәчәкбез, – ди ханым, елмаеп. Һәм янә өстәп куя: «Мин нинди бәхетле хатын, бәхетле ана!» Гаҗәп инде...

PRESSA.RU



«БЕЗНЕҢ ӘНИ МЕҢ АЛТЫН!»



Асия ЮНЫСОВА

Кеше тәңкә түгел, аның бәһасе маңгаена чүкеп язылмаган. Кешенең асыл бәһасе яши-яши танылa.

Сезнең алтын тәңкә күргәнегез бармы? Минем дә юк. Кояшта йөзе балкып тора торгандыр инде ул номиналы алтын белән бәяләнгән тәңкәнең. Нуры белән гел ымсындырып торгандыр инде ул алтын заты. «Мең дә бер кичә» әкиятләрендә үлчәү тәлинкәсенә ябышып калган дирхәмне мин гел ымсындыргыч алтын тәңкә итеп күз алдына китерә торган идем. Алтын адәм затларын аздыручы, юлдан яздыручы ниндидер бер кәсәфәт булып түгел, бәлки нур бөркүче, яктыртучы могҗиза сыман тоела иде миңа. Шулай булмаса, иң кадерле, иң сөекле кешебезне, йә бәгырь җимеше – балабызны алтынга тиңләмәс идек. Әгәренки алтын юньсезлек символы булса, аны зур мәшәкатьләр белән, олы тырышлык куеп җир куеныннан кояш яктысына чыгармаслар, бәлки, тагын да тирәнгәрәк яшерергә омтылырлар иде. Димәк, алтын күренеп, балкып торырга тиеш!

Руль тоткан юлдашымның йөзен яктырткан май кояшы минем уйларымны әнә шундый юнәлешкә кертеп җибәрде. Ә ул түгәрәк алтын тәңкә кебек йөзен кояшка куйган да бер галибанә тынычлык белән куәтле машинасын урман юлыннан алып бара. Зифа наратлар, чәчәккә бөреләнгән шомыртлар арасын кылыч сыман кисеп үткән алтын нурларга күзен йомарга уйламый да. Уйлары матур булырга тиеш аның, нурлар чыбыркысы гына сискәндерерлек түгел. Арттагы утыргычта әнине юк-бар сораулар белән аптыратасы түгел икәнен белеп бетергән төпчек кызы музыка дәресендә әле генә өйрәнеп чыккан җырын кабатлап кайта. Машинабызны язның тәүге сары күбәләге озата бара. Тыныч, рәхәт, гармония! Яшәешнең һәр көне әнә шундый – күз яшьсез, көләч елмаюлы, шатлык кына вәгъдә иткән мизгелләрдән чигелергә тиештер ул.

Хәер, шатлык сәйләннәрен кеше җирдән үзе чүпли, көләч мизгелләрен тузлы тирен түләп үзе таба. Кемгә нинди бәхет елмая бит әле, диясегезне белеп торам. Җавабым әзер: Адәм балаларын Ходай Тәгалә Җир йөзенә бертигез бирнә белән юллый – ак кәгазь мисалындагы чиста җан белән. Шул кәгазь битенә ниләр язу күп вакыт үзебездән тора. Иҗтиһадтан, тырышлыктан, ихласлыктан. Бәхәскә урын бар, әлбәттә. Ләкин, әйдәгез әле, бу юлы бәхәсләшмик. Чөнки мине бу фикергә этәргән кеше янәшәмдә утыра.

Мин аны РКБ поликлиникасында аңа күренергә килгән ханымнар янында чиратта утыра-утыра көтеп алдым. Диләрә Мөсәвир кызы Мусина – табиб-гинеколог, медицина фәннәре кандидаты. Аның белән якыннан танышырга теләвем ул табиб булган өчен түгел иде әле. Бик мактап сөйләделәр аны, яхшы хатын, яхшы ана, яхшы кеше, диделәр. Яхшы табиб та икәнен үзем дә әле генә белдем. Табиб янына кереп киткәндә күзләрендә нуры сүнгән ханымның кабинеттан чыкканда йөзе өмет нуры белән балкыганын күреп...

Үзе белән ни сәбәпле кызыксынуымны аңлый алмый йөди ул. Гап-гади бер ханым – Актанышның Диләрәсе ни эшләгән әле ул чаклы? Кешеләр алдында хисап тотарлык ни гөнаһы яки ни даны бар? Диләрә Мөсәвир кызының коңгырт күзләреннән генә укыйм мин бу сорауны. Өйләренә кайтып җиткәч исә хатыны күзләрендә чагылганны ире Илфат маңгайга бәреп әйтер: «Ни дип язасыз инде минем хатыным турында?»

Агыйдел буендагы Такталачык авылында булганым бар минем. Бөек шагыйрь Гамил Афзал эзләреннән йөрелгән иде. Авылның чыннан да шагыйрьләр ватаны булырлык гүзәллеген күреп белгәнгә күрә Диләрәнең табиб юлын сайлавына эчтән генә гаҗәпләнеп тә куйдым. Югыйсә менә ике дистәгә якын елда Актаныш төбәге, Агыйдел, Сөн, Ык гүзәллегендә оетып, татар мохитенә бер дигән шагыйрьләр, язучылар, рәссамнар бирде. Ул төбәк балалары каләмгә генә гашыйк сыманнар иде. Шулай да Мөсәвирләрнең Диләрәсе табиблыкка укырга бара дигән сүз чыккач, Такталачыкта гаҗәпләнүче табылмый. Бөтен физика, химия олимпиадаларында, спорт ярышларында җиңеп кайта торган бу кызның Казан медицина институтына барып керәсе көн кебек ачык. Керә ул! Нишләп кермәсен?

Казан урамында беренче очраган абзый ук шик белдерә: «Йөрмәгез, балалар, вакыт әрәм итеп. Ул институтка врач балаларын гына алалар. Анда да белгән кешеләренекен, Казаннарныкын гына. Йөрмәгез, йөрмә! Бу кытлык заманда». Чыннан да, заманы да кытлык – 1993 ел бу. Руслар әйтмешли, «лихие девяностые!» Тапканнар Такталачык кызларын куркытырлык сәбәп?! Ике дус кыз икесе дә керәләр дә, укыйлар да. Актанышның русчасын Казанның русчасына әйләндерү кадәресе генә кыенгарак килә. Тамак ягын, фатир ягын үзләре үк кайгыртырлык булмагач, өйдән китеп тә торасы юк! Хәстәрчән инде кызлар: сумка бавы гына чыдасын – өйдән тозы, шикәре, ите, мае ияреп килә. («Духтыр» буласы кызына фермада эшләүче әнисе Мөҗәлия үзенең ак халатын салып бирә. Диләрә ике үлчәмгә кечерәйтү хәйләсен дә таба.) Табагач кына әлегә калып тора. Чөнки кызларның уенда кияү түгел, укып чыгу, диплом алу. Тулай торак юкмы? Карауга мохтаҗ ялгыз карчыклар бар. Стипендия юкмы? Идән юа алган, массаж ясый белгән куллар бар! Ач та түгел, бай да түгел, әмма дискотекаларда сикерергә, кинога барып туңдырма ялап йөрергә вакыт юк.

Адилә оныкЛилия «апасы» белән яшьтәшләр.

Вакыт юкка карамый, Ходай Тәгалә насыйбын үзе юлга чыгарып куя икән ул. Якташының хәлен белергә килгән Илфат анда озын толымлы кызны күреп тынычлыгын югалта. «Беләк юанлыгы толымына гашыйк булдым. Кырыкмыш кызлар күңел кылын һич тибрәтми иде минем. Ә монда шу-у-ундый толым иясе чәй әзерләп йөри. Үзе табиб та икәнен белгәч, бетте абзагыз!» «Абзагыз» үзе дә каты чикләвек икән. Соклануы эчтән генә булган, телендә гел бөтен сүзләр: «Кызлар, миңа гашыйк була күрмәгез. Өйләнердән йөрмим мин. Өйләнгән кеше мин, ике улым үсә». Ә үзе кызлар янына һаман килә дә килә. Әйе, өйләнгән, әмма аерылган. Җитмәсә, 15 яшькә олырак та икән. Ә кыяфәте! Коеп куйган испан егете, спортчы. Янып торган кара күзләр... Гашыйк булып йөргән ул кышта Диләрәнең теленнән шигырь юллары китмәде: «Карар инде, карар инде кара күзләре белән!» Әлеге шигырь юлларын тиздән: «Мин Казанда сине эзләп таптым, Мин Казанда бәхет юрадым!» – дигән җыр сүзләре алыштырыр.

Март аеның сыерчык бураннары дулаганда ике гашыйк йөрәк кушылды. Шул көннәрдә Илфат көтелмәгән оригиналь вәгъдәсе белән кәләшен гаҗәпләндергән дә иде инде: «Көтмә, мин сиңа туй күлмәге кигермәм, туй да ясап тормыйбыз. Загска да бармыйбыз! Миңа кыз табып бирсәң, мин сиңа «Ока» машинасы бүләк итәм».

Фото: Ксения Богданова

PRESSA.RU

Бәхетле ханым иренең бөтен шартларына да күнә. Тик менә кыз урынына малай – Илшатны алып кайта. Әй үртәп тә куялар инде үзен дус-ишләре: «Нәрсә, малаймы? Окай-толкаймы?» Ә ул елмая гына: «Кыз алып кайтам әле мин». Икенчесе дә малай – Тимур; аның каруы, өченче булып туган Лилия инде әнисен шәп машинага утырта. Загска да өч бала белән баралар. Загссыз елларда да Диләрәнең йөзеннән бәхетле хатын елмаюы бер генә мизгелгә дә китми. («Мәхәббәт барында кәгазь нәрсә ул? Балалар аның фамилиясендә иде бит!») Хәтта буран туздырып ачуланышыр өчен сәбәп булган чакларда да елмая гына ул. Бер сәбәбен мин дә беләм. Языйм микән инде, юк микән? Язам! Беренче улы белән авырлы чагында кысан гына фатирда шәһәр читендә яшиләр әле болар. Эшкә бара торган автобуска шактый араны көзге яңгыр астында җәяүләп чыгасы. Туктап утыртучы юк. Бер тапкырында янышннан иренең машинасы выжлап үтеп китә, тизлеген дә киметми. Ул җаваплы эштәге кешене йөртә. Мөгаен, юл буенда калган йөкле хатын минем Диләрәм ул, димәгәндер инде. Югыйсә хуҗа кеше, белә калса, туктаттырмый калмас иде. Диләрә дә үпкәләп тормый. Башка берәү булсамы, дип уйлыйм.

Кайберәүләр бәхетле гаилә җылысыннан егәр алып китәр өчен дә килә.

Сабырлык таулар күчерергә сәләтле. Илфат Разов дөньясына килеп кергәндә Диләрә фәкать сабырлык белән акылны гына юлдаш итеп ала. Илфатның өлкән уллары Илназ белән Марат дөньясына акыллы, шәфкатьле Диләрә апалары иң кирәк вакытта, иң дөрес киңәш бирүче кадерле кеше булып килеп кергән. Илфат белән Диләрәнең икесенә хәзер дүрт уллары, бер кызлары һәм ике оныклары – Адилә белән Әмир бар. Хәер, ике килен дә балалар исәбендә йөри торгандыр инде. Алай дисәң, өлкән килен Резеда белән кара яндырып мунча кергәндә кайнана белән килен сердәшләргә әйләнәләр. Аралары нибары биш яшь кенә булгач ни.

Яшь аермалары җуелган, рәсми, ясалма мөнәсәбәтләр аралыгына шифалы бал коелган гаиләдә бергәлекнең кадерен белеп, уртак хыяллар белән яшиләр.

Инде менә урман уртасындагы бистәдә шәп итеп йорт салып куйганның соңында гаилә бәйләнешләре тагын да ныгыбрак киткән сыман. Чөнки хәзер һәр гаилә үз сукмагы белән берәр чит ил курортына чыгып китәргә омтылмый. Өйдә рәхәт. Нарат, каен агачлары белән янәшәдә, үз бакчаңда үзең утырткан чәчәкләр, түтәлләр арасында кайнашуга җитәме соң! Үз йортың белән яшәгәндә ир кешегә ир-ат шөгыле, хатын-кызга үзенеке табылып кына тора. Бала-чага да телевизор яки компьютер экранына төбәлеп зарыкмый. Иркен, сәламәт яшәеш. Түгәрәк табынны түгәрәк итү өчен сатып алынган диаметры 70 сантиметрлы табаны күреп тә



шаккаттым. Бәлеш табасы бу! Гаиләне түгәрәк итә торган таба.

Аларның түгәрәкләнә торган көннәре шимбә-якшәмбе. IT-лицейда укучы шәкертләр кайткач, алар янына гаиләле агайлары җыйнаулашып килгәч... Дус-иш, туган-тумача... Күп вакыт таба тирәли 20-30 кеше җыела. Каенлы урамындагы тыкрык машиналар белән тула. Килүчеләр югында таба ял итә. Ул чагында чаңгылар, велосипедлар дөньяга чыга. «Бер яңа ел алдыннан кибеткә бардым да барыбызга да Кыш бабай бүләге итеп чаңгылар сатып алдым», – дип сөйли Диләрә ханым. Бу юлы да нигә әле бу эш артыннан мин йөрергә тиеш дип тормаган ул. Энә кайда – җеп шунда дигәндәй, чаңгыны да башлап үзе киеп куя икән. «Безнең әни мең алтын», дип торган әниләрен кышкы урман юлына ялгызын чыгарып җибәрмәс бит инде биш егет. Җиләк җыйганда да шулай – әни алдан йөри.

Егетләренең дзюдода көч сынашканын Диләрә күп вакыт күрми кала, чөнки шайтан малайлар әниләрен юри уятмый китәләр – йокласын! Югыйсә ушуга да, тенниска да гел Диләрә йөртә торган булган үзләрен. Димәк, инде үсеп җиткәннәр!

Хәтта йорт салганда да. «Проектын, сызымнарын үзебез эшләдек, – ди Диләрә ханым. – Хыялланырга яратам инде мин. Менә бу почмакта ак пианино торыр. Анда кызыбыз Лилия музыкаль әсәрләр уйнап утырыр, дигән идем, шулай булды. Ә менә бу нәсел агачы сурәте торырга тиешле дивар һаман буш әле. Җыеп бетерә алмыйбыз. Иремнең әтисенең әбекәе гаҗәеп зирәк Кәримә әби, зәхмәтне (коммунистик зәхмәтне) адаштыру өчен ир балаларын төрлесен-төрле фамилиягә яздырган. Берүк, нәсел корый күрмәсен дип кайгырткан ул. Шул йоланы дәвам итеп, менә мин дә Мусина булып калдым.





Табиб-гинеколог Диләрә Мусинаның нәфис бармаклары сак кына кагылып, гөл тамырларын аралаганда мин аның белән кеше «чәчәкләре» – балалар турында сүз башлыйм. (Ана карынындагы яралгыны чәчәк бөресенә тиңләп куйган иде.) Ул бит институттан соң интернатураны РКБның бәбиләтү бүлегендә үткән. «Үзем бәби тапканчы балалар елавына озак иялләшә алмадым. Һәркайсын кулыма алып юатасым килеп йөдәдем. Аннары гына елау нормаль халәт икәненә күнектем».

Хәзер инде табиб Мусина поликлиникада ана булырга бик теләп тә, төрле сәбәпләр аркасында бу хыялына ирешә алмый йөдәгән аналарны дәвалау белән мәшгуль. «Әйе, экстра-корпораль ысул да бар. Соңчиктә кыралак әни (суррогат ана) табарга мөмкин. Тәрбиягә бала алу юлын сайлаучылар да бар. Тик бит һәр хатын-кыз үз мөмкинлеген ачып бетерергә тиеш дип саныйм мин. Үзең тапкан бәхет кенә кадерле!»

Һәр хатынга үз бәхетен табарга, организмын аңларга ярдәм итү өчен Диләрә Мусина әле дә өйрәнүдән, эзләнүдән туктамый. Югыйсә бер баласының ата-аналар җыелышында, икенчесенең «Соңгы кыңгырау» бәйрәмендә чагында эшне онытып торырга да булыр иде. Ә ул, шул чараларда үзен бик бәхетле тойганга күрә, йөзләгән башка хатын-кызларны ничек итеп үзе кебек бәхетле итәргә икән соң дип уйлап утыра. «Минем янга бөтен республикадан йөккә узып та аны саклый алмаган хатын-кызлар килә. Менә бер хатынның карынындагы баласы 12 атналык булганчы әйбәт кенә үсә дә өч айлык чагында үсеш кинәт туктап кала. Белдек сәбәбен – вак кан тамырларына тромблар утыра икән моның. Яралгыга туклану килми башлый».

Әйтергә генә ансат. «Тырышабыз» – бик хикмәтле сүз. Компетентлы, бала сөяргә тилмергән хатын-кызлар күзендә могҗиза иясе булып күренерлек табиб булып өлгергәнче әле аның ничәмә йөзләгән, меңләгән төннәр дәвамында йокы бүлеп, энә белән кое казыйсы бар. Төпчек кызлары кешеләргә игелек китерә алсын өчен, әни белән әти вазыйфаларны үзара бүлешәләр. Мөҗәлия апа авылда йортны тота; Мөсәвир абзый Казанда бала караша. Өч оныгын ияртеп, Такталачыкка кайтып төшкәндә күрше-тирә аны: «Бабай каникулга кайткан!» – дип, шау-гөр килеп каршылый.

Медицинада сюрпризлар гел бар инде ул...

Кандидатлык диссертациясенең темасы менә сюрпризлардан ерактыр кебек тоелды. Бала табу яшендәге хатыннарның, аннан соң инде ырудан калган, ягъни климакстагы хатын-кызларның сәламәтлеге өчен борчылудан килеп чыккан эзләнүләре инде системалы фәнни хезмәт рәвешен алган.

Борчылу сүзе белән Диләрә Мусина дигән докторның яшәү рәвеше тәңгәл икән ләбаса. Борчылу – аның өчен җаваплылык дигән сүз ул. Шушы җаваплылык тойгысы аны төп эш урынында эш көнен тәмамлап, өенә ашыгудан тыеп тора. Бер рәхмәт мең бәладән коткара! Татарстанда Диләрә исемле кызлар саны һаман арта тору – моның бер мисалы. Бала туарга, хатын-кыз ана булырга тиеш! Шуның хакына ул РКБ клиникасыннан хосусый клиникага барып, пациентларын дәвалауны шунда дәвам итәргә дә иренми.

Ире Илфат туган көненә бүләк иткән букетта 41 роза санадым. Илфатның хатынына мәхәббәте, рәхмәте символы бу чәчәкләр. Ә Диләрә үзен медицинага тулаем багышлый алганы өчен рәхмәтле иренә: «Тылым нык. Мин, әтисе исән генә була күрсен, дип яшим. Иң зур теләгем дә җырдагыча: «Бергә үтик тормыш юлларын!»

PRESSA.RU



РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

Без бүген ыгы-зыгылы, вакыйгалар бер-берсен туктаусыз алыштырып торган заманда яшибез. Көн тудымы – һәр яктан яңалык ява... Ә ул яңалыкны журналист бар кешедән алда ничек эзләп табуы турында уйланганыгыз юкмы сезнең? Журналистиканың бөтен эшчәнлеге дә яңалыкка корылган инде аның. Әмма «кайнар» яңалыкны табуны сәнгать дәрәҗәсендә башкаручылар бар. «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгының татар редакциясе шеф-редакторы Алсу ИСМӘГЫЙЛЕВА белән бүген шул хакта сөйләшәбез.

Гөлнур ХӘСӘНШИНА

ЯҢАЛЫКТАН АЛДА

– Tatar-inform.tatar сайтында көн саен 60 тан алып 80 гә кадәр хәбәр чыга. Шуларның 40 проценты – редакция хезмәткәрләре тапкан эксклюзив хәбәрләр. Калган өлеше – рәсми хроника һәм социаль әһәмияткә ия тәрҗемә хәбәрләр. Яңалыкларны ничек табабызмы? Моның өчен без төрле чыганаклардан мониторинг системасын булдырдык. Мәсәлән, быелтыр җәй Сүриядә һәлак булган россияле очучы Рәфәгать Хәбибуллин турындагы хәбәр безнең яңалыклар лентасына шулай килеп иреште. Самолет бәреп төшерелү турындагы хәбәрне беренче булып федераль яңалыклар агентлыгы таратты. Кызыксынып, һәлак булган очучыларның фамилияләрен эзли башладым. Баксаң, берсе татар икән бит! Исем-фамилиясен шунда ук «googl»га керттем. Ульян өлкәсеннән, Кулаткадан икәнен ачыкладым. Мин бу хакта хәбәр әзерләгән арада, редакциянең баш мөхәррире Рәмис Латыйпов Кулатка белән элемтәгә керде, һәлак булган очучының әнисе, туганнары белән сөйләште. Эзлекле яңалыклар чылбыры шулай туды.

Яңалык туган саен, аны лентага куя барабыз, яна торган кыска хәбәр лентада 3 минут эчендә пәйда була, мәгълүматны җентекләбрәк әзерләүгә 1 сәгатьтән артык вакыт китәргә мөмкин.

Безнең төп максат башкаларны кабатламаган уникаль яңалык табу, шуны иң беренче булып халыкка

җиткерү. Менә монда һәр журналистның шәхси элемтәләре ярдәмгә килә дә инде. Күптән түгел Яшел Үзән районы Бәчек авылы зиратында кабер ташларын җимерүләре турында шулай белдек. Бу хакта якшәмбе көнне кич белән яздык («ял көне, төн, бәйрәм» дигән сүз юк бездә!) Дүшәмбе иртән авылга хәбәрче, фотограф, видеооператор чыгып китте – теманы үстергәндә тагын яңалыклар килеп чыкмый калмый.

Иске яңалыкларны системалаштыру да яңалыкка әйләнергә мөмкин. Быел Тукай премиясен тапшыру алдыннан шагыйрь Ркаил Зәйдулла: «Аны язучыларга бирмиләр», – дигән сүз әйтте. Шулаймы соң бу? Утырдык та барлык лауреатларның исемлеген төзедек, кемгә нәрсә өчен бирелгәнен ачыкладык – инфографика әзерләдек. Чынлыкта, премия башлыча язучыларга һәм рәссамнарга бирелә булып чыкты.

Халык санын исәпкә алу буенча да шулай. Татар кими-кими дип әйтәләр, ә күпмегә кими соң ул? 1926 елгы халык санын алу белән бүгенге көнгә кадәр булган мәгълүматны тупладык. Инфографика шуны күрсәтте: сугыш вакытында, хәтта күпме халык үлеп тә, халык санын алганда татар арткан, ә 2002–2010 еллар арасында 200 меңгә кимегән...

Ә Софья Гобәйдуллинаның шәҗәрәсе буенча ясаган инфографика һәм видеоролик? Ул – мулла нәселеннән. Татар халкы турында әйткән фикерләрен, эшләрен туплагач, ачык күренә: аны бездә зурлаулары бик урынлы һәм дөрес. Ул маңкорт түгел!

«Татмедиа» агентлыгы башлыгы Айрат Зарипов татар халкының тулы куәткә эшли торган үз мәгълүмат агентлыгы булырга тиеш дигән максат куйды. «Татар-информ»ның генераль директоры Шамил Садыйков агентлыкның эшен дөнья стандартларын өйрәнеп, шуларга нигезләнеп кора. Ул һәрвакыт эзләнүдә. Безне дә шуңа этәрә. Алдагы мисаллардан күрәсез: яңалыкны эзләп табуның, җиткерүнең барлык заманча ысулларын кулланабыз. Актуаль тема яки вакыйга уңаеннан, атнага бер тапкыр татарча матбугат конференциясе уздырабыз. Татар телен «калька»лардан чистарту, телнең кагыйдәләрен искә төшерү максатыннан татар журналистлары өчен лабораториум ачтык. Видео-интервьюлар булдырылды. Казандагы татар чараларыннан онлайн-трансляцияләр ясыйбыз. Фотографлар, видеооператорларыбыз бар, монтаж өчен барлык мөмкинлекләр тудырылган. «Кырда» эшләүче һәр журналистта iPad бар.

Коллективыбыз гаҗәеп тырыш безнең! Гөлнар Гарифуллина, Лилия Локманова, Лилия Гаделшина, Рузилә Мөхәммәтова, Мөршидә Кыямова, Гүзәл Насыйбуллина, Сания Әхмәтҗанова, Гөлүзә Василова, Чулпан Шакирова, Надия Шәйхетдинова, Фәрит Салихов... Һәрберсе үз эшенең остасы.

Яңалык күпме яши: бер сәгать, бер көн, бер атна...

– Уйландыра торган яңалыклар озак яши. Әйтик, җитәкчеләрнең, күренекле шәхесләрнең аерым фикерләре күпләрдә кызыксыну уята, социаль челтәрләрдә телгә алына. Ә яңалыкларның 99 проценты, мөгаен, бер көнлектер. Һәм бу дөрес тә. Халыкка барып җиткән икән, димәк, ул бит инде максатына ирешкән дигән сүз. Бер генә мисал. Узган җәй давыл булачагы турындагы хәбәрне кичке сәгать 6 да алдык. Шунда ук язып элдек, аннан 1-2 сәгать социаль челтәрләр аша таратып утырдык. Хәбәрне меңнәрләгән кеше укыды. Төнлә көчле җил тавышына уяндым. Ярый, белделәр, ниндидер саклык чаралары күргәннәрдер, дип уйлаганым истә.

Сүз уңаеннан, «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында хәбәрләрне социаль челтәрләрдә таратуга зур әһәмият бирелә. Белгечләребез бар, яңалыклар таратуның уникаль системасын булдырдык.

Узган елның маеннан сайтыбызны укучылар саны 7,5 тапкырга артты.

Яңалыкларны социаль челтәрләр аша да табабыз, дидең. Әмма Фейсбук яки Твиттерда чыккан хәбәр автобуста колакка кергән яңалыктан әллә ни аерылмаска да мөмкин бит.

– Иң элек бер мисал. Абруйлы федераль чыганаклар, бер видеога таянып, күренекле бер Мәскәү артисткасының ислам дине кабул итүе турындагы яңалыкны язып чыкты. Бу хәбәрнең чынмы-түгелме икәнлеген актриса ханым үзе генә әйтә ала иде, әмма без аның белән элемтәгә керә алмадык, шуңа күрә яңалыкны сайтта чыгармый торырга булдык. Ә кичкә федераль канал аша ул аның дөрес түгеллеген җиткерде... Игътибар итсәгез, бездә һәр яңалыкның чыганагы күрсәтелә. Димәк, ул тикшерелгән, димәк, ул дөрес дигән сүз. Шуңа да рәсми чыганак дип саналабыз, без дәүләт агентлыгы, халык та, мәгълүмат белән эшләүче журналистлар да безгә ышана. Мәгълүмат чыганакларының абруен тикшерә торган «Медиалогия» рейтингында «Татар-информ» Татарстанда беренче урынга чыкты.

Көндәлек яңалыклар һәм... шигырь. Әйе, болар бер-берсеннән ерак кебек. Тик шигырьгә соңгы вакыт яңа сулыш өргәнне үзегез сизәсезме?

– Шигырьгә яңа сулыш өрдекме-юкмы, белмим, әмма шигырьне халыкка җиткерүнең яңа ысулын таптык шикелле. Шагыйрьләрдән интервью алганда сөйләткән шигырьләрне банер, видеоролик итеп ясатып, социаль челтәрләрдә һәм мессенджерларда таратабыз. Шагыйрь Роберт Миңнуллин: «Сез мине икенче тапкыр популяр иттегез», – диде инде. Аның шигырен эштән соң кич белән төгәл 20 кешегә җибәрдек. Ә икенче көнне ул безнең тәрҗемәчебезгә Чаллыдан, КАМАЗда эшләүче бер танышыннан килеп төште... Бер төн эчендә! Минем үземә дә әйләнеп кайталар, хәтта чит төбәкләрдән, чит илләрдән. Раил Садриев шигырь укыган видеороликны ТР Премьер-министры урынбасары Васил Шәйхразыев үзенең Фейсбуктагы битенә элеп куйган. Аңа нинди юллар белән барып ирешкән, монысын белмим.

PRESSA.RU











«ТУМЫШЫМ БЕЛӘН... БАЛАЧАКТАН»

Мәдинә АВЗАЛОВА

БАШКА БЕРӘҮНЕҢ УЕНА ДА КЕРЕП КАРАМАГАН КЫЗЫКЛЫ ИДЕЯЛӘР, ДӨНЬЯКҮЛӘМ ТАНЫТЫРЛЫК БЕРСЕННӘН-БЕРСЕ МАВЫКТЫРГЫЧ ЭШЛӘР... ШУҢА ДА АНЫ БЕЛӘЛӘР, ХӨРМӘТ ИТӘЛӘР, ЯРАТАЛАР.

Без аның белән бер мәртәбә хатын-кызлар бәйрәме алдыннан, «Ел хатын-кызы. Ел ираты: хатын-кыз карашы» дип исемләнгән республика бәйгесен йомгаклау тантанасында очрашкан идек инде. «Хатын-кыз – ел үрнәге» номинациясе буенча зона ярышларында җиңүче булган Наилә Камил кызы Таҗиеваның ул вакытта әйткән сүзләре хәтеремә уелып калды: «Мөмкинлектән файдалана алмый калудан куркам...» – дип гаҗәпләндергән иде ул мине. Нигә шулай диде ул? Нинди мәгънәдә әйтте бу сүзләрне?

...Казан уртасында урнашкан IT-паркның биек катлы бинасына аяк басуга, андагы ыгы-зыгыдан бер мәлгә югалып калгандай булабыз. Егет һәм кызларның кайсы «Безнең Татарстан» республика яшьләр форумы ачылу тантанасында, кайсы үзләре белән алып килгән әйберләрне күргәзмәгә куюу белән мәшгуль. Без аны йөзләгән кеше арасыннан танып алабыз. Әнә ул... Гадәттәгечә инде... тиктормас кыз һәм малайлары янында. Шактый вакыт янына килмичә, читтән генә күзәтеп торабыз. «Татарстан аграр яшьләр берләшмәсе» региональ иҗтимагый оешмасының Питрәч бүлекчәсе дигән зур реклама пәрдәсе тирәсендә кайнашкан яшьләр белән бергә. Күз алдында, санаулы минутлар эчендә ботаклары сушки-булкилардан гыйбарәт «икмәк агачы» барлыкка килә.

«Хәйран калып торабыз»

Бу хәлләрне тамаша кылып торган ир белән хатын: «Ошыймы?» дигән соравыма шулай дип җавап кайтара. «Авыл яшьләре дә үзгәрде хәзер, – ди абзый теле ачылып китеп. – Без бит питрәчлеләр. Шуңа кызыксынабыз.

Халык үзгәрдеме, җитәкчеләрнең авылга, авыл хуҗалыгын үстерүгә мөнәсәбәтеме, бүген әлеге мәсьәләнең көн үзәгендә торуы хак анысы. Күз алдындагы авылларга гына түгел, буй-күз җитмәс еракта гы, эчкәредәге авылларга да ярдәм итү, булган бөтен алдынгы үсеш алымнарын, юлларны куллану турында бара сүз. Сөйләнеп кенә калмаска, эшләп күрсәтергә! Ә эшләп күрсәтү ул «Татарстан аграр яшьләр берләшмәсе» региональ иҗтимагый оешмасының Питрәч бүлекчәсе җитәкчесе Наилә Таҗиева үрнәгендә булырга тиештер дип уйлыйм. Ишеткән-күргәннәремне тагын бер кат күңелем аша үткәргәннән соң, шундый фикергә киләм.

– Әле генә Италиядән кайттык, – дип сөйли башлый ул сүзне җөмләнең уртасыннан башлап. – Без Миланга – Халыкара күргәзмәгә Россия вәкилләре исеменнән бардык. Былтыр Питрәчтә уздырган «Скорлупино» йомырка фестивалендәге тамашаны күрсәттек. Күргән берсе хәйран калды. Италия телевидениесенең ике үзәк каналы килде. «Без – Татарстанның Питрәч районыннан», – дигәч, нык гаҗәпләнделәр. Ишеткән, күргәнмени?

Бүлекчә яшьләренең Халыкара күргәзмәләрдә беренче катнашуы гына түгел. Ә бит барысы да «Russian Event Awards» дип аталган вакыйгалы туризм өлкәсендә Милли премия алудан башланган иде.

Былтырның июнь ахырларында булып узган фестиваль турында питрәчлеләр әле дә булса сагынып, яратып искә ала. Ул чагында меңләгән халыкны үзенә караткан бу тамашага республиканың төрле шәһәрләреннән һәм авылларыннан дәрәҗәле кунаклар җыела. Бәйрәмгә Татарстан Республикасы Премьер-министр урынбасары, Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов та килә. Әйе, ул чагында Наилә Камилевна авторлыгындагы әлеге проект «Безнең Татарстан» республика форумының «Минем кече ватаным» номинациясендә беренче урынны яулый. Республикабыз авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең һәм агропромышленность комплексы эшчәннәренең абруен, дәрәҗәсен күтәрүне максат итеп куйган бу чараны Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов югары бәяли. Бәлкем, шуңадыр да аны алга таба да, ел саен үткәрергә, дигән карарга киленгәндер.

Миллионлаган сумлык грантлар да – аның казанышы.

Бер мең йомыркадан тәбә

– Ни өчен йомырка фестивале? Кай ягы белән үзенә каратты соң ул халыкны?

– Бездә танылган кошчылык фабрикасы барын онытмагыз, – ди ханым елмаеп. Проектны эшләгәндә иң элек шуны күздә тоттык. Кай ягы белән каратты дисезме?! Фестиваль берничә мәйданчыкта барды. Халык һөнәрчелеге күргәзмәсендә кулдан ясалган әйберләр сатылды. Икенче бер мәйданчыкта Казаннан һәм башка төбәкләрдән килгән оста ашчыларыбыз фарштан һәм йомыркадан төрле ризыклар әзерләү буенча мастер-класслар үткәрделәр. Янәшәдә генә зоопарк эшләде. Анда казын-үрдәген дә, бәрәнен-кәҗәсен дә, төрле кошларның, әйтик, попугай, тавис кошы, фазаннарның йомыркаларын күрергә дә була иде. Шулай да тамашачыны иң нык җәлеп иткәне, берсе – күмердә, икенчесе – электр плитәсендә пешкән йомырка тәбәсе булды. Аларның һәркайсына берәр мең йомырка китте. Һәркайсы йөзәр килограммлы табада пеште. Аның каравы, бәйрәмгә килгән кешенең берсе генә дә аны авыз итмичә китмәде.

Һәркайсы грантка лаек

Әгәр дә ул: «Тумышым белән... балачактан» дип әйтә икән, бу шулай. Чөнки үзен белә-белгәннән – балачак дөньясында. Мәктәптә укыганда, башта – комсомол район комитеты бюросы әгъзасы. Аннары «Чайка» сәламәтләндерү лагере вожатые, аннары – Чаллы педагогика институтын тәмамлап кайтканнан соң, башлангыч сыйныф укытучысы, Питрәч районы хакимиятенең балалар һәм яшьләр эшләре бүлеге җитәкчесе, 2009 елда әйткәнебезчә, Аграр яшьләр берләшмәсенең Питрәч бүлекчәсе һәм ниһаять, 2014 елдан «Форпост» җәмәгатьчелек тәртибен саклау үзәге директоры. Җыеп әйткәндә, менә 20 ел инде яшьләр сәясәтен җитәкли. «Татар-

PRESSA.RU

стан аграр яшьләр берләшмәсе»нең региональ иҗтимагый оешмасы рәисе Миләүшә Заһидуллина әйткәнчә, ул үзе эшләгән дәвердә 2 миллион сумга якынлык дистәләгән проектны гамәлгә ашырырга өлгерә. Узган ел Татарстан Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының авыл яшьләре арасында патриотик эшләр һәм наркотикларга каршы көрәшкә юнәлдерелгән грант ота. Көнен ел итеп яшәгән тынгы белмәс ханым яшьләргә экстремизм, терроризм турында сөйли, милләтләр арасындагы дуслыкның ни дәрәҗәдә мөһим булуын аңлата, аларны коррупциягә каршы көрәшергә чакыра. Былтыр ул республика форумына «АнтикоррЛига» коррупциясенә каршы интеллектуаль уеннар» дип исемләнгән проект тәкъдим итә. Экспертлар аңа янә иң югары бәя бирә, проектны гамәлгә ашыру өчен бирелә торган грант та аларга була.

Мәскәүдә узган Халыкара күргәзмәдән соң танылды да инде алар башта илгә, аннары – дөньяга!

– Җыр халыкны берләштерә, төрле милләтләрне дусләштыра. Былтыр без «Йөрәктән чыккан җырлар» дип аталган зур фестиваль үткәрдек. Яшьләр хоры районыбызда яшәүче халыкларның: рус, татар, белорус, чегән, яһүд халыкларының җырларын башкарды. Ел башында йомгаклау концерты булды. Әлеге проект республиканың 6 нчы форумында катнашу өчен җибәрелгән иде. Ул сертификат белән билгеләп үтелде. Идел буе федераль округы буенча үткәрелгән «Диво России» туристлык презентациясе бәйгесендә икенче урын, җәйге ялны оештыру буенча беренче диплом алдык.

...Мактанып әйтми, ә бары авыл яшьләренең иҗади мөмкинлекләре турында сөйли. Яшьләр лидеры тирәсенә тупланган егет һәм кызлар форумнарда, бәйгеләрдә катнашалар, район күләмендә генә түгел, хәзер инде ил һәм дөнья күләмендәге чараларда, иҗади осталыкларын күрсәтеп, республиканы таныталар. Наилә Таҗиева эшләгән проектларның һәркайсы («Син сайлаганы!», «Авылның алдан баручысы», «Йөрәктән чыккан җырлар», «Язмыш һәм ватан бердәм!» һәм башкалар) районлашлары арасында киң яклау таба. Ул тәкъдим иткән социаль проектның унбиштән артыгы республика гранты белән билгеләп үтелүе үзе үк күп нәрсә турында сөйли.

Аның: «Илкүләм үткәрелгән бер генә чарадан да читтә калмыйбыз...» – дигәне белән дә килешәбез. Бөек Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан, «Җиңү волонтерлары» хәрәкәтенә кушылып, авыл яшьләре һәм «Форпост» хокук саклау хәрәкәтендә катнашучы егет һәм кызлар, Җиңү көне уңаеннан нинди генә кызыклы, истә калырлык чаралар уйлап тапмадылар: Хәтер шәме, Билгесез солдат көне, Ватан герое көне, Җиңү хатлары, Советлар Союзы Герое Муса Җәлилнең туума 110 ел тулуга багышланган төрле кичәләр... Алай гына да түгел, Наилә Таҗиева үткәнебезгә, тарихыбызга битараф булмаган кайнар йөрәкле яшьләр белән дан аллеясын төзекләндерүдә катнаша, «Чайка» балалар лагеренда тарихи дәресләр үткәрә. Ул җитәкләгән былтыргы смена Татарстанда иң яхшылардан танылa. Аның шәкертләре Бөек Ватан сугышы ветераннарына булыша, алар турындагы фотодокументлардан архивлар оештыра.

Ул мине: «Башкарган эшләребезнең тамчысы гына әле болар», – дип гаҗәпкә калдыра. Һәм «Шатлык» социаль приютындагы балалар турында сөйләп китә. Хәтта вакытлыча гына яшәп тору урынын да авыл хуҗалыгы белгечлеген күтәрү, популярлаштыру үзәгенә әйләндерә алганнар: хәзер биредә алар инициативасы белән теплица эшли, кыз һәм малайлар анда яшелчә, чәчәкләр үстерәләр, ландшафт дизайны серләренә өйрәнәләр. «Без ул приютка «Агрокласс» программасы буенча методик материаллар тапшырдык, – ди әңгәмәдәшем. – Тормышта ярап куячак әле ул аларга».

Әйе, тормышта барысы да кирәк булачак: яшьтәшләрең белән аралаша белү, үз фикереңдә калу да, кайнар бәхәсләрдә дөреслекне табу, туган җиреңне ярату да...

«Таянычым, өметем...»

Уйлаганын шундук гамәлгә ашыра алу осталыгына ия булган бу ханымның ире турында: «Өметем ул», – дип сөйләве бераз сәеррәк яңгыраса да, кайтарып сорамыйм. Сабыр гына аны тыңлыйм.

– Әгәр дә ирем, балаларым булышмаса, мондый эштә эшли алмаган да булыр идем, – ди ул.

Эчке кичерешләрен кешегә күрсәтә торганнардан түгел ул. Шуңа да бу темадан читкә китеп, тагын әлеге дә баягы фестивальләр, бәйгеләр турында гәп куерта башлый. Әнә алар күптән түгел генә тагын бер җиңүгә ирешкәннәр: «Җәмгатьчелекнең тануы» номинациясендә җиңеп чыкканнар. Май урталарында булып узган «Яшьләр. Авыл. Агропромышленность комплексы» дип аталган Халыкара форумда ел саен үткәреләчәк «Скорлупино» фестивале турында сөйләгәннәр. Авыл туризмын үстерүгә зур өлеш кертү дигән сүз бит бу! Ә иң зур хыяллары – шушы исемдә аталган утар салып кую. Үзенә бер музей булачак бит ул аннары. Инде килеп, яңа эш урыннары, эшмәкәрлекне, халык иҗаты һөнәрен үстерү дә бит әле ул!

Алда берсеннән-берсе мавыктыргыч, зур эшләр көтә. Август урталарында алар «Скорлупино» фестивале үткәрергә җыеналар. Наилә Камил кызы әйтмешли, Сабантуйдан ким булмаячак бу бәйрәмгә Италиядән дә кунаклар көтелә. Инде килеп, тагын бер грант отсалар, «Икмәк» фестивале үткәрерләр, Зәйдә узачак «Печән» фестивалендә катнашырлар. Хәер, көн дә бер яңалыгы белән шаулатып алган яшьләр лидерының иртәгә сезне ни белән шаккаттырасын берәү дә әйтә алмый.

ҖӘМГЫЯТЬ



■ РФ Премьер-министры Дмитрий Медведев эш визиты белән Казанда булды. Ул КФУның Фундаменталь медицина һәм биология институтында эшләүче яшь галимнәр белән очрашты. Соңрак Россия икътисадын модернизацияләү һәм Россия инновацион үсеше буенча Россия Президенты карамагындагы Совет президиумы утырышын уздырды.

■ Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Идел Болгарстанында ислам динен рәсми кабул иткән көн уңаеннан мөрәҗәгать белән чыкты. «Яңарыш» республика фонды тырышлыгы белән быел беренче шәкертләрен кабул итәчәк Болгар ислам академиясе комплексы төзелде. Аны тәмамлап чыгучылар дин гыйлемебезнең бай традицияләрен лаеклы дәвам итәрләр дип ышанам», – дип белдерде ул.

■ Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов KazanSummit-2017 пленар утырышы ачылыр алдыннан «Invest expo» күргәзмәсен карады. Анда 25 предприятие катнашты. Рөстәм Миңнехановны КАМАЗ, Горький исемендәге завод, Ак Барс банкы, Иннополис һәм Казан (Идел буе) федераль университеты казанышлары белән таныштырдылар, мәгариф, сәнәгать, эшмәкәрлек өлкәләрендәге проектларны тәкъдим иттеләр.

КОТЛЫЙБЫЗ



■ «Сөембикә» журналының әдәби мөхәррире Эльмира Закирова XX «Бәллүр каләм»-2017» фестивалендә «Журналистикада исем» номинациясендә җиңүче булды. Шушы көннәрдә каләмдәшебезнең Татарстан китап нәшриятында «Иясез шатлык» китабы да басылып чыкты. Иҗат уңышлары белән котлыйбыз!

МӘДӘНИЯТ

■ Казанда XIII «Нәүрүз» Халыкара театр фестивале якутларның төньяк халыклары риваятьләре буенча эшләнгән «Бәхет кошы» балалар спектакле белән башланып китте. Быелгы «Нәүрүз» фестивале Саха Республикасы театр сәнгатенә багышланган иде. Ачылыш тантанасы Кабан күле буендагы амфитеатрда узды. Тамашачылар Алтай, Башкортстан, Кабарда-Балкар, Казакъстан, Татарстан, Тыва, Хакасия, Якутиянең иң яхшы спектакльләрен карады. Эстониянең «R.A.A.M» театры фестивальнең махсус кунагы иде.

■ Казан «Пирамида»сында студентларның «Дөнья энҗесе-2017» VIII Халыкара матурлык һәм талант ачык бәйгесенең финалы узды. Чарада дөньяның 30 иленнән меңнән артык кеше – Россия һәм чит ил студентлары, мәртәбәле кунаклар, мәдәният һәм мода өлкәсендә экспертлар, яшьләр, бизнес оешмаларында эшләүчеләр, иҗат әһелләре катнашты. 14 вәкил финал этабында жюрины һәм тамашачыларны иҗади чыгышлары, интеллектуаль бәйгедә – рус телен белүләре, үзләренең милли киемнәре белән сокландырды.

МИЛЛӘТ

■ Парижда, Марс кырында, Эйфель манарасы янында 12 илдән 300 дән артык татар диаспорасы вәкилләре Сабантуйга җыелды. Бәйрәмне тамаша кылучылар саны исә 20 меңгә җитте. Париж мэры Анн Идальго, Казан делегациясен сәламләп, Франция башкаласында татарның милли бәйрәме үтүгә шатлануын белдерде. Кунаклар Сабантуй ярышларында актив катнашты, җырчыларга кушылып җырлады, татар милли ризыклары белән сыйланды. Артистларның чыгышлары алкышларга күмелде. Татар милли көрәшендә 13 илдән 33 батыр көчләрен сынап карады. Татарстан көрәшчесе Раил Нургалиев баш батыр булды.



■ «Ак калфак» татар хатын-кызлары оешмалары Башкортстанның Салават шәһәрендә «Шәҗәрә бәйрәме» уздырды. Анда Россиянең 11 төбәгеннән, Татарстанның ике дистәгә якын районыннан килгән хатын-кызлар катнашты. Башкортстанда һәр гаиләнең нәсел шәҗәрәсе бар: татар милли традицияләрен, гаилә кыйммәтләрен саклау максатында оештырылган бу бәйрәмдә шуның матур үрнәкләрен күрсәттеләр.

СПОРТ

■ Татарстан башкаласында «Казан марафоны-2017» узды. Йөгерештә Татарстан Республикасы Премьер-министр урынбасары Васыйл Шәйхразыев, Премьер-министр урынбасары – мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры Роман Шәйхетдинов, яшьләр эшләре һәм спорт министры Владимир Леонов, сәламәтлек саклау министры Гадел Вафин, Казан Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Дамир Фәттахов катнашты. Өч километрлы дистанциядә популяр җырчы Нюша да старт алды. Марафонга 10 меңгә якын кеше теркәлгән. Катнашучыларның географиясе дә киң: анда 75 төбәктән, дөньяның 25 иленнән вәкилләр катнашты.

PRESSA.RU



Фото: Ландыш Әбүдәрова

УЕНЧЫКНЫҢ ФӘЛСӘФИ НИГЕЗЕ ДӘ ШУНДА: УЛ БАЛАНЫ ОЛЫ ТОРМЫШКА ӘЗЕРЛӘРГӘ, ҮСКӘЧ, СОЦИАЛЬ РОЛЬЛӘРЕН БАШКАРУ ӨЧЕН КҮНЕКМӘЛӘР ТӘРБИЯЛӘРГӘ БУЛЫШЫРГА ТИЕШ. ӘГӘР БАЛАГА КҮҢЕЛСЕЗ ИКӘН, ДИМӘК, ӘЛЕГЕ УЕНЧЫКЛАРНЫҢ ФАЙДАСЫ ДА ШУЛКАДӘР ГЕНӘ БУЛЫП ЧЫГА?!

Ландыш
ӘБҮДӘРОВА

«ЧӘЙ ЭЧӘРГӘ ФИЛ КИЛСЕН!»

Озын ял көннәре туры килде дә Зөлфия өч көн буена бакчага бармыйча өйдә утырды. Өченче көнне: «Миңа күңелсез!» – дип, ямансулап, безгә аркасын куеп караватына менеп яткач, йөрәгем «жу» итеп китте. Күңелгә шундук шөбһә йөгерде: Куприн хикәясендәге кебек, чәй эчәргә филне чакырыгыз, дип әйтмәсә генә ярый инде.

Филе бер хәл, 4 яшьлек бала күңелсезлекнең ни икәнен белсен әле?! Чәчелеп яткан уенчыклар өстенә басмаска тырышып, бала янына килəм. Пультка басып, телевизордан мультфильмны сүндерәм. Баланың көйсезләнүе генәме бу, әллә бала тәрбияләүдәге хаталарыбызның чираттагысы, төзәтүне сорап, чаң кагамы?

– Нәрсә булды? – дим кызымның аркасыннан сөеп.

– Миңа күңелсез, – ди.

Бераз үгетләгәч, күңелсезләнүенең сәбәбе дә ачыклана: кибеткә барып берәр яңа уенчык сайлап аласы килә икән. Караватка менеп ятуы көйсезләнү генә булган икән әле аның, менә баланың яңа уенчык алу теләге – хәзерге заман әти-әниләренең тәрбиясендәге бер хата дияр идем.

Кайсыдыр бер психолог-педагог уенчыкларның күләме әти-әнинең балага биргән наз-игътибары күләменә пропорциональ дигән. Ягъни әти-әни баласына биреп бетермәгән игътибарны уенчыклар белән компенсацияләргә омтыла, ди ул. Монда хаклык бар барын, әмма һәр кагыйдәдән чыгармалар булган кебек, аның да үз нечкәлекләре.

Мәсәлән, бездәге бер олау уенчык ничек җыелды соң? Барысы да компенсация акты түгел, әлбәттә. Дөрес, кайберләрен шулай дияргә дә була: менә бу раковинасы, плитәсе булган өстәлне Зөлфиягә әтисе Һиндстанга китәр алдыннан алып бирде, янәсе, үзе югында күңелсезләнмәсен. Калганнары туган көн, Яңа ел, 8 Март бәйрәмнәре бүләкләре. Бер өлеше – дәү әни, дәү әти, әби-бабай, абый-апалар, туганнар, дусларның «ярату билгеләре». Баксаң, өйдә очраклы гына килеп кергән бер уенчык та юк, һәркайсының «үз тарихы» бар икән. Ләкин балага барыбер күңелсез бит әле монда – менә хикмәт нидә. Димәк, кайдадыр хата бар.

Үзем әни кеше буларак, уенчыкларны бала үсешенә файдалы булсын дип алырга тырышам. Уенчык кибетендә үземне берәр күзәтү органының инспекторы кебегрәк тотам, имеш, уенчыкның бер бәйләнер җире дә булмасын. «Made in China» дигән язулысын шунда ук бракка чыгарам – инглиз телен белмәгәндә дә әле бу сүзләр безнең баш миенә «түбән сыйфатлы» дигән стереотип булып уелып калган. Ягъни мондый тамгалы уенчыклар сасы исле, димәк, формальдегид, фенол кебек бала сәламәтлегенә өчен зарарлы матдәләр бүлеп чыгаралар. Икенчедән, алар бер көнлек. Хәер, хәзер уенчык сатучылар да моны аңлый, кибетләрдә зарарлы булырдай уенчыклар бик сирәк очрый.

Зөлфия, үсә төшкәч, уенчыкларны үзе сорап ала башлады. Реклама да үз хасиятен башкара: телевизорда күргән берен алдыра бара. Соңгы вакытта агачтан эшләнгән уенчыклар күп сатыла. Без дә мавыгып алдык. Һәртөрле конструкторлар, «Лего»лар да җәлеп итте аны. Ләкин фанат дәрәҗәсенә җитмәдек. Андыйлар да бар икән: мәсәлән, «Лего» белән «җенләнүчеләр» туган көненә дә, бәйрәмнәргә дә бары тик шуны гына сорый, коллекция туплый. Хәтта ки «лего»лы кызлар-малайлар белән генә дуслаша. Ә андый «фирменный» уенчыклар бик кыйммәт тора. Кемгә ничектер, әмма мин моны маркетологларның чынга ашкан хыялы дип саныйм. Баланы кармакларына эләктерделәр дә шуның белән эшләре хутта аларның. Үзләре дә балалыктан чыгып бетмәгән әти-әниләре дә алар тозагында. Уенчык тартмасына киләсе модельнең рекламасын салырга да онытмыйлар, акча җыя торыгыз, янәсе. Шөкер, безне әлегә «My little Pony», «Лего» һәм һәртөрле трансформерлар, роботлар, монстр курчаклар урап узды. Уйнарга чыккач, яшь әниләрнең чираттагы коллекция белән мактануын эчтән генә елмаеп тыңлыйм: куллanучылар җәмгыятенең кечкенәдән сукырайтылган кулланучылары үсеп килә бит.

Шулай итеп, бала хыялында йөрткән уенчыгына кинәнергә дә өлгерә алмый кала, аңа инде рекламадагысы кирәк була башлый.

Ә балалар өчен чыннан да файдалы һәм алар яратып уйный торган уенчыклар, мавыгулар кыйммәт түгел. Болар – кәгазь-каләмнәр, төсле буяулар, рәсемле китаплар, шул ук шакмаклар һәм пирамидалар. Болар баланың фантазиясен дә баета, вак моторикасын да камилләштерә, интеллектын да үстерә.

Шулай да уенчыклар алгандагы хаталарыбызны танымый булдыра алмыйм.

Беренчедән, уенчык кибетендә без үзебез дә бала икән ләбаса! Зөлфия әле бала арбасында утырган чакта ук без аңа үзебез кызыккан уенчыкларны алып бирергә тырыштык. Мәсәлән, әтисе идарә итеlә торган кәттә машина сатып алды. Алганчы күпме бәхәсләштек. Ул машина ди, мин – Барби. «Зөлфия яратып уйнаячак! Шофер кызы ул», – дип хәл итте ул вакытта әтисе. Кич буена ул машинаны алга-артка, уңга-сулга йөртеп күрсәтеп, баланың игътибарын җәлеп итәргә тырышты. «Кыз бала ул, аңа курчак кирәк», – дип каршы төштем, кулымдагы Барбины селкетеп. Ләкин балабызга болар кирәкмәде никтер. Машиналар белән кызыксына торган кызлар бар ул, ләкин Зөлфия андыйлардан түгел. Аның каравы, хәзер Адилә яратып уйный ул машина белән.

«Без кечкенә чакта мондыйлар юк иде», – дидем мин, Барбины күкрәгемә кысып. Барбилар сатуга чыкканда, без инде курчаклы уйнау яшен узган идек. Ләкин безнең Настя, Ира, Зина кебек курчаклардан бик нык аерылган Барбиларга кызыгу калган иде. Шуңа да үземнекен иттем – Зөлфиягә дигән булып, Барби ал-

PRESSA.RU

дым. Әле дә өр-яңа килеш көзге алдында тора балерина Барбием. Ә Зөлфиягә «baby born» кызык булды: ашыйэчә, кече йомышын йомышлый, күз яшьләре чыгарып елый белә. Аңа «памперс»лар алабыз, караваты, кашыктәлинкәләре, чүлмәге, тартып йөрергә арбасы бар.

Икенче хатабыз: безнеке булмады, аныкы булсын, дигән принцип. Безнең өйдә шулай итеп «Икеа»ның кара тактасы, самокат кебек Зөлфия әлегә кызыксынмый торган әйберләр барлыкка килде. Яше җиткәч, үзе сорап алачак икән ул аны. Әгәр кызыксынса.

Кыйммәтле уенчыклар беренче чиратта әти-әниләрнең үзләренең капризы, алардан күреп – балаларныкы.

Йомшак уенчыклар

Ниндие генә юк ул йомшак уенчыкларның? Кибеттә күргән саен аласы, кочып-кочып уйныйсы килә үзләрен. Әлеге дә баягы балачак кайтавазы, дип аңлыйм мин йомшак уенчыкларга тартылуны. Безнең буын классик йомшак аюдан башканы күреп үсмәсә дә, йомшаккайларыбыз күп иде: авылда эт-песи асрамаган гаилә аз була иде. Кыш көннәрендә сарыклар бәрәнләсә, өшемәсен дип яңа туган бәтиләрне төнгә өйгә кертәләр. Өлкәннәр өчен мал ул, ә безнең өчен – тере уенчык. Мәш киләбез шулар белән. Сөт исе килеп торган шул юеш борыннар үзләре йомшак, үзләре җылы... Яз җитүгә караватастында йомырка басып утырган казларның бәбкәләре борынлый. Тилгәннән кем саклый ул нәни, йомшак йомгакларны? Әлбәттә, әбиләр һәм бәбиләр инде. Җәй башына печәнлектә тавыклар качып утырган җирләреннән сапсары йомгакларын ияртеп чыгалар. Алар янына тагын дистәләрчә инкубатор чебие өстәлә. Авыл баласының йомшак уенчыклары әнә шулай күп була. Әле сыер бозаулый, әле бия колынлый. Боларның берсе дә кызыксынучан бала игътибарыннан читтә калмый – ул көннәр буе шулар янында кайнаша. Санитария-гигиена кагыйдәләре дип тормый әти-әни – рөхсәт итә, аллергия кебек чирләр дә юк әле ул вакытта... Хәзерге заманда йомшак уенчыклар әнә шулар урынына барлыкка килгәндер дип саныйм мин.

Яраткан уенчык

Баланың яраткан уенчыгы булырга тиеш, ди психологлар. Ләкин юк бит ул. Менә шул бер олау уенчык арасында иң ятратканы юк аның. Аның каравы, кунакка килгән берәр яшьтәшенә кайсы да булса берсе ошап, бүләк ит, дисәң, Зөлфия мал кортына әйләнә.

Яраткан уенчык дигәннән, баланың ватылган уенчыкларына мөнәсәбәте дә күп нәрсә турында сөйли. Мәсәлән, җигүле аты бар иде аның. Шуның тәртәләре сынган. Моны күргәч, Зөлфиянең әллә ни исе китмәде. «Икенчесен алырбыз, яме», – диде. «Ә монысын нишләтәбез?» – дим. «Ташлыйбыз», – ди. Аның мондый мөнәсәбәте борчыды, әлбәттә. «Ташласаң, ул елый бит. Аны башка кыз яки малай табып, өенә алып кайта, төзәтә, аннан соң ат ул кызны яки малайны ярата башлый», – дигәч кенә, бала уйга калды. Ә бераздан карасам: ул нәкъ менә шушы атына игътибарлырак була башлаган, миннән тәртәсен дә төзәттереп алды. Шул рәвешле Зөлфия кадерләүнең ни икәненә төшенде.

Уенчык күпме булырга тиеш, дигән сорау минем өчен әле дә ачык кала. Төгәл генә җавапны бирәү дә бирә алмыйдыр. Өй буйлап чәчелгән уенчыкларны бергәләшеп (баладан уенчык җыйдыру – бала тәрбияләүнең югары ноктасы, дип уйлыйм) яки инде бала тәмам арып йокыга талгач, үзең генә җыйганда, бу кадәр уенчык кирәкми, дигән фикергә киләсең. Уенчыклар кибетендә йөргәндә, баламның мондые юк бит әле, дип кызыгып карап торасың да капма-каршысын уйлыйсың. Һәм бүгенге муллык заманында: «мөгаен, мулдан булырга тиештер», дигән нәтиҗә ясап куясың.

ФИКЕР



Эльвира КЫЯМОВА-КӘЛИМУЛЛИНА, Динә исемле кызчыкның әнисе:

– Бездә дә уенчыклар бик күп. Аларны күбрәк безгә бүләк итәләр. Барысы да диярлек баланың үсешенә булыша торганнар. Үзебез күбрәк китапларга, пазлларга өстенлек бирәбез. Бармак белән рәсем ясарга, трафарет ярдәмендә сурәт төшерергә яратабыз. Вак моторика өчен файдалы, диләр. Ә менә йомшак уенчыклар, курчаклар ни өчендер кызыксындырмый.

Уенчыклар күп булса да, аларны чиратлаштырырга кирәк. Бер көнне пирамида, бер көнне шакмаклар, бер көнне формалы уенчыклар...

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА, Илһам белән Ильяс исемле малайлар әнисе:

– Уенчыкларны балаларның кызыксынуына карап алам. Мәсәлән, олы улым машиналар белән уйнамый, аңа китап, язу-сызу әйберләре кызыклырак. Кече улым исә стандарт «малайларча» уенчыкларны үз итә. Шунысы кызык: ишегалдында берәр бала таяк белән уйнап йөри икән, калган барысына да шул таяк кирәк! Заманча, интерактив, күпфункцияле уенчыклар читтә ятып калырга да мөмкин. Ә менә планшет, телефон ише нәрсәләрдән урамга, саф һавага йөрергә алып чыгып китеп кенә аерып була балаларны. Әлегә...

КЫЙБАТЫ БАР, АРЗАНЫ ЮК...

«Volga Fashion Week 2017» мода атналыгының финалы алдыннан әлеге чараны оештыручылар мода индустриясе өлкәсендә эшләүче белгечләрне «түгәрәк өстәл»гә чакырды. Алар арасында мин дә бар идем. Габриэль Шанельнең: «Мода үзгәреп тора, стиль беркайчан да үзгәрми» дигән канатлы сүзләре ул көннең шигаренә әйләнде. Традицион милли кием һәм аны бүгенге көнгә яраклаштыру турындагы кайнар бәхәсләр, яңа фикерләр «түгәрәк өстәл»нең төп темасына әйләнде.

«Сөембикә» журналы редакциясе 2009 елдан бирле милли кием дизайнерларының «Internacional Fashion» Халыкара конкурсын оештыручыларның берсе. Конкурсның җиңүчеләре һәм лауреатлары инде исемле дизайнерлар булып танылдылар, үз предприятиеләрен ачтылар. Республикада татар милли күлмәкләре, аяк һәм баш киемнәре, төрле аксессуарлар җитештерүчеләр бар. Ләкин алар күп түгел. Татарстанга килүче кунаклар һәм туристлар саны елдан-ел арта, алар традицион милли мотивлы заманча киемнәр сатып алырга тели. Башкалабыз кунаклары халкыбызның милли модалы киемнәрен тренд итеп киеп йөрергә хыяллана икән. Ни кызганыч, бүгенге көндә республикабызда андый киемнәрне җитештерүчеләр юк дәрәҗәсендә.

Чит ил базарына чыгу максатын куйган дизайнерлар өчен иң мөһиме – үз товарын сату. Бу юнәлештә нәкъ менә профессиональ байерлар эшли инде. Безнең яшь талантлар әле Европа базарына ук чыгарга әзер түгел. Алай да ниндидер уңышларыбыз да бар. Мәсәлән, татар милли аяк киемнәренең «күн мозаикасы» стилендә тегелүе Европа мода индустриясе белгечләренә инде яхшы таныш. Ләкин «Спартак» аяк киемнәре фабрикасы торгынлык хәлендә. Югыйсә фабрика тикле фабрика куәте белән традицион татар аяк киемнәре җитештереп, дөнья базарына чыгарга, милли чүәкләрне Сабантуйларда кияргә мөмкин булыр иде. Сүз дә юк, читекчеләребез дә бар, ләкин алар берән-сәрән генә. 20–30 меңгә кем генә сатып алсын! Алар бит кулдан тегелә, диярләр. Әйе, читек, чүәкләр гомер-гомергә бары кулдан гына тегелгән. Шуңа аларны урта хәлле кеше сатып ала да алмый – артык кыйммәт.

Үзәк шәһәрләр берничә була ул чакларда – Казан, Уфа, Касыйм, Әстерхан, Тобол. Шәһәр татар мәдәнияте аларда урта гасырлардан ук күзәтелә, шул ук вакытта бер-берсеннән аерыла да. Гади генә итеп әйткәндә, милли кием – ул, беренче чиратта, милләтнең мәдәнияте, кабатланмас үзенчәлеге, тәрбиялелеге. Бездә ул милләт тәртибе дип йөртелә.

Нәрсә ул заманча концепцияле мода коды? Моданың ул юнәлеше турында яшь дизайнерлар сөйләшергә ярата. Эш тәҗрибәсе дә булмаган килеш, милли костюм мирасы турында өстән-өстән генә нәрсәдер ишетеп, традицияләрне боза-боза, эчтәлектә һәм символларда яңа мәгънәви кыйммәтләр эзләп, мода темасына сөйләшкәндә фантазиягә бирелеп китәләр. Мисалга, татарның милли күн аяк киемнәре бизәкләрен яшь дизайнерлар күлмәкләргә, футболкаларга күчерә. Бер караганда, мода индустриясендә яңа ачыш кебек тә карала, ләкин бозарга ярамаган кануннар да бар бит әле.

Костюмдагы этник традицион мотивлар, борынгы бабаларыбыз тарафыннан буыннан-буынга күчә барып тупланган мәгълүматны, нигездә, табигый һәм функциональ белгеләр ярдәмендә җиткерә. Күп гасырлык тәҗрибә бу очракта милли кием телен иҗат итүче буларак карала.

Бүгенге көн татар милли җәмгыятендә, аеруча аның алдынгы катламында (эшмәкәрләр, иҗат әһелләре, фән кешеләре, зыялылар), территориаль кысалар белән чикләнмичә, татарлыкны күрсәтергә тырышу ихтыяҗы артты, ул милли костюм элементларында да сизелә. Ләкин бездәге җиңел сәнәгать, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары бүгенге көндә татар милли элементлары булган киң кулланылыштагы товарларны (киемнәр, баш һәм аяк киемнәре, аксессуарлар) җитештерергә әзер түгел әле. Мәсәлән, Казан дәүләт милли тикшеренү технология университетында аерым факультет, Казан федераль университетында дизайн кафедрасы бар, алар күпмедер дәрәҗәдә кием дизайнерларын да әзерләп чыгара. Әлеге уку йортлары укытучыларына мин, студентларыгызны Көнбатышка түгел, Шәрык илләренә җибәрегез, дияр идем. Анда текстиль әзерләү традицияләре, ефәк җитештерү, алтын җепләр белән чигү, гамәли сәнгатьнең мәдәни мирасын саклау өлкәсендә эшләүче гыйльми академияләр бар. Татар сәүдәгәрләре гомер-гомергә Урта Азия белән тыгыз элемтәдә булды, аннан кайтартылган ефәк, бәрхет тукымаларга милли бизәкләр төшерделәр.

Милли киемнәр җитештерүчеләр исеменнән Татарстан хөкүмәтенә дәүләт ярдәме сорап мөрәҗәгать итәсе килә. Биредә барысы да – мода индустриясенә булышкан хөкүмәт тә, икътисад үсешенә юл ачкан индустрия үзе дә отачак кына.

Милли үзенчәлеккә ия булган җиңел сәнәгатьне үстерү бу өлкәдә эшләүчеләрнең төп бурычы булырга тиеш. Тик шунысын да онытырга ярамый: модага сукырларча ияреп, үз йөзеңне югалту куркынычы да бар.

Рәмзия КАШАПОВА









PRESSA.RU



АЛАРДАН КӨНЕ БУЕ КЕШЕ ӨЗЕЛМИ! СУРГУТ МӘЧЕТЕНДӘ МИНЕМ ҮЗЕМНЕ ИҢ ШАККАТТЫРГАНЫ ШУЛ БУЛДЫ. КИЛГӘН ҺӘРКЕМНЕ ИКЕНЧЕ КАТКА, МАХСУС БҮЛМӘГӘ ЧАКЫРАЛАР, ҮТЕНЕЧЕН ТЫҢЛЫЙЛАР... ҖЫЛЫ ИТЕП, ЯКЫН ИТЕП КАРШЫ АЛГАН, ХӘЛЕҢӘ КЕРГӘН, КИҢӘШ БИРГӘН ҖИРГӘ ТАГЫН, ТАГЫН КИЛӘСЕ КИЛӘ БИТ УЛ!

ХӘЗРӘТ БЕЛӘН АБЫСТАЙ

– Хәзрәтнең чит илдә укыган вакыты иде. Һич онытмыйм, әти Себер ягында йөреп кайткач, хәл белешергә дип, янына кемнәрдер килде. Аның Казанда казый булып эшләгән чагы инде бу... Мин кунакларга табын әзерләп йөрим. «Безгә берәр хәзрәт җибәрсәгез иде, мәчет салыр идек, дип сорадылар, киңәшләшик әле», – дип сөйли әти. Үзем чәй ясыйм, үзем уйлыйм: «Ай-һай, кем барыр икән шулкадәр еракка?» – дим...

Шулай, Төркиядә белем алган олы улы Таһир өйләнеп кайтуга, Габделхак хәзрәтнең сак кына: «Улым, бәлки, Сургутка син китәрсең?» – дип әйтәчәген, аннан килененә карап: «Кызым, озакка түгел, бер елга гына. Бары бер елга!» – дип өстәячәген ул чакта кем белгән?! Ә бу гаиләдә әти сүзенә каршы төшү юк...

Әмма Себергә ничек килеп төшүләре турында сөйләүгә күчкәнче, аларның бер-берсенә бүгенге кебек «Хәзрәт» һәм «Абыстай» дип түгел, «Таһир» һәм «Рәйсә» дип кенә эндәшкән чакларына кайтасым килә әле. Дини кануннар буенча яшәүче гаиләләр Рәйсә туып-үскән Кече Елга авылында гына түгел, Казан кебек зур шәһәрдә дә бармак белән генә санарлык чакта, алар нәкъ менә рухларына туры килгән кешене – бер-берсен ничекләр эзләп тапканнар соң?

– Ә безнең әтиләр дус иде, – дип сөйли Рәйсә абыстай. – Әти җомга намазларына Казанга, Мәрҗани мәчетенә барып йөри. Ә Таһирның әтисе анда эшли.

Кайнатамны – бөтен гомерен халык арасында дин-ислам таратуга, ислам дине тарихын өйрәнүгә багышлаган, Татарстанның Баш казые булып торган Габделхак хәзрәт Саматовны инде беләсез... Дин кардәшләр буларак алар бер-берсен якын итәләр иде. Таһирның әтиләре җәйләрен, җыелып, безгә – Лаешка бал алырга кайталар. Без гаиләдә җиде бала, мин – өченчесе. Кунакларга минем дә чәй көйләгән чакларым булгалады. Бәлки шунда игътибар иткәннәрдер, бәлки Таһирга да әйткәннәрдер... Мирный бистәсендә Муллаян абый дигән кеше үз өенә яшьләрне чакыргалый иде. Егетләр Коръән укыйлар, без, кызлар, тыңлыйбыз. Бер-беребез белән танышабыз. Берсендә без авылдан өч кыз килдек, әти китереп китте. Бик оялчан идем әле... Таһир шул көнне миңа беренче тапкыр сүз дәште.

Аннан соң егет турындагы хәбәрләр кыз колагына бал аерткан көнгә туры китереп кайткан Казан кунаклары сөйләгәннән генә килеп ирешә: «армиядә», «хезмәт итә»... Таһир солдат киемнәрен салуга исә Кече Елгага башкодалар килеп төшә. Унынчыны тәмамлагач, читтән торып техникумга укырга кергән һәм китапханәдә бер генә ел эшләргә өлгергән Рәйсә никах күлмәге киюен сизми дә кала. «Әни бик озак: «Безнең Рәйсә парта арасыннан ук кияүгә китте», – дип сөйләде. Аңарга шулай тоелгандыр инде», – ди ул. Яңа ел бәйрәмнәре узуга, гөрләтеп туй ясыйлар. Ул еллардагы мәҗлесләрдән аларныкы, әлбәттә, аерыла: яшьләр үзләре генә түгел, барлык кунаклар да намазлы бит. Монысы нәкъ 35 ел элек булган хәлләр.

Себергә киткәнче, алар ике тапкыр әти-әни булырга, Казанның Каравай бистәсендә йорт салырга өлгерәләр. («Хәзрәтнең кулы бөтен эшне белә аның, – дип сөйли абыстай. – Туганнар булышса да, без ул өйне икәү генә диярлек салып чыктык. Таһир ул чакта экскаваторда эшли иде: бер тәүлек эшли, өч тәүлек ял итә. Өй салганда, бик җайлы булды». Үз йортларын күтәргәндә туплаган бу тәҗрибә соңрак, Сургутта мәчет салганда бик кирәк булачак әле аларга!) Себергә кузгалганчы Таһиры укый да укый.

– Мин килен булып төшкәндә, кайнатам Габделхак хәзрәт Әлмәттә имам иде. Аннан аны Оренбургка күчерделәр. Бераздан – Чистайга. Шунда эшләгәндә, Россиядә беренчеләрдән булып мәдрәсә ачты ул. 1987 нче еллар бу. Әти чакырганга түгел, үзе теләп укырга керде Чистайга Таһир. Аннан инде ике елга Төркиягә укырга китеп барды. Ярый әле бу вакытта әтиләр инде Казанга кайтканнар иде. Ике кечкенә бала белән калдым бит. Үз йортың белән яшәгәч, кыш көне кар басып китә. Мин эшли торган аптека, бәхетемә, үзебезнең урамда гына иде. Ә Камилне «хәзрәт оныгы бит ул, татарча укырга тиеш», дип, ерак булса да, бер трамвайдан икенчесенә күчә-күчә, 2 нче татар гимназиясенә йөрттем. Чыдадык инде, Аллага шөкер... Әтиләр бик булыштылар, атнага бер тапкыр Лаештан үземнең әти дә килә, сөтен, эремчеген, катык-каймагын алып килә иде. Төркиягә туры рейслар әле юк, кайтып-китеп йөри алмый, Таһир белән хат кына язышабыз, бик сирәк кенә ул минем эшкә шалтыраткалый. Андый көннәрдә даруханәдә эшләүче бөтен кызлар минем белән бергә сөенә...

Себергә дә ире башта ялгызы гына чыгып китә әле. Карап кына кайтырга... Үзенең кырыслыгын бу як табигате барып төшүгә күрсәтә. Казанда инде җылы, бөтенесе юка күлмәктән йөри, ә Сургутта Таһир хәзрәтне кыш каршылый. Костюм өстеннән кияргә кемдер үзенең курткасын салып бирә. (Май бәйрәмнәрендә монда әле кар очып торганына ияләшер өчен еллар кирәк булачак!)

Сургут мәчете – шәһәрдә туристлар күрергә тиешле күренекле урыннарның берсе дип санала.

Хәзер искә төшереп сөйләргә генә җиңел, ә ул чакта... Барысын да буш урында, юктан, нольдән башлыйсы, булдырасы, төзисе... 1993 елның 2 маенда килә хәзрәт Сургутка. Ә 16 июньдә инде ул мөселманнар оешмасын рәсми рәвештә теркәтүгә ирешә. Моның өчен 300 чакрымдагы Ханты-Манси шәһәренә барып кайтырга да өлгерә. Ә ике арада әле юлларның юк чагы, анда кадәр елга буйлап, «метеор»да гына барып була. (Бүген килүчеләрнең яңа мәхәллә ачу, аны теркәү артыннан ике-өч ай, хәтта яртышар ел йөрүенә мөфтинең аптыравы шуңа күрә аңлашыла да.)

Сургутта узасы Сабантуйга туры китереп, улы Камил белән юлга Рәйсә дә кузгала.

– Сабантуйда азан әйтергә кирәк, дигәннәр. Хәзрәт: «Камил әйтсә, матур булыр иде», – диде.



Мәчеткә гыйбадәткә йөрүчеләрнең 60–80 проценты – татарлар һәм башкортлар. Шуңа күрә Таһир хәзрәт үзенең вәгазьләрен һәрвакыт туган телебездә башлый.

PRESSA.RU

Əлфинурны авылда əнилəрдə калдырдым. Барып төштек, хəзрəт килеп каршы алды. Торган җир кунакханə инде... Юк, ошамады, билгеле, Сургут. Хəзрəт иртүк тора да, эшлəре белəн чыгып китə. Ə без Камил белəн икəү шəһəрне карап йөрибез. Гел онытмыйм – «Газпром» бинасы янына килеп чыктык шулай. Күрəм – ике-өч чəчəк үсеп утыра! «И-и, монда чəчəк тə үсə икəн!» – дип, шундый сөенгəн идем... Хəзрəт калды, без кайтып киттек. Көзгə кире килдек. Машина туры килде дə, азрак кирəк- яракны салып җибəрдек: өстəл, келəмнəр... Озакка дип килү түгел иде бит.

Күңеллəре бик киң аларның, мəчеткə нинди генə миллəт вəкиллəре йөрми!

Ноябрь аенда парк эчендəге кечкенə бер вагонны гыйбадəт йорты итеп арендага алгач, алар бөтен җиргə игъланнар ябыштырып чыгалар: «Вакытлы мəчет ачылды, намазга чакырабыз». Башта унлап кына кеше килə. Олылар, билгеле. Аннан яшьлəр тартыла. Хəзрəт дин дəреслəре алып бара. Татар һəм башкортлар өчен якшəмбе мəктəплəре ачып җибəрəлəр: укытучылары да бик тиз табыла. Берсеннəн-берсе ишетеп, шушы кечкенə генə мəчеткə халык агыла башлый...

Шул елны ук мəчет салу өчен җир алуга да ирешəлəр. Сургутның үзəгендə! «Шəһəр җитəкчелəреннəн чыгып та тормадым», – дип тыйнак кына елмая Таһир хəзрəт. Тик... ул җирдə үз өйлəре белəн яшəп ятучы 12 (!) гаилəне күчереп, башта аларга фатир бирергə кирəк була əле. Ничеклəр итеп?! Юлны күрсəтүче, киңəш бирүче табыла: əлеге агач өйлəрне



Рəйсə абыстай кызлары Əлфинур, Сара һəм оныгы Дауд белəн.

тузган торакны сүтү программасына кертүгə ирешəлəр.

Бушап калган җиргə башта кечкенə генə бина төзилəр. Яңа ел керүгə нигезен салалар һəм алты ай дигəндə «Газпром»ның бер предприятиесе (җитəкчесе – Хəмит Ясəвиев), халык ярдəме белəн аны өлгертеп тə куялар. Ул мəчет булып хезмəт итə башлый. Бүген бер гектар җирне билəгəн мəчет комплексына шулай нигез салына.

– Хəзрəт дөрес əйтə, иң авыры: халыкны уятып, кузгатып җибəрү, аларны туплау иде. Газеталарга, телевидениегə игъланнар бирдек, һəр татар концертында хəзрəт чыгыш ясарга тырышты. Барыбыз да шул эшлəр эчендə кайнадык, балалар белəн мин дə мəчеттəн кайтып кермəдем ул вакытларда. Аның кебек үк мин дə кизү тордым. Аннан Тəлгатъ, Сəгыйть, Җəгъфəр абый кебек ярдəмчелəребез табылды. Туганнар кебек яшəдек алар белəн... Мəҗлескə кая чакыралар, шунда булган бөтен кунакларның исемнəрен, телефоннарын язып кайта идем. Ураза, Корбан гаетлəренə халык килə, ə Мəүлет кебек бəйрəмнəрне белми: барысына шалтыратып, чакырып чыгам. Корбан сарыгы алырга телəүчелəрне дə алдан шулай барлый идем.

1997 елда яңа мəчеткə нигез салалар. «Акчабыз юк, əмма төзелеш материаллары күп иде, – боларын Таһир хəзрəт үзе сөйли. – Җитəкчелəре татарлар булган оешмаларның барысын йөреп чыктым. Субайлар, блоклар, бетон, арматура тупладым... Манара өлешен күтəрдек тə, туктап тордык – мөмкинлек булмады. 2000 елны шəһəр бюджетыннан безгə 55 миллион акча бүлеп бирделəр. Мəчет үзе 150 миллионга төште. Оешмалар гына түгел, халык та бик күп булышты. Манарабызда мозаикадан торган кечкенə генə бер өлеш бар иде. 2003 елны миңа мəчеттə бер кеше килеп дəште: «Мин – архитектор. Уфадан килгəн идем. Əйдəгез, манарагыздагы мозаиканы дəвам иттерик!» – диде ул миңа. Уразаев Фəһим Фоат улы белəн шулай таныштык. Ризалаштым. Əгəр алдан планлаштырсак, бу эшкə тотынмас идек, кыйммəткə төшə, дияр идек. Ə ул, булган акчага риза булып, əкрен генə эшли. Мондый манара башка юк! Эксклюзив ул!»

Əйткəнемчə, монда хəзер – тулы комплекс. Иң беренче салган бинаны инде шактый зурайтканнар, анда мəдрəсə, хəлəл кафе, кибет урнашкан. «Төзи башлаганда шушы мəчет тə җитəр кебек иде, ə хəзер сыймыйбыз. Менə бүген дə җомгага килүчелəрнең күбесе намазны урамда, карга утырып укыды», – диделəр. Гадəти җомгаларның берсе иде югыйсə... Ə бəйрəмнəрдə унар мең кеше җыела, мəчет янындагы бөтен урамнар тула икəн. Күптəн түгел икенче мəчеткə җир алганнар, димəк, тагын төзелеш эшлəренə чумачаклар.

2011 елда Таһир хəзрəт Саматовны Ханты-Манси автономияле округы татар милли-мəдəни мохтарияте рəисе итеп сайлыйлар. Мөфти хəзрəтлəренең (мин

бит әле аның 1999 елда Ханты-Манси автономияле округы мөселманнарының төбәк Диния нәзарәте мөфтие итеп билгеләнүен әйтмәдем!) динне генә түгел, телне, мәдәниятне, гореф-гадәтләрне саклау белән дә шөгыльләнгән өлкәләр башка юк диярлек. «Регион – зур, бер ягыннан икенче ягына барып җитү авыр. Ә миңа дин эшләре белән гел йөрергә туры килә, – ди ул. – Өлкәдә 30 яңа мәхәллә ачтым, имамнар китерттем. Һәрберсенә фатир алырга, хезмәт хакларын хәл итәргә дә кирәк бит. Һава шартларына түзә алмыйча, гаиләсе килергә риза-лашмаганга кире китүчеләр дә булды. Урыннардагы җитәкчеләр белән килешеп эшлибез. Барган җирдә татарлар белән очрашмый кайтканым юк. Милләттәшләр шактый бит бездә. Нефтеюганск каласында, мәсәлән, безнекеләр – 30 процент. Бер сыйныфта 70 процент татарлар укыган мәктәпләр бар. Әле менә Приобьедан йөреп кайттык. Сургуттан 800–900 чакрым ул. Китаплар алып бардык, эшләре белән таныштык».

«Хәзрәтнең регионда абруе бик зур, без аңа ышыкланып яшибез», – диләр милли-мәдәни мохтарият әгъзалары. «Газпром», «Лукойл», «Сургутнефтегаз» оешмалары, «ЮТэйр» авиакомпаниясе, өлкә, шәһәр җитәкчеләре, губернатор каршында да, башка милләт вәкилләре арасында да (мөфти өчен монысы да гаҗәеп мөһим!).

...Барысы да сөйләгәнчә шома гына бармаган, әлбәттә. Әмма алар гел бер-берсенә терәк булганнар. Берсе: «Әйдә, җыен, китәбез», – дигәндә, икенчесе туктаткан: эшли алмый кайттылар дисеннәрме, кеше күзенә ничек күренербез? Аннан, кайтулар онытылган: тизрәк мәчет салырга, кешеләрне дингә тартырга, хаҗга баручыларны тупларга кирәк (2006 елны алар бер мәр биргән махсус очкычта Сургуттан 150 кешене хаҗга үзләре алып бара)... Дәресләр үткәрү, никах, исем кушу мәҗлесләре, мәетне соңгы юлга озату (юып кәфенләү өчен мәчеттә махсус бүлмә булдырганнар)...

Бер ел да узган, ун да, инде егерме биш тә... Төркиядә, аннан Мәскәү дәүләт университетында белем алган, Лангепас шәһәре мәчетендә эшләп кайткан уллары Камил – бүген әтисенең уң кулы. «Хәзрәтебезнең яшь чагы!» – дип яраталар аны Сургут мәчетендә. Хатыны Гөлназ белән (Габделхак хәзрәтнең туган ягы – Аксубай районы Иске Ибрай авылыннан!) ике кыз үстерәләр. Себергә килгәндә 6 гына яшьлек булган Әлфинурлары да үсеп-буй җиткән – гаиләсе белән Самарада яши. Сургутка килгәч туган төпчек кыз Сара да инде мәктәп тәмамлаган.

Кызык, улы белән киленен «бер генә елга» дип Себергә озатканда, бу якларга аларның яңа сулыш өрәсен белдеме икән Габделхак хәзрәт? Ата күңеле бит ул, сизгәндер...

Гөлнур САФИУЛЛИНА.
Казан–Сургут–Казан.

■ **МӘРЬЯМ:** Без Сургутка Әлмәттән күчеп килдек. Иремнең әти-әнисе монда яши, аның үз ягына кайтасы килде. Миңа яңа җиргә ияләшү бик авыр булды. Нинди генә якын кешең булса да, берәүнең дә ишегең теләсә кайсы вакытта ачып кереп булмый. Ә мәчеткә килергә мөмкин! Һәрчак елмаеп каршы алган Рәйсә абыстайга рәхмәт... Күңелемдә берәр борчуым булса, иремә: «Әйдә, мәчеттән әйләнеп кайтыйк әле», – дим. Юлда ук җиңеләясең... Безнең арттан инде кайнанам белән кайнатам да намазга басты.

■ **ФӘНИЯ ШАКИРОВА:** Мәчетебезне җыештыручы бар, билгеле. Әмма халык күп йөри бит, шуңа күрә хатын-кыз кулы беркайчан да артык булмый. Атна саен диярлек, 12-15 кеше җыелып, өмә ясыйбыз – бөтен тузанны сөртеп чыгабыз. Бездәге чисталыкка игътибар иткәнсездер... Хәзрәтебез бик кече күңелле безнең: никадәр ашыга торган чагы булса да, туктап, хәл белешә. Җыештырырга килгән чагыбыз булса, апаларны чәйгә алып керегез ди.

■ **ӘЛФИЯ АПА:** Сургутка килгәнгә инде 30 ел. Ник кайтмыйсыз, диләр. Мәчет өчен генә булса да, монда торабыз, дип җавап бирәм. Яшәүләре күңеллеләнде! Мин беренче тапкыр эзләп барганда су аръягында бер бүлмәдә генә иде мәчет. Әле үзем дә дин юлында түгел идем. Ә хәзер җомга көнне ирем, ике улым белән киләбез намазга. Коръәннәр укытабыз, ураза вакытында бергәләп авыз ачабыз. Оныкларымның исем туйларын шушында үткәрдек. Мәчет безне берләштерде. Хәзрәтебез дорфа булса, кеше яратмаса, абыстаебыз елмаеп-көлеп каршыламаса, килер идекме?! Алар булганга мәчетләребез шулай ямьле, нурлы. Берәр сорау белән шалтыратсаң, вахтада утыручы бабайларыбыз да шулкадәр әйбәт итеп аңлаталар. Хәзрәт шулай өйрәтәдер.

■ **РӘХИЛӘ ГЫЙБАДУЛЛИНА:** Уфа университетында башкорт теле һәм әдәбияты факультетын тәмамлаган идем, 4 бала тугач, монда мәктәптә эшләргә туры килмәде. Мәчет каршындагы «якшәмбе мәктәбе»ндә башкорт теле укыттым менә. Рәхәтләнеп эшләдем! 6 яшьлек балалардан алып пенсионерларга кадәр йөрде. Иремә инсульт булды да урынга калды менә, хәзер аны карыйм. Хәзрәт белән абыстай берәүнең дә кайгысына битараф түгелләр. Рәхмәт, хәлебезне белешеп торалар, мәчеттән ярдәм итү җаен да таптылар.

■ **ФЛЕРА НАСЫЙРОВА:** Беренче дини дәресләрне Таһир хәзрәт безгә үзе бирде. Ул эш белән каядыр киткән чакларда, «аңа хәерле кешеләрне юлдаш ит» дип дога кылам. Хәзрәт юлда йөреп кайтып керсә, мәчетебезгә нур иңә. Берәүне дә кире бормыйлар: нинди киемдә килсә дә, динле булса да, диннән ерак торса да...

■ **ӘЛФИЯ АПА:** Сургутка кайдан килдем дип әйтим? 11 яшьтә ятим калган кешенең адресы Советлар Союзы инде... 1966 елны килеп урнашкан идек. Кая ул балаларны дингә өйрәтү, татарча да сөйләшмәдек – укытучылар гел ачуланып торды бит. Хәзрәт белән абыстай килеп, күзне ачты, дөрес юлга бастырды. Әтиләренә рәхмәт укыйм – ярый, аларны безгә җибәргән, бу көнне күрмәс идек.

PRESSA.RU



Фото: Рамил Якупов

ХАҖИ ТАРХАН ЯГЫНДА



Рушания
МИҢНУЛЛИНА

ӘСТЕРХАНДА ИҢ БЕРЕНЧЕ КҮЗГӘ ТАШЛАНГАН НӘРСӘ – СӘҮДӘГӘРЛӘРНЕҢ XIX ГАСЫРДА САЛЫНГАН ЭКЛЕКТИК, МОДЕРН СТИЛЕНДӘГЕ ЙОРТЛАРЫНЫҢ САКЛАНЫП КАЛУЫ. НӘКЪ ТУКСАНЫНЧЫ ЕЛЛАРДАГЫ КАЗАН ИНДЕ МЕНӘ!

Нугай далаларын, Сөембикә ханбикәбез туып-үскән җирләрне барып күрәсе килү хыялы күптән бар иде инде! Ниһаять, җай чыкты менә. Әстерханда узган Федераль Сабантуйга турылап, юлга кузгалдык. Әмма баштан ук әйтеп куям: ни кызганыч, Алтын Урданың башкаласы Сарай Батуга аяк басарга насыйп булмады. Ул җирләрне Иделдән кергән су баскан икән әле... Кәеф төшсә дә, берни эшләр хәл юк – Әстерханда карарлык җирләр күп, шуңа күрә вакытыбызны әрәм итмичә, шәһәр белән танышырга киттек.

Әстерхан шәһәре һәм Кремле XVI гасыр уртасында, Иделнең сул як ярында төзелә. Агач үсми, таш чыгарылмый торган якта төзелеш материалларын кайдан алырга? Урыс архитекторлары чишелешне тиз таба – Волгоградка таба барган юл өстендә – 150 чакрым ераклыкта кайчандыр таштан төзелгән Сарай Бату шәһәре бар бит! Нигә әле аннан ташымаска? Алтын Урда хәрабәләре барыбер берәүгә дә кирәк түгел бит. Һәм шулай эшлиләр дә...

Әле хәзер дә Әстерхан Кирмәнендә шул ташлардан 1580 елда салынган манара сакланган.

Мин үзем туристларга Казанның Иске Татар бистәсендә, Каюм Насыйри урамында урнашкан Казаковлар йортын күрсәтергә яратам. Күренекле шәхес Мулланур Вахитов шул нәселдән бит. Мөхәммәтшакир Казаков Әстерханда яши, Казанда исә чәй кибетләре тота. 1898 елда Әстерханда Ваһап хәзрәт Алиев салдыра башлаган мәчетне төзеп бетерә. Ул мәчет бүген дә әле үзенең матурлыгы, мәһабәтлеге белән күпләрдән аерылып тора – Әстерхан шәһәренең җәмигъ мәчете ролен үти.

Ак мәчет! XVII гасыр уртасында ук барлыкка килеп, 1810 елда таштан беренче гильдия сәүдәгәр Давыд Измайлов акчасына салынган бу мәчетне торгызуда, яңартуда Казан сәнәгать оешмалары, Казан хакимияте үз өлешен кертә. Намазга килгән һәр мөселман рәхмәтләрен Минтимер Шәймиевкә укый – 2008 елда Әстерханның 450 еллык юбилеена мәчет төзекләндерелсен дип, ул акчаны да кызганмады, эшчеләрне дә җибәреп торды, ди алар.


Әстерханда татарлар сан ягыннан руслардан кала икенче урында. Шәһәрдә «Тияк» дип аталган татар бистәсе дә бар. XVII гасыр уртасында барлыкка килгән бу бистә каланың аскы өлешендә урнашкан. Шәһәр башлыклары карары буенча, татарларга йортларын биек итеп төзергә ярамаган. Ни өченме? Чөнки татарларның бистәдә ни белән шөгыльләнгәннәре өстән караучыларга күренеп торырга тиеш булган.


1927 елга кадәр бистәдә 8 мәчет эшләп килгән, әмма бүгенге көнгә кадәр Яшел мәчет дип аталганы гына сакланып калган. (Совет замнында әлеге мәчет бинасында аракы складлары була. Инде ул мәчет урынына, мәхәллә кешеләре тырышлыгы белән, яңасын торгызып киләләр.) XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында Яшел мәчетнең имамы булып мөгаллим, дин белгече, мәгърифәтче, җәдитчә укыта торган Низамия мәдрәсәсен оештыручы, «Идел» журналының нәшире һәм мөхәррире, Шиһабетдин Мәрҗанинең шәкерте Габдрахман Гомәри торган. Берничә тел белгән, акыллы сүзләре белән мәхәллә кешеләрен үзенә каратып торган дин кешесе бервакыт хөкүмәткә комачаулый башлый. 1930 елда аны Архангел өлкәсенә сөргенгә җибәрәләр. 66 яшьлек Габдрахман хәзрәт сөргеннең авыр тормышын күтәрә алмый – өч ел узуга дөнья куя. Бүгенге көндә Гомәри торган йортның янкормасында аның музее эшләп килә. Бу урын – татар бистәсенең йөзек кашы дисәк тә була. Кечкенә генә шушы ике бүлмәле җыйнак йортта алар Шиһабетдин Мәрҗани белән очрашалар, уртак проблемаларын чишәләр.

Элеккеге шәһәр – Хаҗи Тархан – Иделнең уң як ярында, биектәрәк урнашкан була.

Тиздән Габдрахман хәзрәтнең 150 еллык юбилеен билгеләп үтәчәкләр. Аңа кадәр әле мәхәллә мәчетен торгызып бетерәселәре бар. Бистә урамнарына юл салырга кирәк: җай чыккан саен бу хакта югарыдагыларның исләренә төшереп торсалар да, кызганыч, әлегә үзгәрешләр күренми... Шушы эшләрнең башында ару-талуны белмәс, тынгысыз кешеләр – Гомәри музееның хезмәткәре Әсма апа Иштирәкова һәм яңа мәчетне төзүдә үзеннән күп өлеш керткән имам Марат Сәмигуллиннар тора. Алар безне Әстерхан татарларында бик популяр булган, майда пешкән итле пәрәмәч белән сыйладылар, биредәге татарлар тормышы турында сөйләделәр, киләчәккә планнары белән уртаклаштылар. Саубуллашканда: «Август аенда, лотос чәчәк атканда килегез!» – дип чакырдылар. Кем белә?!







PRESSA.RU



Ул шигъриятебездә аерым бер урын алып тора. Таң чыгы кебек саф-нәфис шигырьләре, кызлар җыры булып, йөрәкне җилкетә, яңгыр җиле булып, җаннарны сафландыра, зәңгәр эңгер булып, хыял дөньясына күчерә... Балачак, яшьлек эзләре сакланган Актаныш, Мөслим, Минзәлә яклары җылысы, шагыйрәгә генә хас илаһи хисләр, хатын-кызның тирән кичерешләре, зирәклеге, фәлсәфәсе бергә кушылып, Эльмира Шәрифуллина иҗатын укучыларына тагын да якынайта, шундук күңелдә дә уелып кала. Бу көннәрдә матур юбилеен бәйрәм итүче шагыйрәгә иҗат уңышлары, илһамлы сәгатьләр телибез!

Эльмира
ШӘРИФУЛЛИНА

ШИГЫРЬЛӘРЕМ ОЧА!..

Хыялымда кайтып килдем

Озын-озак көн булды бу –
Иртәдән төнгә кадәр.
Хыялда җәяүләп кайттым
Иделдән Сөнгә кадәр.

Сөн буйларына кайттым да
«Утырып уйлар уйладым».
Үзәкне өзгән моңымны
Җырга салдым, җырладым.

Кушылды куш каеннарым
Сагышлы хисләремә.
Күзләремә яшь төелде,
Төштең дә исләремә...

Озын-озак көн булды бу –
Иртәдән төнгә кадәр.
Хыялымда кайтып килдем
Иделдән Сөнгә кадәр.

Хат көтәм

Мин хат көттем
Күзе төсле зәңгәр күлмәк кигән,
Ерак калган
Кара егеттән...
Килмәде,
Күрәсең,
Йөрәкнең янганын
Сизмәде,
Көн саен хат язып
Ертканны күрмәде,
Юк, күрмәде...
Белмәде,
Магниттай үзенең
Тартканын
Белмәде,
Мин хат көттем...
Хат көтәм,
Күңелем һаман да бизмәде.
Сәбәпләр күп була дөньяда...
Әй, кызый,
Өметең өзмә әле!

Күрсеннәр

Миңа каян юл тоттың?
Каян сиңа юлыктым?
Кузгаттың күңелемне,
Яктырттың бүгенемне.

Син минем көткәнемдер,
Син өмет иткәнемдер.
Язган барлык җырларыма
Мөкиббән киткәнемдер.

Санаулы көннәр иде,
Сансыз күп серләр иде.
Янып көлләргә әйләнсәм,
И дошман көләр инде.

Яныйм әле, көлсеннәр,
Көлим, көлә, дисеннәр.
Яна белгән, көлә белгән
Кыз баланы күрсеннәр!

Үзе сөя, үзе кача

– Хәерле көн сиңа, Мөслим кызы!
– Хәерле көн, Бикбау егете!
Чү, туктап тор,
Ат юлыннан барма,
Буяла бит арба дегете.

(Ул туктады,
Ап-ак чалбарының
Балакларын куйды сызганып.
Җил күтәреп киткән җыр артыннан
Атладылар алга, кузгалып.)

– Хәерле юл Бикбау егетенә!
– Хәерле юл Мөслим кызына!
Мин ут ягам бүген, Мөслим кызы,
Йөрәгеңне сарган бозыңа!

Эретәмен
Һәм дә сөю тәмен
Сеңдерәмен кырыс холкыңа.
– Юк, кирәкми! Якыная күрмә!..
(Үзе сөя, үзе йолкына.)

– Хәерле кич сиңа, Мөслим кызы!
– Хәерле кич, Бикбау егете!
...Намусларны берүк тапламасын
Җәйге төннең кара «дегете»!

Шагыйрь йөрәге

Йөрәгемнән кошлар очырам...
С. Сөләйманова

Шигырьләрем – йөрәгемдә
Канат ярган кошларым.
Кайсы оча иртә язда,
Кайсы оча кышларын.
Кайсы оча җилгә каршы,
Кайсы күкләргә аша.
Кайсы сайрый былбыл булып,
Кайбере сулкылдаша.
Кайсы яши җылы җәйдә,
Кайсы кар-буран гизә:
Бәбигә тәпи китерә,
Кайсы хәвефне сизә.
...Кошлар оча йөрәгемнән,
Очырган гына беләм!
Кайгысы да, шатлыгы да
Шагыйрь йөрәген телә...

Ләис Зөлкарнәй... Студент елларында, 80 нче еллар башында ук үзенчәлекле шигырьләре белән укучылар күңелен яулаган, яңалыгы, табышлары белән соклandырган талантлы шагыйрь... Ул – мәңгелек юлчы бер җан; ул – җәяүле бер кош; ул төнге учакларга гашыйк, ярсып шигырьләр яза... Шагыйрьнең шушы халәтен «Сөембикә» укучылары да яратып кабул итәр, мөгаен.



Ләис
ЗӨЛКАРНӘЙ

МОҢ СУЛЫЙМ...

* * *

Кайчан җилеп үтте кояш? –
Утлы тузан офыкта.
Кая агып китте бу көн? –
Мин эңгердә тубыктан.

Ник йолдызлар ташлап китә? –
Төн ава җиргә сулыгып.
Сөйгәнемдәй китә көзләр –
Гөл булып җаным сулды.

Еллар ашыгып китә миннән,
Кошлардай тезем-тезем...
Юк, ялгышам, алар кала.
Мин китәм, китәм үзем!

Китәм. Гомеремне сүтеп,
Җир әйләнә җиһанда.
Мин – мәңгелек юлчы бер җан –
Гомерлеккә генә монда.

Барысын да калдырып китәм:
Җир белән калыр язлар,
Минем артта кояш калыр,
Тезелеп калыр йолдызлар...

* * *

Сине сөю – миңа хәрам.
Яратмау да хәрамдыр.
Өндә синнән
Өнсез китсәм,
Төштә йөгреп барамдыр.

Сине сөймәү – гөнаһ, гөнаһ...
Ярату да гөнаһтыр.
Яратуымнан
Башка да
Ятагында төн актыр...

Сөюләрем савапмы соң?
Сөймәү сиңа саваптыр.
Санлап торма мин сансызны,
Саксызлыктан саклап тор.

Яратуым сине – гөнаһ.
Яратмау да гөнаһтыр.
Шул ярату өчен генә
Төнем кара...
Көн актыр.

* * *

Төнге учакларга гашыйк идем.
Шуңа учак яктым – дөрләсен!
Ә син хәвефләнеп кабатладың:
«Чәчрәп китеп, очкын тимәсен...»

Очкын миңа түгел, сиңа тигән.
Ах, аны мин нигә күрмәдем! –
Бер караусыз төнге учак сыман,
Янәшәмдә янган йөрәгең...

Төнге учаклардан очкын калган.
Янсын иде алар тагын да...
Йолдыз-очкын оча сискәндереп,
Гөлтләп хәтер генә кабына...

* * *

Мин кагам ишегеңне,
Дөп-дөп кага бәгырь дә.
Тәрәзәң ачык калган,
Кул изәп калган пәрдә.

Сагынып килгән идем,
Моң басты күзләремне.
Тәрәз аша ташладым
Кулдагы гөлләремне.

Кайтып керерсең дә син,
Моңсу булыр сиңа да.
Гөлне суга куярсың,
Инде сулган булса да.

* * *

Син эзләмә китапханәләрдән.
Анда юк ул. Миндә. Кил, табын.
Сиңа бөек шагыйрь булсам да мин,
Юк «Мәхәббәт» дигән китабым.

Зур томнарга сыймый минем сөю,
Язганым юк, укыйм үземнән.
Кил җаныма, сөю шигыремне
Төннәр буе укы күземнән.

Шулай шул

Моңсулыйм.
Моңсулыйм.
Суласам,
Моң сулыйм.

Ямансу.
Ямансу.
Эчкәнем –
Яман су.

Юксынам.
Юксынам.
Юк-сы-нам –
Юк, сынам!

Шулай шул.
Шулай шул.
Тәрәзәдә
Шул ай шул.

PRESSA.RU



Ландыш ӘБҮДӘРОВА

КУНАК МАЛАЙ

(Хикәя)

– Кызым-кызым, тор, тор!
Җеннәр оча пыр-пыр.
Әллә пәри, әллә җен,
Бисмилланы әйтеп тор!

Әбекәйнең шаян такмагын ятлап бетердем инде. Ул мине көн саен шулай такмаклап уята. Үзе таң белән уяна. Уянгач, беренче эш итеп, минем өстәге юрганны рәтли, аннан юына, алдына ак яулык җәеп, чәчен тарап үрә. Юкарып беткән чал чәчен баш артына төйнәп, кәкре тарак кадап куйгач, яулыгын кысып бәйли дә үзе турында онытa. Иң элек самавыр кайната, ипине кисеп куя, өстәлгә җиләк яки чия кайнатмасы чыгарып куя, үтә күренмәле бизәкле савытка җимеш салына, суыткычтан каймак ала. Әбекәй шыпырт кына йөрсә дә, әни белән әти дә уяналар. Мин бу тавышларга колак салып ятам да кабат йокыга талам.

Менә әбекәй бүген дә такмагын көйли-көйли уятты. Үзе: «Бүген йоклап кына ята торган көн, урамда салкын җил исә, яңгыр ява, кара көзгә кереп барабыз», – дип сөйләнә. Аның сүзен җөпләгәндәй, тәрәзә артында җил шапылдап куя. Абау, уйнарга да чыгып булмас инде бүген. Мин сикереп торып, тәрәзәгә капланам. Айсылуны да чыгармаслар инде.

– Әбекәй, ә, әбекәй, кара әле...

– Нәрсә булды? – ди әбекәй чаршау артыннан.

– Кәбир муллалар турында нинди машина тора ул? – дим, чия кызыл төстәге машинага ымлап. Безнең авылга мондый машиналар сирәк килә.

– Кая? – Әбекәй дә тәрәзәгә үрелә. – Бер дә күренгән машина түгел, Кәбир мулла да кунак көтәм димәгән иде.

Шулчак муллаларның ишегендә бөдрә чәчле бер апа күренде. Аның янына озын буйлы абый чыгып басты. Кәбир мулла белән Гөлйөзем абыстай да шунда. Шул арада бер бәләкәй генә бөдрә башлы кара малай пәйда булды.

– Ә-ә, урыс кияве белән Фәүзия кайткан инде алайса. Малайлары бар дигәннәр иде, шушындый зур микәнни?.. Әйдә, төш тәрәзә төбеннән, күреп калмасыннар тагын, күзәтеп яталар, диярләр, – дип, әби мине тәрәзә яныннан куалый башлады. Төште, ди! Монда шундый кызыклар була торып, күздән ычкындыралар димени? Урыс кияү... Кара, урыс та безнең авыл кешеләре кебек икән бит. Малайлары да нәкъ минем шикелле, буе белән дә, төсе белән дә нәкъ безгә охшаган.

Капканың бу ягына чыккач, теге Урыс кияү Кәбир муллага кул биреп, Гөлйөзем абыстайга баш кагып, саубуллашып машинасына кереп утырды. Матур киенгән апа икесен дә кочаклады, аннан соң теге бөдрә чәчле малайны кысып кочаклап, ике битеннән кат-кат үпте. Шуннан соң алар китеп бардылар. Малай кул изәп калды. Тегеләр кузгалуга, абыстай малайны шәленә төрмәкче булган иде, ул ялт кына әбисенең кочагыннан чыгып, бабасын җитәкләп алды.

– Әбекәй, болар малайларын калдырып киттеләр, уйнарга чыгар инде безнең белән, име?

Безнең авылда русча сөйләшү гөнаһ санала иде. Саналмый ни, әбиләр тәрбиясендә үс тә, авыз тутырып көфер сүз әйтеп кара син!

Тәрәзә төбендә радио торса да, ул ахыр заман «яшниге»н татарча сөйләгән вакытта гына кабыза иде безнең авыл әбиләре, шулай итеп телне күз карасы кебек саклый иде. Кичләрен безгә «Сак-Сок» бәетен көйли, «Әлхәм» белән «Колһу алла»ны кабатлата, йокларга ятар алдыннан төнлә битне шайтан яламасын дип, мич авызындагы комганнан җылы су алып, битләрне юдырта. Минеке генә түгел, Айсылу белән Гөлназның әбекәе дә шулай итә. «Әни» сүзенең русчасы «мама» икәнен белсәк тә, кычкырып әйтмибез: тьфүтьфү, йә авыз пычраныр?! Әбекәйләр безгә шәһәр малайлары белән дә дуслашмаска куша. Юк, әлбәттә, уйнамыйбыз – бөтен әшәкелек шәһәрдән кайта икән. Алма апа да шунда китеп кенә «бозылды», ди әбекәй. Ничек бозылганын әйтә алмыйм анысы, әмма тырнагын кызылга буяп кайткач, әбекәй бик каты ачуланды үзен. Юып кына бетми икән әле ул – Алма апа кыракыра юды. Үпкәләмәде дә, каршы сүз дә әйтмәде, хәтта ки ирен читендә елмаю да бар кебек иде. Миңа матур кебек тоелган иде аның кып-кызыл тырнаклары, әбекәй әйткәч, ярамый торган эштер инде.

– Әбекәй, бу малай шәһәрдән кайтканмы соң?

– Фәүзия башкалада яши, диләр иде. Шәһәрдәндер инде, бала, – дип, әбекәй алдыма йомырка тәбәсе китереп куя. Минем күз алдыннан китми генә бит теге малай. Эх, бүген үк уйнарга чыгып булмас микәнни инде? Көне дә ямьсез бит, ичмасам, яңгыр ява.

– Әбекәй, ә безгә аның белән уйнарга ярыймы соң? – дим мин, аның шәһәрне бер дә өнәмәвен белгәнгә.

Әбекәй җитдиләнә төшә:

– Балалар бергә уйный инде, – ди ул сузып кына, эшеннән аерылмыйча. Чәемне чөмереп кенә эчеп бетерәм дә «Аллаһ әкбәр» дип, бит сыпыра-сыпыра, янә тәрәзәгә капланам. Тик урамда эт тә йөрми, салкын җилле яңгыр гына ява. Мин теләр-теләмәс кенә, нишләргә белмәгәннән Алма ападан калган мәктәп букчасыннан кәгазь-каләмнәремне алып, рәсем ясарга утырам.

Бүген тәки уйнарга чыгып булмас инде. Ә минем шундый зур яңалыгым бар – күршегә бер кунак малае кайтты! Тизрәк шуны Айсылуга әйтәсе килә. Аннан икәү бергә Гөлназларга китәр идек. Безнең өчебез арасында Гөлназ өлкәнрәге. Ул бездән бер башка зуррак та. Айсылу белән икәү генә булганда, без бер-беребезне тыңлыйбыз, Гөлназ чыкса, берсүзсез аңа ияребез, чөнки ул бездән күбрәк белә. Аның әбисе дә укымышлы кеше. Суфый әби, диләр аны безнең авылда. Кушаматмы, исемме бу – күптән онытылган инде. Аның бу дөньяда белмәгән нәрсәсе юк бугай, бөтен кешене өйрәтә. «Китап шулай куша», дип кенә бетерә ул сүзен. Шуннан соң каршы килеп кара син аңа. «Бу фани дөньяның чите ә-әнә тегендә, оланнар, – ди ул таягы белән офыкка таба төртеп күрсәтеп. – Ә бакый дөньяның чиге юк. Ахирәттә бер генә нәрсәнең дә – рәхәтнең дә, газапның да чиге юк». Ахирәт дигәннәре турында ул безгә каз бәбкәләрен саклаганда сөйли. Ә безнең офык артында ниләр барын күрәсе килә. Суфый әби безне орыша, «шайтан коткысы», дип төкеренә. Без шайтан турында сорашабыз. Гел котыртып йөри торган булгач, шуктыр инде ул, кап-карадыр инде, ямьсездер. Ләкин тагын Суфый әби ачуланыр дип дәшмибез. Соңрак Гөлназдан сорарбыз әле. Гөлназга әбисе әйткәләр әле. Гөлназ барыбер берәр җавабын таба ул. «Шайтан күргәнең бармы?» дигәч тә: «Әби бер көнне генә куып җибәрде әле, бүтән килмәс инде, курка», – диде. Бу урыс малае турында да Гөлназга әйтмичә булмас. Ул нәрсә дияр бит әле?

Иртәгәне көтә-көтә кич тә җитте. Әти белән әни күптән инде эштән кайтып, маллар карап керделәр. Әни, яккан мичкә салып киптерергә дип, алма турап йөри иде. Шулчак капка ачылган тавыш ишетелде, бераздан ишек тә кактылар. Әбекәй җитез генә ишеккә китте.

– Әйдүк, әйдүк, Гөлйөзем, иминме? Бәрәкалла, кунагың да бар икән әле, – дип, көзге салкынча һаваны ияртеп, гөрли-гөрли килеп тә керде алар. Өлкәннәр кыймылдаганчы, артларыннан тагын теге кара малай тәгәрәп килеп чыкты.

– Әлхәмделлилаһ, Нурия. Үзегездә исәнлекме? Менә, Фәүзия бүген малаен кайтарып китте кияү белән. Әнкәй, Мишаны Сахалинга җибәрәләр, мине дә үзе белән ала, барып урнашканчы, баланы сездә калдырып торыйк әле, ди. Кызым сорагач, каршы килмәдек инде, алып калдык. Кышка каршы бит… Көндез әйбәт кенә торган иде, кичкә таба күңелсезләнә башлады. Сагына балакай. Шуңа – бераз юанып торыр дип алып кердем инде…

– Бик дөрес эшләгәнсең, шулай-шулай, абыстай, – дип, әбекәй аларны түргә әйдәде. – Ни атлы соң үзе?

– Жинә. И-и, Нуриякәем, бер авыз безнеңчә белми, мин урысчасын аңлата алмыйм. Ничекләр аңлашырбыз?! Ярый әле, Кәбир бераз сукалый. Сезнең Зәйнәп белән дуслашып китмәсләрме, диюем иде.

Мин теге малай бу якка аяк басуга – шылдырт эчке бүлмәгә. Ишек чаршавы артыннан гына күзәтәм: менә нинди була икән ул урыс малае! Татарча да белми икән әле үзе. Абау, чәче! Нишләп алдында кәҗәкәй калдырып кистермиләр икән аны, бөдрә чәчен кызларныкы кебек үстергәннәр. Ул арада Женя бу өйдә үз ише барлыгын абайлап алырга өлгерде, минем качып карап торганны да сизгән, ахрысы. Чишен, утыр, дигәнне дә

PRESSA.RU

көтмичә, өстен салып, ишек катындагы караватка атты да туп-туры миңа таба килә башлады. Мин исә елгыр гына караватка өеп куйган мендәрләр артына чумдым.

Гөлйөзем абыстай шук малаен:

– Жинә, улым, иди сюда, кил, – дип чакырып караса да, тегесе ишетмәде дә бугай, көлә-көлә эчке бүлмәгә килеп керде.

– А-ха, попалась, – дип, мәче җитезлеге белән минем янга сикереп тә менде.

– Кит, кит, урыс, – дип чинап җибәрдем куркуымнан. Һәм гарьлегемнән елый ук башладым. Ул арада Гөлйөзем абыстай белән әбекәй килеп керделәр, аш бүлмәсеннән әни атылып чыкты. Абыстай малайның кулыннан әләктереп тарта, тегесе карыша, үзе әллә нинди урыс сүзләре белән мине үрти. Әбекәй мине караваттан күтәреп алды да, артына яшерә башлады. Мин инде гарьлегемнән әбекәйнең итәк-чабуына урала-урала, үксеп елый идем. Ярый әле әти белән әни Женяны русчалатып үгетләп алып чыгып китә алдылар. Ул кичне мин әбекәйнең тезеннән төшмәдем, әбекәй дә кич буе әле аркамнан, әле чәчемнән сыйпап кына утырды. Тегеләр чыгып киткәч, җиңел сулап, Женяны орышып алды:

– Орчык кебек кенә үзе, ә минем кызымның котын алды, юньсез малай! Тьфү!

Орчык дигәннән, ул кичне Женя әбекәйнең бер орчыгын сындырды, бәйләменнән энәләрен тартып чыгарды, сәгатьнең күкесенә алма чүбе атты. Чылбырына үрелеп маташа иде, ярый әле абыстай күреп калды...

Икенче көнне яңгыр туктаганга сөенә-сөенә Айсылуларга элдерттем. Кичәге хәлләрне сөйләп бирдем. Аннары Айсылу белән Гөлназларга чаптык. Яңа хәбәрне аңа да сөйләргә кирәк бит инде.

– Күрдем инде мин ул урыс малаен. Әби әйтә, нәкъ шайтанның үзе, ди. Без таң белән үк Кәбир муллаларга менеп төштек инде. Йомыш бар иде. – Гөлназ бездән өлгеррәк булып чыкты.

– Кичә Зәйнәпләргә кунакка кергәннәр алар, – ди Айсылу. Аның да тизрәк Женяны күрәсе килә иде. Озак уйлап тормадык, Кәбир муллаларга таба киттек. Женяны уйнарга чыгарсалар, күрми калмыйк тагын.

Безне генә көткән кебек, килеп җитүгә атылып чыкты бу шайтан кебек кара малай. Авызы ерык. Аның каравы, без бик җитди. Каш астыннан гына карап, өчебез бер сафта басып торабыз, күз йомарга да куркыта – берәр яры ычкынмасын тагын. Гөлназ бик батыр, Айсылу белән икәү генә булсак, күптән табан ялтырата идек инде. Аның батырлыгы безгә кыюлык бирә. Шулай күпме басып торганбыздыр, Женя үзе сүз башлады:

– Я Женя! А вас как зовут?

Айсылу белән минем дәшәсе юк инде, Гөлназдан җавап көтәбез. Ә ул тагын бер мизгел тын гына басып торды да бармагы белән Женяга төртеп күрсәтеп:

– Ааааа, пычрак авыз, пычрак авыз, тешләре черек, – дип кычкырып көлә башлады. Кара, Женяның чыннан да алдагы сөт тешләре каралып тора икән. Безгә исә шул гына кирәк, Гөлназга ияреп:

– Пычрак авыз, пычрак авыз, кяфер, – дип такмаклый-такмаклый, төртеп күрсәтә-күрсәтә, йөгереп качтык.

Үзебез йөгерәбез, үзебез ап-ак, тип-тигез булып тезелеп киткән тешләребезне күрсәтеп көлешәбез. Гөлназныкы бигрәк энҗе кебек тезелеп тора. Сипкелле битендә аның ак тешләре бигрәк тә ачык күренә. Шулчак капка артыннан Кәбир мулла йөгереп чыкты. Ул «Аһ, сез, гөнаһ шомлыклары, бирермен мин сезгә кяферне!» – дип, куарга керешә. Бездә инде көлү түгел, исән-сау котылу кайгысы гына калды, чөнки Кәбир мулланың болай да бала-чаганы куркытырга яратканлыгын яхшы беләбез. Куркытуын куркыта, ә менә берәүне дә тота алганы юк әле.

Ул кичне әни миңа «кешедән көләргә ярамый, бу әдәпсезлек була, тәрбияле-тәртипле балалар алай эшләми», дип үгет-нәсыйхәт бирде, әбекәй җайлы гына «тәкәбберлек өчен кыямәт көндә җавап бирәсе була», дип, Алла бабай белән куркытты. Мин инде үткән көнне кире кайтарып булса, мәңгегә дә алай эшләмәс идем, дигән тирән үкенү хисе белән вәсвәсәле уйларга бирелеп, йокыга талганымны гына хәтерлим.

Нишләргә инде: Женя миңа күрше генә тора бит әле. Аның минем белән уйныйсы килә, әти белән әни дә, әбекәй дә кыерсытмаска кушалар. Гөлназ дуслашмаска куша. Кяферлеге йогар, дип куркыта. Ул ничек йогадыр, әмма Женя татарча сүзләр әйткәли башлагач, эчкә җылы керде. Мин дә хәзер кайбер сүзләрнең русчасын беләм. Әбекәйгә генә әйтмим белгәнемне. Гөлназга да. Айсылуның да Женя белән дуслашасы килә: бергә күңеллерәк бит, ләкин Гөлназдан курка. Женяның әллә нинди уенчыклары, җебеннән тарткач, аяк-кулларын селкетә торган клоуннары, «мама» дип кычкыра торган йомшак аюы, матур рәсемле китаплары күп. Мин алар турында сөйлим дә, Айсылу кызыга, Гөлназ гына үз сүзендә нык тора: шайтан ялтыравык белән котырта, ди. Суфый әбинең сүзләрен кабатлый инде, үзенең дә уйнап карыйсы киләдер әле.

Женя безнең авылга тиз ияләште. Татар телен дә кай арада отып алды! Әниләре тегендә барып урнашканчы гына калдырабыз, дип китсәләр дә, яз җитте, җәй килде – кайтып алмадылар әле Женяны. Җәй җитүгә без урамнан кайтып кермибез. Женяны сызыклы уйнарга өйрәттек. Бу вакытта безгә Айсылу да кушылган иде. Әмма ул кайчак Гөлназ йогынтысыннан чыгып бетә алмый. Май ахырларына исә, каз бәбкәләре сакларга дип, яланга күчәбез. Бу вакытта без котылгысыз рәвештә Суфый әби ятьмәсенә эләгәбез. Уңга-сулга бер адым да атлый алмыйбыз: Суфый әбинең җыерчыкланып килгән йөзендәге чепи күзләре барысын да күреп тора. Тик менә Женяны башта ук сөймәде ул. «Теге нәрсә» дип кенә җибәрә, исемен хәтерләп калуны кирәк дип санамады да. Женяның самокаты бар иде. Менә шул самокат Суфый әби өчен соңгы тамчы булды да инде.



Рәсем: Наталья Васильева

Хуш, көннәрдән бер көнне Суфый әби ата казын, ана казын, оясы белән бәбкәләрен, оныклары Гөлназ белән Илнурны, бәбкәләргә ашатырга дигән җимне алып, төшеп кенә утырган иде. Нәкъ шулчак Женя бахыр үз бәхетсезлегенә каршы, самокаты белән җилдереп килеп төшмәсенме яланга. Ата казы кеше төсле генәме?
Иң беренче ул курыкты, метр ярымлы канатларын кага-кага бөтен яланга сөрән салды. Аңа безнең ата каз кушылды, Айсылуларныкы. Казлар каңгылдашкан тавыш бөтен яланны тутырды, без, бала-чага, каз бәбкәләре аналарының канаты астына кереп тулган кебек, Суфый әбигә елыштык. Суфый әби исә безгә бер генә ысылдады: «Тотыгыз!» Гөлназның күзләрендәге нәфрәт Айсылуга да күчте, ул курку катыш нәфрәтле күзләрен Женяга төбәде. Гөлназның энесе Илнур инде Женяга таба чаба иде, Гөлназ – аның артыннан. Менә-менә Айсылу шул якка ычкынырга тора. Мин, хәзер ни булыр инде, дип, тор採таштай куркып калдым. Хәтта еларга да куркам. Бер якта тузгыган каз көтүе, икенче якта коты алынган Женя. Шул вакытта Суфый әбинең ниятен чамалап алам. Әстәгъфирулла, тәүбә, хәзер безне куркытуның иң үтемле чарасы чынга ашарга тора. Тыңламасаң, шукланып йөрсәң, безне башта сыек чыбык белән куркыталар, ул да үтмәсә, ыштан төбенә кычыткан салам, диләр иде. Ыштан төбенә салынган кычытканның ничек көйдерәсен бераз чамалыйбыз: кулны гына чакса да, җан әрни. Ә монда!!! Ләкин моңарчы эшнең аңа кадәр барып җиткәне юк иде әле, безнең авыл тарихында җәзаның бу ысулы кулланылган очракларны гел хәтерләмим. Ә менә хәзер!

Икенче мизгелдә Женя Гөлназ белән Суфый әби кулында иде. Өченчесендә Суфый әби кулындагы кычыткан Женяның ыштан төбендә юк булды...

Бу хәлдән соң Женя авылда озак тормады, аны кайтып алдылар. Бу турыда Женя әбисе белән бабасына сөйләде микән, юк микән – белмим, һәрхәлдә, Гөлйөзем абыстай да, Кәбир мулла да ләм-мим бер сүз ишеттермәделәр. Әллә безгә генә ишетелмәгәнме? Миңа да әни дә, әбекәй дә бер сүз әйтмәде. Ичмасам, әйтсәләр! Нишләп дустыгызны кыерсыттыгыз, нишләп якламадыгыз, дип сүксәләр?! Менә шулай, үкенеч белән үзем генә калдым мин. Женяның арт саны янгандыр, ә минем җан әрни. Ичмасам, миңа да салса шунда Суфый әби. Берничә көн Кәбир муллалар турыннан үтәргә куркып йөрдем әле. Абый-апалар кечерәкләрне иске тунны кирегә әйләндереп киеп, дию пәрие яки папай булып кереп куркытканда, иң мөһиме – тоттырмау. Тота калсалар да, берни эшләтмәсләр иде бит инде, ә без чырыйлап кычкыра-кычкыра елыйбыз. Кәбир мулла да тотып нишләтер иде икән инде? Ләкин барыбер куркыта. Бу юлы тагын да дәһшәтлерәк итеп куркытыр иде, чөнки миңа аның хакы, минем гаебем бар кебек тоела.

Женя исә башка безнең күзгә күренмәде. Әллә гарьләнде, әллә үпкәләде шунда. Иртән торсам да, кич ят-

PRESSA.RU

сам да, әбекәй белән икәү йоклый торган караваt турысындагы тәрәзәгә үреләм. Бу гадәтем Женя кайткач ук башланган иде. Өйдәгеләр күнектеләр инде. Тик менә бу көннәрдә ешрак күз салам. Тәрәзә аша ул яшәгән өй каршыннан чебен үткәрмәсәм дә, саубуллаша да алмый калдык. Әллә кай арада гына кайтып алып киттеләр аны. Мин өйдә бит инде, киткәндә саубуллашырга керсә дә булыр иде... Үпкәләгән, димәк.

Еллар үтте. Бу хәл дә, Женя үзе дә онытылды инде. Гөлназ, Айсылу, мин – 12-13 яшьлек кызлар булып өлгердек. Борынга да ис керә башлаган чак. Безгә клубка киногa чыгарга рөхсәт бирә башладылар. Киномеханик Әхтәм абыйның кара афиша тактасына акбур белән түгәрәкләп «Индийский» дигән язуын күрүгә, безне бәхет баса – бүген клубка чыгабыз. Йөгереп кайтып, кадерләп кенә яшереп саклый торган тартмадан 20 тиенне санап алып куябыз, беләзек яки башка берәр бизәнгечне барлыйбыз, бәлки әле әнинең сирень исле хушбуен сибәргә дә насыйп булыр...

Һай, ул һинд кинолары! Гөлназ, Айсылу һәм мин – тәмам һинд киноларының фанатларына әйләндек. Бер үк төрле кино ун тапкыр килсә, унысын да карыйбыз. Иң алгы рәткә утырып. Тын да алмыйча, елыйелый. «Җәми-Җәми-Җәми, ача-ача-ача...» – безнең авызда шушы җыр гына. Алма апа почтадан яздырып, Мәскәүдән миңа һинд киносы артистларының аклыкаралы фотоларын кайтартты. Менә, ичмасам, байлык иде ул минем өчен! Шри Деви, Шаши Капур, Амир Хан, Амитабх Баччан, Рекха, Мандакини, ә иң чибәре, иң кадерлесе – Митхун Чакраборти! «Мин Митхунга охшаган егеткә генә кияүгә чыгачакмын!» – дип, берберебезгә сүзләр биреп бетердек. «Их, Һиндстанга барырга, андагы гүзәллекне үз күзләрең белән күрергә иде!» – дип хыялланабыз. Нинди ефәк, өрфия кебек яулык яки чүпрәк, әниләрнең кирәкмәгән сәйләннәрен, алкаларын тапсак, шуны яшерен тартмага җыя барабыз. Берзаман Айсылуларга икетуган абыйсы һинд киноларыннан җырлар яздырылган кассета алып кайтты. Юләрләндек шуны тыңлап. Биибез, бертуктаусыз һинд биюе биибез. Тора-бара безгә тамашачы кирәк була башлады, клубта концерт куярга булдык. Репетициягә дип җыелабыз да башка номерларны аннан-моннан гына әзерләп, төп номерга күчәбез. Тегеләй итеп тә биеп карыйбыз, болай итеп тә. Ул кадәр әйләндерүгә, магнитофон түзмәде – теге кассетаны чәйни башлады. Аны күз карасы кебек кенә саклап тотабыз. Концерт көнен билгеләдек. Түземсезләнеп, дулкынланып шуны көтәбез. Әйтерсең лә, нәкъ шушы концерт безнең бөтен тормышны, язмышны үзгәртәчәк! Ул көтүнең рәхәт, татлы мизгелләре соң?! Концерттан соң нишләрбез – анысын уйлаган юк, әлбәттә. Мөгаен, йолдызлар булып уянырбыз инде.

Клуб мөдире булган апа каршы килми тагын – репетицияләргә дә рөхсәт бирә, концерт куярга да. Үзе дә булыша. Ләкин менә һинд биюен генә өйрәтә алмый – белмим ди. Үзегезнеке әйбәт чыга, дип куандыра. Гәүдәләрегез килешеп тора, дигән була. Көне килеп җиткәч, белдерү язып элде, клуб иданен юып, урындыкларны тезеп куйды. Печәннән соң, дип тормаган халык – клуб шыгрым тулы. Пәрдә артыннан гына күзәтәбез. Безнең һинд биюен бииячәгебезне бөтен авыл белә иде инде, нәкъ шул номерны карарга җыелдылар. «Теге биюегезне дә биерсезме соң?» – дип аптыратып бетерделәр.

Кем нәрсә эшли ала: кайсы җырлый, кайсы татар биюе бии, кайсы шигырь сөйли, скетчлар да куйган булдык. Иң соңыннан төп номер – һинд биюе! Аны игълан итәр өчен алып баручы Зөһрә апа үзе дә маңгаена кызыл төртеп чыкты. Магнитофон янына Гөлназның энесе Илнурны бастырдык – андый-мондый магнитофон кассетаны чәйни башласа, ул тиз генә туктатып, әйләндереп җибәрергә тиеш булачак иде.

Ниһаять киендек. Мин кызыл төстәгесен кидем, Гөлназ каяндыр зәңгәрсу төстәге ялтыравык ыштан тапкан, өстен дә килештергән, Айсылуга әнисе яшелдән тегеп бирде. Нинди сәйлән таптык – шуларны асып чыктык. Өчебез бер-бер артлы басып торабыз. Иң алда – Гөлназ, мин – аның артында, Айсылу – минем арттан. Зал шым булды. Чебен очкан тавыш та ишетелми. Илнурның магнитофон төймәсенә баскан тавышына кадәр ишетелде хәтта. Китте бит музыка. Биибез, юк, очабыз гына – әйләнәбез, бөтереләбез, зал безгә кул чаба, артта малайлар сызгыра, аяк белән дөбердәтә! Менә безнең йолдызлы сәгать! Без елмаябыз, тик кассета гына тыңласын, магнитофон берүк кенә чәйни күрмәсен! Инде яртысын биедек, тигез генә чыга кебек инде үзебезчә. Нәкъ шул вакыт клуб ишеге ачылып китте. Кем инде мондый вакытта бүлдереп йөри дигән кебек, залдагылар, канәгатьсезлек белдереп, дәррәү ишеккә борылды. Безгә дә аермачык булып күренә ишектәге кеше. Ә анда... ап-ак, тип-тигез тешләрен күрсәтеп, киң елмаеп Митхун басып тора! Кит инде, булмас, төштер бу!.. Шул мизгелдә магнитофон тасмасындагы җыр акрыная, «Җәми» дип ачыргаланып җырлаган кызның тавышы калыная. Чукынды инде болай булгач – чәйни! Без шып итеп туктап калдык. Илнур тиз генә магнитофонны туктатып, кассетаны рәтләп, янә җырлатырга куеп җибәрә, әмма безнең беребез дә селкенми – безнең күзләр Митхунда, әй лә, Женя бит ул! Кайткан бит, кайткан Женя! Әнә каршыда – хыялның тере гәүдәләнеше булып басып тора. Күңелдән әллә ничә потлы ташны алып ыргыттылармыни – күңелгә җылы йөгерде, әллә ничә еллык үкенеч хисе, сөртеп алгандай, юкка чыкты.

Билгеле, шушы мизгелдә без аңа өчебез дә үлеп гашыйк булдык. Ләкин бу вакытта әле беребез дә Женяның кайсыбызны сайлаячагын белми идек. Шулай ук аннан русча иркенләп сөйләшә белмәвебез өчен оялып йөриячәгебезне дә белми идек. Җәй ахырына таба Женяның Гөлназны сайлаячагын да, аларның бездән кача-поса очрашып йөриячәген дә белми идек әле...

ТОРМЫШ УЛ – КИЧӘ БЕЛӘН ИРТӘГӘ АРАСЫНДАГЫ БЕР МИЗГЕЛ ГЕНӘ... КҮЗ АЧЫП ЙОМАРГА ДА ӨЛГЕРМӘДЕМ: ҮТКӘН ДӘ КИТКӘН...

РӘШӘ...



Ризидә
ГАСЫЙМОВА

Коръән ашында утырабыз. Абыстай яхшылап, җиренә җиткереп Коръән укыганнан соң, без, туган-тумача, бер-беребезне барлый башладык. Җиңгәм ягыннан гел күз күрмәгән кешеләр дә килгән икән. Сөйләшеп киткәч, ачыкланды – болар безнең мәрхүмә әби белән бер авылдан, Баландыштан.

И-и, бу авыл бик таныш. Әби үзе исән чакта барган булды! Бүгенгедәй хәтеремдә – әти 40-45 чакрым араны бишекле матай белән келтер-келтер генә китереп илтеп куйган иде. Әбигә туган тиешле Мөхлисә апаларга тукталдык. Ул чагында телефоннар юк, әйтми-кисәтми, көтмәгәндә килеп кергәнбездер инде. Шуңа карамастан, алар безне ачык чырай белән каршы алганнар, бик әйбәтләп кунак иткәннәр иде. Ничәнче кундык икән? Ике-өч кич булгандыр шулай да. Киленнәренең иртән урын-җир җыештырып йөргәне, ап-ак тышлы чиккән мендәрләрне кабартып-кабартып зәңгәр бизәкле сандык өстенә өеп куйганы бүгенгедәй күз алдымда... Авыл хатыннарына – безнең әниләргә бер дә охшамаган иде ул нишләптер: озын зифа буйлы, чәчләрен матур итеп баш өстенә өйгән, халат түгел, караңгырак төстәге бик килешле күлмәк кигән, биленә ак алъяпкыч бәйләп куйган. Аермачык булып истә калганы менә шул килен дә, әби белән дога укып, зират тирәсендә теркелдәп йөрүем истә калган...

Яңа танышыма шул матур хатирәләрне сөйләп утырам. Башына ак яулыгын әбиләрчә таратып япкан олы яшьләрдәге бу апакай мине көлемсерәп кенә тыңлап утырды-утырды да әйтеп куйды:



– Мөхлисә апаның үлгәненә инде...

– Беләм, – дидем мин, – ашап утырган җиреннән кисәк кенә үлеп киткән. Ничек соң малае белән килене?

– Малае да үлде инде. Фаҗигале үлем белән үлде. Бер иптәше белән эчеп утырганда ачуланышып киткәннәр. Аннары инде... сөйлисе дә килми... Иптәше Мөхлисә апаның малаена пычак белән... Аннары үзе дә асылынып үлгән.

– И Ходаем! – дидем мин, ишеткәннәремнән өнсез калып. – Мөхлисә апаның килене үзе генә калдымыни?

– Сәлимәне әйтәсеңме? Ул да бит бер биш еллар чамасы элек үлеп китте!

– Ничек... үлде? – дип сорадым әле кайчан гына мендәрләр күпертеп йөргән матур киленнең үлгәненә ышанасы килмичә.

– Авырып...

– Ничә яшьтә иде соң ул?

– 65 ләрдә булды микән... Шул тирә инде...

– 65 ләрдә?

Тукта, без икебез бер кеше турында сөйлибез микән соң? Төз гәүдәле матур киленнең 65 кә җитеп, инде биш ел элек үлеп китүенә минем бер дә ышанасым килмәде...

Санап карарга әллә? Миңа ул чакта 6 яшьләр чамасы булгандыр. Ә киленгә 30 лар дип алыйк. Димәк, ул миннән чама белән 24 яшькә генә өлкәнрәк булган. Миңа хәзер ничә яшь соң әле? 48 ме? Тукта, урыс әйтмешли, черт побери – миңа да 48 яшь икән бит инде! Ә 48 гә 24 не кушкач...

Дөресен әйтим, тетрәнеп киттем мин 48 гә 24 не кушкач. Күңелне кинәт иксез-чиксез моң биләде. 42 ел элек миңа ят та, якын да булган шул авылда дога укып, зират тирәли әйләнеп йөргәнем еллар томаны аша тагын күз алдыма килде. Әби миңа ул чагында мең «Кольһуалла» укырга кушкан, мең «Кольһуалла» бер Коръәнне алыштыра ул, кызым, дигән иде. Укый алдым микән мин үз гомеремдә шул мең «Кольһуалла»ны? Ул чаклардан соң күпме сулар аккан, күпме кеше килгән, күпме кеше киткән... Ә без тормыш мәшакатьләре белән өч көнлек дөньяда яшәвебезне әле һаман аңламыйбыз...

Бу дөнья бит... рәшә генә!..

PRESSA.RU



Кышкы Норвегияне күз алдыгызга китерегез... Тромсе шәһәренең курчак урамнары. Шул урам буйлап Фәрит абый Бикчәнтәев һәм Люция апа Хәмитова белән култыклашып йөрергә насыйп булды. Видеога төшерәм – карга шыгырт-шыгырт басып атлап узып баралар. Люция апа кулын болгый: «Без – троллик-лар!» Тролльләр иле бит... Сувенирлар кибетеннән парларының символы итеп, куш тролльләр сынын озак сайладылар – иң матурын, иң пөхтәсен, иң-иңен. Янына «уллары» да килеп кушылды.
Бер-берсенә нәзакәтле итеп эндәшүләре, бер-берсен кайгыртулары... Тыныч кына сөйләшүләре, фикер алышулары, хатирәләр белән уртаклашулары... «Миңа да шулай кирәк, төреп бирегез, зинһар», дип, кемгәдер әйтәсе килде...

Моннан берничә ел элек... Ярар инде, берничә ел элек түгел. Моннан күп еллар элек – балачагымда караган спектакльләрнең берсе – Г. Камал театрындагы Лопе де Веганың «Биюче»се булды. Спектакль барышында әнием сәхнәдәге актерларның исемнәрен колагыма пышылдап чыкты. Калганнарын кабат-кабат сорарга туры килде, ә Люция Хәмитова исеме, ничектер, бер әйтүдә истә калды. Һәр спектакльдә аны күптәнге танышым кебек эзләдем...
Татарстанның халык артисткасы Люция ХӘМИТОВАның юбилее да килеп җиткән. Яшен белгәч, ышанмадым. Сөйләшүне дә нәкъ шул мәсьәләгә ачыклык кертүдән башлап җибәрим, 50 диеп алдашмыйлармы?..



Сөмбел ГАФФАРОВА

РОЛЬЛӘР ҺӘМ ТРОЛЛЬЛӘР

Сез һәм 50 санының бер җөмләдә торуы гаҗәпләндерә. Чибәр, стиль белән киенгән, үзенә үтә игътибарлы Люция Хәмитова белән бәйрәм ителүче юбилей яше тәңгәл килми. Шуңа күрә бу сан турында күңелегезгә тимичә генә сөйләшә алырбыз дип уйлыйм. Ничек Сезгә илледә?
– Үзем дә гаҗәпләнәм. Аптырыйм. Ничек инде – илле? Кайчан килеп җитте соң ул илле? Ярты гомер бит бу?! Үземне бер дә илледә дип хис итмим. Бу саннан – яшемнән һич кенә дә курыкмыйм. Гомумән, бу турыда уйларга вакытым юк дисәм дә була – репетитор белән инглиз телен өйрәнәм, фитнеска йөрим, рольләремне иҗат итәм.

Менә нәрсә хакында сөйләшик әле. Ничек иҗат итедә ул роль? Бөтен дөньяга танылган Норвегия драматургы Йон Фоссеның «Җәйнең бер көнендә» спектаклендәге Хатын персонажы бик авыр, минемчә...
– Роль генәме соң, пьеса үзе дә җиңелләрдән түгел. Ритмик прозада язылган текстны ничек уйнарга? Ничек башкарырга?! Пьеса да үзенчәлекле булды, репетицияләре дә – этюдлар рәвешендә. Режиссер белән бергә текстның тональностен, сәхнә телен эзләдек. Героинямны үзем «киендердем» – режиссер хуплады.

Сез анда күз белән уйнадыгыз бит!
– Башкача була да алмады. Әлеге спектакльдә героинямн – бүгенгесен үткәне белән тоташтыручы җеп ролендә. Күз карашым бер мизгелгә генә суынса, ул җеп шартлап өзеләчәк!

Озын монологлы, ташып торган динамикасы булмаган спектакльне... тамашачы тын да алмыйча күзәтә. Атмосферасы сихерли диимме...
– Режиссер һәм автор сихере ул. Әйе!

Бу роль Сезнең өчен...
– ...Чираттагы этап. Сәхнәмдәге башлангыч этабым – «Ромео һәм Джульетта»дагы Джульетта роле булды. Яшь, тәҗрибәсез, күңелле чаклар... Аннары Гөлҗамал роле. Чеховның «Өч сеңел»ендә – Маша, «Җирән чичән»дә – Карачәч, «Кара чикмән»дә – Чобра... Төрле-төрле рольләр бу! Гомердә бер мәртәбә була торган рольләр... Минем байлыгым...

«Ак калфагым төшердем кулдан» спектаклендә Сез журналистлар тиресен «киеп карадыгыз». Геройларга читтән карау мөмкинлеге булды. Үзегез өчен кайсы як бәхетлерәк, дигән сорауга җавап бирә алдыгызмы?
– Теге як та, бу як та тилмерә. Халкыбызның ярасы бит бу. Кистереп җавап бирә алмыйм. Хәер, беркем дә бирә алмыйдыр. Режиссер да бу сорауга җавап бирми – сорау билгесе белән тәмамлый. Тамашачыга уйланырга калдыра.

■ 2014 елда «Җәйнең бер көнендә» спектакле «Иң яхшы кече формадагы спектакль», «Иң яхшы режиссер эше», «Иң яхшы актриса», «Иң яхшы ут куелышы» номинацияләрендә «Алтын битлек» фестиваленә тәкъдим ителде.

■ Әлеге пьеса Россиядә беренче булып Г. Камал театрында куелды.




Ахырда «Ак калфагым» җырын тыңлап еладык.
– Ой, мин үзем дә елыйм...


Актер белән табиб һөнәрләре охшаш, минемчә. Табиб, еламас-сыкрамас, йөрәге ярылып үлмәс өчен, тормышка сарказм, цинизм белән карый, кара юморны үз итә. Ә Сез авыр рольләрдән ничек таушалмый чыгасыз?
– Рольгә тулаем кереп китеп, һәр рольне йөрәк аша уздыра торсаң, чыннан да, юләрләнерсең. Юк, актер ролен күзәнәк арты күзәнәк җыеп төзи. Ролен ясый, һәрьяклап өйрәнә. Гомумән, ролеңне өйрәнү – эшнең иң интим өлеше, аның барысын сөйләп бетереп тә булмый. Героеңны өйрәнгәндә үзеңдә актарынасың, үзең белән булган вакыйгаларны искә төшерәсең, шулар белән үз ассоциацияләреңне бәйлисең. Кирәкле китаплар укыйсың, авторы турында күбрәк белергә тырышасың. Аннары аны читтән күрә башлыйсың – бу яктан да, теге яктан да. Нинди генә драматик, фаҗигаи роль булмасын, сәхнәдә син аны уйнап чыгасың, бу синең профессияң, эшең...

Ә менә Фоссеның спектакленнән соң җан чистарына сыман. Җиңеллек тоясың. Кәеф күтәренкелеге. Рәхәт...
Барлык рольләр белән дә андый хисләр кичермисең...

Бүген нинди пьеса премьерасын әзерлисез?
– Һе! Синең «Килмешәк» исемле пьесаңны! Беләсеңме, монда да Фоссе пьесасында кебек эзләнүдә без. Радик Бариев һәм мин башкарган төп рольләрнең үз авырлыгы – кызыгы бар. Икебез дә залның күз алдында – киемне алмаштырмыйча, йөзне яшермичә

PRESSA.RU





егерме яшьлекләрдән җитмеш яшьлекләргә һәм аның киресенә әверелергә тиешбез. Эш дәвам итә.

Ирегез режиссер Фәрит Бикчәнтәев белән эшләве ничегрәк?

– Мин ансыз эшләүнең ничек икәнен белмим дә бит. Башыннан ук бер җайга салынды ул. Бар да табигый һәм шулай тиеш кебек. Үзеннән-үзе бара.

Фәрит абый тәнкыйтен күтәрү авыр түгелме?

– Эш барышында икебезне дә канәгатьләндерерлек нәтиҗәгә киләбез. Монда күбрәк мин: «Фәрит, әйт инде, кайда дөрес уйнамыйм, кай төшне үзгәртим?» – дип бәйләнәм. Ул беркемгә дә каты бәрелми. Миңа карата да ниндидер иллюзия эчендә яшәми, аек акыллы, объектив карашлы ул. Беркемне дә үпкәләтерлек итеп сүз әйтми, бик позитив, нәзакәтле дип тә әйтер идем. Аның белән рәхәт. Җайлы кеше ул. Ачуы чыкса да, әйтәсен юмор белән әйтә... Үзең аңлыйсың инде, нәтиҗәләр ясыйсың. Мин кабынып китүчән, эмоциональ булсам, ул тыныч, сабыр. Холыклар туры килә безнең.

Гаилә тормышында кем гакыллырак?

– Икебез дә дип әйтер идем. Гакыл табигатьтән биреләдер ул. Тәҗрибә генә заман белән килә. Ялгыш адымнар ясамадым, шулай дип беләм. Нәрсәнедер үзгәртер идем... дип тә әйтә алмыйм. Өйләнеп карыйм да, дөрес яшәгәнмен икән дим.

Гади гаилә кичләрегез ничек уза?

– Безнең уртак кичәләр бармы дип сора! Репетицияләр, спектакльләрдән буш арада Бәрәскә авылына кайтып киләбез. Мунча керәбез. Чын ял – менә ул!

Фәрит абый Сезгә ничек тәкъдим ясады? Туегыз ниндирәк булды?

– Тәкъдим булмады да кебек. Без бит озак йөрдек. Үзеннән-үзе өйләнешергә дә карар кылдык. Фәриткә мин күптәннән гашыйк идем. Әти-әни белән театрга йөри башлаудан. Ул – кызларның кумиры. Аннары мин театраль училищега укырга кердем. Фәрит Марсель Хәкимович курсын тәмамлады, ә мин шул ук курска эләктем. Шуннан аралаша да башладык. Еллар узгач, Фәрит искә ала: «Минем сине беренче күрүем кайчан, беләсеңме? Училищега кергән идем, холлда утырам шулай. Син барасың. Аякларың – биючеләрнең беренче позициясендә. Төп-төз гәүдә, башың югары күтәрелгән. Шунда шаккаткан идем сиңа». Аннары бер тапкыр урамда очрашып сәламләштек. Фәрит Рифат Йосыпов белән сөйләшеп басып тора, мин узып барам икән. Артымнан Фәрит: «Менә бу кызчык минем хатыным булачак», – дигән! Аннары Фәрит Мәскәүгә укырга китте. Озак хат алыштык, ул хатлар миндә әле дә саклана. Кайткач та өйләнештек. Туй дигәне гомергә истә сакланып калды. Фәритнең беренче җыйган курс студентлары – Искәндәр Хәйруллин, Радик Бариев, Фәнис Җиһаншалар безгә кече сәхнәдә шоу әзерләде! Сәхнә уртасында мендәрле таган, мин таган атындым, ә тирә-ягымда – сәхнәгә чыга торган күлмәк-костюмнарым эленгән... Бик романтик кичә булды ул... Бәйрәм Фәритләр яшәгән фатирда дәвам итте. Театрда әле дә шулай – өйләнешкән парлар башта театрга килә. Котлашабыз. Бала табу йортыннан каршы алабыз. Театрыбыз – зур гаилә.

Улыгызның яшүсмер чоры проблемалары белән ничек көрәштегез?

– Проблемалар булды дип әйтә дә алмыйм...



Яшүсмерлекнең драматик күчешен тоймадык та. Йосыфның гел ниндидер эше-шөгыле бар иде. Спорт, музыка... Әбисе Наилә Хәкимовнаның ярдәме зур булды, ул күп вакытын оныгына багышлады.

Пианино, труба, гитара, бәрмә инструментлар, брейк-данс, инглиз, кытай телләре... КФУның көнчыгыш телләре факультетын тәмамлап, ике ел инде театрның труппасында эшли. Планнары?

– Йосыф ГИТИСка режиссерлык курсына укырга керергә йөри. Сергей Женовач курсына. Бик борчылабыз. Фәрит тә әйтә: «Әйтерсең укырга үзем керәм. Шуның кадәр дулкынлан инде!..» Әлегә планнар шушындый.

Мин үзем – артык борчылучы әни...

– О! Син ялгыз түгелсең, мин – шашкан әни! Минем ничек борчылганымны белсәң?! Ут йотам! Башка әллә нинди уйлар керә бит! Ә тынычланып булмый, шуңа күрә һаман шалтыратып, язып торам. Баланың бар да яхшы икәнлеген һәрдаим белеп торырга кирәк.

Улыгызның исеме дә исеме бит әле! Ул вакытларда андый исемне кайсыгыз тапты?

– Мисхорда ял иткән чаклар. Фәриткә куанычлы хәбәремне әйттем. Кулында Томас Манның «Иосиф и его братья» китабы. Фәрит: «Малай була. Йосыф дип кушарбыз». – «Каян беләсең кем туачагын?! Нинди Йосыф тагын? Нинди исем инде бу? Каян таптың? Ю-ук!» дигән ай-вайларыма карамады. Бик матур исем шул.

Улыбызның тууы – иң бәхетле көнемдер. Бәби тапкач, палатада ял итеп ятам. Пыялалы ишеккә карасам, Фәрит белән Шамил Зиннурович басып торалар. Ничек керткәннәр диген?! Кулларында чәчәк бәйләме. Яз башы. Март. Шул көнне дөньяны каплап кар яуды... Күз алдымнан һич китми торган көн ул.

Тормышта иң мөһиме нәрсә?

– Тегенди роль, мондый роль уйныйсы иде, дип әйтмим. Юк. Туганнарым, якыннарым сау-сәламәт булсын. Минем өчен ул иң мөһиме. Алар өчен күңелем тыныч икән, димәк, тормыш та дәвам итә. Эшли дә алам. Өйдә тыныч кына булсын. Безгә килгән һәркем: «Өегезнең үзгә аурасы бар», – дип әйтә. Бу – чыннан да шулай, моны үзебез дә тоябыз.

Фәрит белән Люция гастрольдән яки эштән өйгә кайтып керә. Хатын – иркен күлмәк, ир уңайлы киң ыштан киеп куя. Ашап-эчеп алалар. Берсе җайлап кына кәнәфигә, икенчесе диванга ава, бер-берсенә җылы карашып алалар...

ИР. Өйдә рәхәт, әйеме, Люсь?!

ХАТЫН. Әйе-е, Фәрит...

Юк, бу пландагы спектакль түгел. Бу – тормыш үзе язган бәхетле гомер мизгеле...

Күңел*
радиосы FM 92.6 УКВ 67.79
БЕЗНЕ ТАТАРСТАН ТЫҢЛЫЙ!
105,6 FM
105,6 FM
105,6 FM
103,9 FM
100,2 FM
92,6 FM
103,9 FM
100,2 FM
Балтач
Арча
Кукмара
Байлар Сабасы
Биектау
Казан
Мамадыш
Яр Чаллы
РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ ТЕЛЕФОННАРЫ:
8 (8552) 56-15-09
8-917-235-65-32
РЕКЛАМА
12+

PRESSA.RU



ЗӘҢГӘР ҖӘЙЛӘР ЕРАК ДИСӘҢ ДӘ...

Клара БУЛАТОВА

Казан дәүләт университетында укып йөргән елларым. Кызыл Позиция урамындагы тулай торакта бер бүлмәдә без дүрт кыз яшибез. Чиратлашып дежур торабыз, ягъни татарча кизү тору була инде... Шулай ашарга әзерлибез, идәнне юабыз. Минем кизү көн. Мин үрмәләп идән юам, балачактан шулай өйрәнелгән. «Лентяйка» дигән әйберне мин яратмыйм. Бөтен җиргә керәлми ул. Ялкау хатын-кыз шуның белән юа. Мүкәйләп, караватасларына кереп китәм. Өстемдәге 3 сум 60 тиенлек трикоband тезе дә, терсәге дә изрәп беткән. Чыгып киләм бер тимер караватастын юып... Карасам – ике аяк уртасына бер пар ирләр ботинкасы килеп басты. Сап-сары ботинкалар. Аптырап торам инде карап...

– Клара Булатова дигән кеше монда торамы? – ди.

Ә минем әле тагын өч карават астын юасым бар. Шуңа хәйләгә керештем:

– Әйе, – мин әйтәм, – ләкин ул үзе өйдә юк әле...

– Кайчан кайта соң? – дип сорый сары ботинка иясе.

Караватларга карыйм: вакытны саныйм үземчә.

– Бер ярты сәгатьтән кайтыр, – дим.

– Ярый алай булгач, коридорда көтеп торыйм, – дип, чыгып китте сары ботинка.

Мин дә юып бетердем. Өсне алыштым. Халат киеп куйдым, кеше кыяфәтенә кердем инде. Егет кеше килгән бит Клара Булатованы сорап! Чәчәк булдым инде! Чәчемне тараттым. Ни яулыкка, ни бүреккә

Кыңгырау чәчәкләре

Кара урман уртасында
Яшел үзәндә
Кыңгыраулар, кыңгыраулар
Җилдә тирбәлә.
Кыңгыраулар,
кыңгыраулар –
Зәңгәр бигрәк тә;
Зәңгәр сагыш уяталар
Алар йөрәктә.
Хәтерләтә кыңгыраулар
Миңа берәүнең
Кыңгырау чәчәкләредәй
Зәңгәр күзләрен.
Аерылыштык,
аерылыштык
Еллар буена.
Кыңгыраудай зәңгәр күзләр
Калды уемда.
Кара урман уртасында
Яшел үзәндә
Кыңгыраулар,
кыңгыраулар
Җилдә тирбәлә.
Кыңгыраулар,
кыңгыраулар,
Зәңгәр карашны,
Әйтегезче, ничек кабат
Эзләп табасы?
Кыңгыраулар,
кыңгыраулар, –
Зәңгәр бигрәк тә;
Кыңгыраудай зәңгәр күзләр
Калды йөрәктә.

буйсынмаган баш бит инде миндә. Инсафлы гына, матур гына бала тора. Мин бу җирдә нәрсә калдырам, дөнья мине нишләтә, дигән сорау бу баланың карашында. Теге егет тә керде.

– Мин – Марс Макаров, – ди. – Клара кайтты микән? – дип сорый.

– Мин ул Клара, – дим.

Бер күрде бит инде, дисезме? Күрсә ни! Шулай итеп, ярты сәгать эчендә бөтенләй икенче – чын Клара булып кабул итәм егетне.

– «Азат хатын» журналында чыккан шигырегез миңа ошаган иде... Мин аны көйгә салган идем... Әйттеләр, үзе белән сөйләшмичә ярамас, ул шундыйрак нәрсә инде, диделәр... Шуның өчен яныгызга килдем, – ди егет.

Менә шундый тарихы бар ул җырның. 1959 елда язылды. Беренче тапкыр 1960 елда Фәхри Насретдинов башкаруында радиодан яңгырады. 70 нче елларда бик популяр иде ул. Кая барсам, шунда җырлыйлар. «Зәңгәр кыңгыраулар»ны Вафирә Гыйззәтуллина үз репертуарына кертте. 60 яшьлек юбилеемда ул җырны Зөһрә Шәрифуллина җырлады.

Зәңгәр кыңгыраулар, зәңгәр күзләр, зәңгәр сагыш... Сөеп кигән төсем дә зәңгәр иде... Болары инде балачакның матур истәлекләре.

...Ләкедә әтием Гариф укыткан мәктәптә күрше Алан авылыннан өч ятим малай йөреп укыды. Әтиләре сугыштан кайтмаган иде. Чабата киеп киләләр, яңгырда чыланып беткән бишмәтләрен мич каршында тотып киптерәм... Олысы – миннән бер яшькә генә зур Валентин Малов. Әтинең иң яраткан шәкерте. Күзләре зәп-зәңгәр иде ул малайның!.. Ничектер күңелемә якын иде ул зәңгәр күзләр... Гашыйк булу менә шулай була бугай. Серләремне ахирәтем Зина-Зинукка сөйләп барам. Берчак шул Зинук белән июль уртасында күрше авылга Питрау кайтуына барганда, ял итәргә туктап, аланда ромашкалар җыеп йөргән идек. Зинук: «Яратамы, юкмы?» – дигән булып, өзми генә ромашкаларның таҗын санады. «Мәхәббәтең шатлык бирсен!» – диеп, чын күңелдән юрапюатып, чәчләремә чәчәк кадады. Тик ул кичне Чәпчи Валентины... бүтән кызны озата киткән булып чыкты! Минем өчен инде бәйрәмнең – тәме, җәйнең яме киткән кебек булды. Керәч төсле ак ромашкам да ничектер сулып калды... 17 яшьлек кыз күңелен авырттырган беренче яра иде ул. Еллар узгач, Питрау печәннәре өлгергән кояшлы июльдә улым белән шул болында – яшьлек эзләрем калган урыннарда ромашкалар җыеп йөрдек. «Исән микән Чәпчи Валентины, бәхетле микән бу көндә?» – дигән уйлар һич баштан чыкмады. Шулар барысы «Июль хатирәсе» дигән шигыремә кереп калды.

Һай, «Зинукка хат» шигыремдә дә шул ук зәңгәр күзләр лә:

Зәңгәр күзләр җырлап
яшьлек үтте,
Зәңгәр хыял җебен сүтә-сүтә...

Соңрак ишеттем инде: университетның геология факультетын тәмамлаган, инженер булган егетебез. Читкә киткән, өйләнгән. Үзебез дә башлы-күзле булдык, балалар үстердек. Берчак Зинук белән үткәннәрне, мәктәп елларын искә төшереп, хатирәләр яңартып утырдык. Ул малайны да сагынып телгә алдык. Һәм үзебез дә сизмәстән зәңгәр кыңгыраулар, зәңгәр күзләр, зәңгәр җәйләр хатирәләренә чумдык. Минем күңел халәте менә мондыйрак иде:

Җәйләр саен шул Питраулар
җитсә,
«Олы җәйләр» кереп төшемә,
Күңел кылларымны
тәүге чирткән
Зәңгәр җәйне искә төшерә.

Олы җәйләр минем төшләремдә
Әле һаман җырлы, гармунлы.
Кабат-кабат алам исләремә
Питраулардан калган
бар моңны.

Күңел кылларымны
тәүге чирткән
Зәңгәр җәйләр ерак дисәң дә,
Тәүге сөю онытылмый икән,
Язмышыңны бүтән булсә дә.

...Күңел кылларыңны
тибрәлдергән
Зәңгәр күзләр хәзер ниндидер...
Җәйләр саен шулар Питрауларда
Төшкә кереп тынгы бирмидер.

Фотода: Зөлхәбирә Ишбирдина (Әстерхан), Салисә Гәрәева, Рашат Гайнанов, Розалина Йосыпова, Клара Булатова «Азат хатын» редакциясендә. 1960 ел.

PRESSA.RU



ВАКЫТ БӨТЕНЕСЕН ДӘ СЫНЫЙ, ҮЛЧИ, БӘЯЛИ ТОРГАН ТӨШЕНЧӘ.

Еш кына без, берәр эшкә әзер түгел икәнлегебезне сизгәндә, җиңел генә: «вакыт юк!» дип, җаваплылыктан качабыз. Вакыт бер ул, бар ул, ә кем өчендер, гомумән дә, туктап калган ул.

Асия ЮНЫСОВА

ВАКЫТ БИЗМӘНЕ

Саба районындагы Югары Утар зәгыйфь балалар интернатына беренче мәртәбә килгәнемнән соң узган егерме елга кадәр араны әнә шул вакыт төшенчәсе калыбына салып бәяләргә тырышып карыйм.

Утар мәйданындагы каеннар бу вакытны әрәмгә уздырмаганнар – тагын да зифалана, зәңгәр күк гөмбәзенә тагын да якыная төшкәннәр. Интернат биналары да шактый «яшәргәннәр». Хәзер инде алар тәмам европалашып беткәннәр. Димәк, биредә тәрбияләнүче балалар заманнан калышмыйча, иң алдынгы җиһазлар ярдәменә ышанып дәвалану мөмкинлегенә ия булганнар. Без дә, без дә бар әле монда – сез санаган тәрбияви чаралар исәбендә дигәндәй, тавислар чурыйлап аваз сала, аңа бөркетнең куәтле коркылдавы өстәлә, үзәнлеккә төшкән тарафта ламаларның сыртлары күренеп кала, интернат директорын кунаклардан көнләгән маймыл кызының ризасыз зарлануы ишетелә... Болары – табигать балалары, аның да вакыт белән ярышта яңарып, үзгәреп, кабатланып тора торган өлеше.

Табигать патшасымын дигән кеше үзе генә вакытка бирешмәскә, яшәүнең ләззәтен татырга, дөресрәге, шул яшәешне мәгънәлерәк итәргә тырышып, һаман-

һаман күрәштә. Бу ел башында ачылуына 55 ел тулуны билгеләп үткән интернатның директоры Имам Гәрәй улы Гәрәевнең генә вакыт белән мөнәсәбәтләрен ничек билгеләсәң дә, чын хакыйкать табылмас кебек. Япь-яшь егет килеш шушы урын һәм вакыт аралыгына кереп кал да шунда эчтәлекле, мәгънәле итеп яшәп кара! 55 елда интернат аша узган мәзлүмнәрнең саны да, интернаттан соңгы язмышы да билгесездер дип уйлыйм да... үзем үк җавабын да табам. Ә нигә билгесез булсын икән ул. Берьюлы йөзләп бала тәрбияләнә. Балигълык яшенә җиткәннәре Яшел Үзәндәге, Казан янындагы өлкәннәр өчен булган интернатларга китеп бара. Шуннан соң, нормаль балалар тәрбияләнеп киткән интернатлардагы кебек, елына бер очрашу кичәләре дә була, рәхмәтле күз яшьләре, гөлләр-чәчкәләр була... Юк булмый! Бу интернат балалары үзләренә биредә каралган вакыт аралыгын үткәннән соң, аларны тәрбия кылганда шушы бичаралар өчен җаннарын ярып бирергә әзер Гөлнараларның, Гөлүсә, Гөлназ, Әнисәләрнең йөрәк җылысын алып, бөтенләйгә орбитадан төшеп калалар. Җавапсыз мәхәббәт йорты бу!

Әйе, Имам Гәрәевнең вакыты 55 ел элекке берәмлектә тукталып калган. Аңа олыгаерга да, картаерга да, авырырга да ярамый. Һәм ул үзенә коллективны да шундый кешеләрдән туплаган. Бу орбитага бер килеп кергән кеше, мөгаен, үзең өчен яшәү дигән нәрсәне оныта торгандыр. Кешечә атлап китүдән, кешечә кашык тотудан, аңлаешлы итеп сөйләшүдән, ә кайвакыт биш кенә минутка калтыранмый торудан мәхрүм сабыйларның газап-кичерешләрен күрә торып, ниндидер вак-төяк мәшәкатьләрең турында уйлап буламы соң? Әйе, биредә вакытның гына түгел, тормыш кыйммәтләренең дә үлчәме бүтән.

Газаптагы, бигрәк тә бу газапларны азга гына булса да алдап тору өчен шөгыльсез, уйланып ятар өчен акылы да зәгыйфь булган гарип баланың тәүлектәге сәгатьләре, минутлары ничек озын булуын уйласаң, дөньяга гарип бала тудырган наркоманнарга нәфрәт тагын да көчәя. Дөрес, гариплекләрнең байтагы «табигать шаяруы», ә, бәлки, экология «казанышы»дыр. Белмим, белмим, ләкин, сәбәпләре ни генә булмасын, нәтиҗә – аяныч! Кирәксезгә калган шушы бичаралардан ярый әле дәүләт баш тартмый да, ярый әле фидакарь затлар бар.

Шуларның берсе Әнисә Зарипова белән сөйләшеп утырабыз. Югыйсә әйбәт, бөтен гаиләдә үскән, яхшы һөнәргә ия булган Әнисә бу хәсрәт йортын урап та уза алган булыр иде. Аның тормышы хыяллар, романтика кочагында Чулман дулкыннары өстендә башланган лабаса. Елга көймәсендә кок (аш пешерүче) Әнисә белән матрос егет мәхәббәте кызны соңыннан Шәмәрдәнгә китерә. Туйлардан соң озак та тормый Саша-Александр армиягә алына, Әнисә, кызы Ларисаны табып, ярда кала. Чын-чынлап ярда калу була бу. Чөнки солдаттагы иргә кеше арасын бутаучылардан хатлар китеп торган икән. Яшь гаилә таркала. Әнисә сынауларга әзер үзе. Ләкин кулда яшь бала булу һәм Шәмәрдәндә эш табуның кыенлыгы сынауларның шартын авырайта. Ни эшләргә? Андый чакта кешеләр күрәзәгә бара. Әнисә дә китә һәм... канатланып кайта. Күрәзәгә барма, башыңа чир алма, дигән булалар тагын. Күрәзәче хатын аңа күп итеп кыенлыклар вәгъдә итә. «Әй, кызым, түзеп тә карыйсың әле син! Тик картлыгың гаҗәп бәхетле синең. Мондый матур фалны бирәүгә дә ачканым юк иде әле», – ди. Менә шушы «матур фал» кызны дәртләндереп җибәрә. Яшьлек җиңә алмаган сынау булырмы? Кыз бу юлы нефтьүткәргеч трассада эшләүчеләрне ашатырга яллана.

Бичаралар бичара булып күренмәсен өчен, хәсрәтле йорт бәхетле кебек тоелсын өчен кирәктер инде ул Әнисә Зарипова кебек фидакарьләр.

Рифкатьне ул шунда таба. «Димләделәр. Өен барып карадым. Таза йорт. Безнең гомергә җитәрлек. Тәвәккәлләдем – чыктым кияүгә». Менә шушы «тәвәккәлләдем» гомер буе юлдаш булыр әле аңа. Бу никахтан кызы Ләйсән туа. Әмма Әнисәне ире өендә Рифкатьнең әни дияргә тилмергән улы да көтеп торган икән. Малай беренче көнне үк мәктәпкә укытучысыннан сөенче алырга чаба: «Минем дә әнием бар хәзер!» Шул баланың күңелен ничек китәсең инде, дип тә яшәп калган бугай ул ире белән.

Әле әллә нинди китек күңелләргә юлыгасын уйламаган да чагында тормыш аны интернат сукмагына төшерә. Ул болайрак була: «Гает көн иде бу. Кызым Ләйсән туар көн җиткән иде. Ирем авариягә юлыкты. Гренадер кебек кеше тугыз ел хаста ятты». Ларисасын, Илшатын, Ләйсәнен, кайнанасын кочаклаган Әнисә эшсез бит әле. Хәзер ул трассага да чыгып китә алмый.

Ярый, ике-өч сыер асрасын, ди. Кайда кочегар, кайда охран эше бар – Әнисә анда! «Кайнанам Миңзифа алтын иде. Бик яраттым мин кайнанамны. Ул да мине яратты. Мунчага күтәреп алып барып юындыра торган идем. Үз әниемне дә шулай карадым».

Интернаттагы эш стажын да «күтәреп йөрүләр» белән башлый ул. «Бер чарам да калмагач, Имам Гәрәй улына гозерләнеп, эш сорап килдем. Санитаркалар кирәк икән дип ишеткән идем. Ул миңа карап-карап торды да: «Синең рәвешең бер дә килмәгән санитаркалыкка. Син бик шәһәрчә, үзең матурсың, яшьсең. Бездә бит әрсез кешеләр генә чыдый. Синең килеш-килбәт белән конторда гына утырасы. Авыр безнең эш. Бар, палаталарны урап чык. Шуннан соң сөйләшербез», – диде.

Кала Әнисә. «Өлкән төркемгә куйдылар. Ат чаклы малайлар тезелешеп басканнар баскыч буена. Элек

PRESSA.RU



Әнисәнең бәхетле киләчәге – ике кызы, улы, килене, кияүләре, оныклары...

тәмам җитлеккән малайлар да интернатта яши иде әле. «Егетләр» яңа санитарканың идән юганын шаккатып карап торалар: «Смотри-ка, сама полы моет!» Аларны болай шаккаттырасы түгел икән, үзләрен эшкә өйрәтәсе икән. Шунда Әнисә үз-үзенә сүз бирә: Бөтенесе тәртип булачак! Ә эшкә өйрәтү йоклаган урыныңны җыярга, кашык тотып ашарга, тешләреңне чистартырга, уңны-сулны аерырга, ал белән артны бутамаска өйрәтүдән башлана. Бер күрсәттең дә шулай эшлиләр дип уйласагыз, ялгышасыз. Һәр күнекмә ныгып урнашсын өчен кайвакыт айлар да җитми.

Ә менә авыру бала астын чылатмасын, пычранмасын өчен дежур санитарка төне буе уяу тора.

Мунча көннәре үзе бер тамаша. Кызларның гына түгел, малайларның да гигиенасы санитарканың кайгыртучан кулларын көтә. Җитлегә башлаган кыз балаларның көндәлеген алып бару кадәресе вак-төякме? Бәлки шулайдыр да, әгәр алар ике-өч кенә булса. Әмма чирле баланы күтәреп хастаханә юлында йөрү белән чагыштырганда, чыннан да, вак-төяк шул. Әнисәгә дә, Гөлүсәгә дә берьюлы өчәр баланың әнисе сыйфатында хастаханәдә ятарга еш туры килә. Чөнки бу зәгыйфь балаларның телләрен, ымнарын үзләренекеләр генә аңлый. Чирле бала янында ана кеше үзе дә чиргә сабыша. Әнисә ничә үлеп, ничә терелгәнен үзе генә белә торгандыр. Әле яңарак кына 20 көн йөрәк белән ятып кайтканнар. «Интернатка эшкә урнашуга ук биш баланы Әстерханга санаторийга алып киттек. Ул чагында җиңел арбаларыбыз юк иде әле. Казан тимер юл вокзалында безнең составны иң түрдәге юлга куйганнар. Авыр балаларны күтәреп күперләр кичә-кичә вагонга барып җиткәнче бурлак хәленә төшкән идек. Болар белән хатын-кыз икәнеңне дә онытасың кайчак.

Минем изалануларымны күреп үскән үз балаларым бик миһербанлы булып чыктылар. Теге күрәзәче хатын белеп әйткән: картлыгым бәхетле булырга охшап тора. Илшат улымның өч баласы бар. «Дәү әни, без сиңа охшаганбыз – намаз укыйбыз», – дип сөендерделәр әле».

Ул боларны интернат балаларының уңышлары рәтеннән генә саный. Балаларын елый-елый калдырып киткән ата-аналар да бирегә юлны бик тиз оныталар. Кунакка алып китеп торганның соңында сөенүләрен күрсәгез. «Бу сугыш чукмары күрше тавыкларының башын өзеп аткан», – ди берсе. Икенчеләре һава суларга чыккан җирдән баланы эткә талатып кергән – кыскасы, аз вакытка да чыдамыйлар. Ярый әле интернат бар, дип сөенәләр.

Әнисә күптән инде хуҗалык эшләре өчен җаваплы. Дөресрәге, сестра-хозяйка! Аннан да дөресрәге, әнкә! Ул, чыннан да, чәчәк түтәлләре өчен дә, урын-җир бөтенлеге өчен дә, памперслар җитешлеге өчен дә, кием-салым, савыт-саба муллыгы өчен дә җаваплы. Җиңел арбалар «паркы», гомумән дә, горурлыкның иң олысы! Арбалы булып алгач, гарип балалар тәмам аякланганнар.

Сабыйлар биш тапкыр әйбәт итеп ашасын өчен келәтләр ризык белән тулы, тәннәре рәхәттә ятсын өчен койма башларында урын-җир кояшта кибә, җайлы-уңайлы караватларда яткан 18 яшендә 3 яшьлек кимәлдә күренгән сабыйларның асты коры. Акыл зәгыйфьлеген җиңү өчен сыйныф бүлмәләрендә дәфтәр-карандашлар кытлыгы сизелми – кыскасы, тәртип! Әнисә ханым хәзердән үк инде Кызыл Мишә мәктәбенә беренче сыйныфка укырга төшәсе дүрт кызның мәктәп киемнәрен хәстәрләп йөри. Аларның чәчен тарап-үреп, ак бантиклар тагып мәктәпкә үзе озата барачак ул кызларны. Мондагы балалар мәдәни тормыштан мәхрүм икән дип уйлый күрмәгез. Әнисә Зарипова аларны «Возьмемся за руки, друзья!» бәйгесенә матур итеп киендереп алып бару уенда йөри әле.

Әнисәнең фидакарьлеге кызы Ләйсәнгә дә күчкән. Моннан өч ел элек гашыйк кызы әнисенә сөйли дә сөйли: «И әнием, син Раилнең күзләрен күрсәң...» Әнисә зәңгәр күз иясен белешә. Егет коляскада утыра икән. Авариягә юлыккан. Әмма бик көчле рухлы. Россиянең паралимпиячеләр командасында теннис уйный икән. Әнисә кызына бер каршы сүз дә әйтми. Акыллы, уңган Ләйсән бәлагә тарыган егеткә чын юлдаш була алган. Икәүләшеп чаңгы шуалар, велосипедта йөриләр, бәби алып кайту турында хыяллана-лар. Әнисә җиденче оныкны алардан көтә инде.

Яза башлаганда мин интернатта җавапсыз мәхәббәт яши дигән идем. Алай ук түгел икән. Әнә, Әнисәнең телефонына: «Доброе утро!» дигән «смс» килеп төшкән. Яшел Үзән интернатына җибәрелгән Руслан Вәлиевтән – чукрак малайдан. Димәк, Руслан телефонны да үзләштергән хәзер. Димәк, бу егет катып калган вакыт аралыгыннан чыга алган. Мондый нәтиҗәдә Әнисә Зарипова, Гөлүсә Ибәтуллина кебек фидакарь тәрбиячеләрнең 20 еллык гомер өлеше бар.



ӘХМӘДУЛЛИН Ришат

Казан театр училищесы (2011 ел)

Өйләнмәгән.

Карьера: Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты.

Тормыш шигаре: «Кеше, бик теләсә, мөмкинлекләр таба, теләмәсә – сәбәп эзли».

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Боз кузгалды!


«Үзгәреш җиле» проектын көтеп алдым. Идеясе глобаль, бик вакытлы һәм кирәкле иде. Татар җырын, татар композиторларын дөньяга таныту мөмкинлегеә бирде ул. «Үзгәреш җиле»ннән соң күп яшьләр татар җырын тыңлый башлады. Тик халык җырларын яңача яңгыратуны кабул итә алмадым. Алар халык аңында калыплашкан бит инде, аның драматургиясен нигә бозарга? Чакырылган музыкантларга сүз әйтә алмыйм, алар үз эшен югары дәрәҗәдә башкарды. Ләкин безнең үзебезнең дә менә дигән музыкантларыбыз бар бит. Бу эшне аларга ышанып тапшырганда да, оттырмабыз. Үзебезгә үзебез ышанабыз икән, безгә башкалар да ышаначак!


Хәрәкәттә – бәрәкәт


Сәламәт яшәү рәвеше хәзер модада. Күп шәһәрләрдә, хәтта авылларда спорт мәйданчыклары төзелә, халык кышларын чаңгыда шуа, җәй көннәрендә велосипедта йөри. Табиблар һәрбер шәһәр кешесендә диярлек вегетатив-кан тамырлары дистониясе бар, дип кисәтә икән. Соңгы елларда халык моны аңлый башлады – күбрәк хәрәкәтләнә. Ниһаять, Россиядә күбрәк елмая башлаганнар. Моның сере спорт белән шөгыльләнүдә, диләр экспертлар. Чөнки спорт шатлык, канәгатьлек хисе бирә. 20-30 минут шөгыльләнгәннән соң, кеше тәненә эндорфин – рәхәтлек гормоны бүленеп чыга. Күбрәк хәрәкәтләнгән саен, күбрәк елмаясың.

Юлбарыслар «ябыга башлаган»

Кыш айларында Кытайның Харбин зоопаркында симереп беткән Амур юлбарыслары турында хәбәр таралган иде. Аларны күргәч, күңелне әллә кайдан гына бер кыргый ген тырнап куйган иде: табигатьнең иң гаярь, иң кыю җанварлары да шулай ялкаулангач инде... Кыю ирләрне юкка гына курку белмәс юлбарыс белән чагыштырмыйлар бит. Әле күптән түгел генә аларның «җанланып» китүе турында ишетелде. Юлбарыслар үзләрен күзәтүче пилотсыз җайланмага ау оештырганнар, берсенә зыян да салганнар. Димәк, табигый инстинктлары йокламаган икән әле, куркыныч янавын сизенеп, кыймылдаганнар әнә.








сөендерде / көендерде

Таш белән атканга – аш белән

Мин кешеләргә үпкәләп йөрергә яратмыйм. Башкалардан да шуны көтәмдер, күрәсең. Күптән түгел берәү белән якыннан аралашып киттек. Шул арада ул миңа гашыйк булып өлгергән. Ул үзе тыштан кыю, җитди булып күренергә ярата, ә эчтән бик нечкә күңелле. Минем тарафтан шундый ук җавап булмагач, ул миңа нигәдер ачу саклый башлады. Усал-усал сүзләр дә ычкындыргалый. Мин елмаям гына... Ташка таш белән ата алмыйм бит инде. Гомумән, негативны таш урынына атышып «уйнаганны» аңламыйм. Бу дустымның да миңа карата ачуы тизрәк үтсен иде, дип көтеп йөрим әле менә.

Дума, ераккарак китеп уйла!

Россиядә баласыз яки бер генә балалы гаиләләргә салым кертү турында канун кабул итү башлангычы берничә ел дәвамында «эленеп» тора. Әгәр бу салым канунлаштырыла калса, аны берничә елдан әниләренә ана капиталы «алып биргән» икенче балалар түләргә тиеш булып чыга. Менә шундый гади генә арифметика: хөкүмәт бер кулы белән бирсә, икенчесе белән ала. Дума мондый канунннар уйлап чыгарганчы, яшь гаиләләргә ярдәм итү турында күбрәк уйласын иде, дип телисе генә кала инде. Ул чагында буйдаклар үзеннән-үзе кимер иде.

Гаджетлар революциясе

Смартфоннар аркасында, кешеләрнең умыртка баганасы кәкрәя икән. Бигрәк тә муен өлешендәге остеохондрозга зарланучылар ешайган. Лос-Анджелес нейрохирурглары бу гипотезаны фәнни яктан исбатлаган да инде. Алар, смартфоннар барлыкка килү белән кешенең вертикаль халәте үзгәрде, хәзер аларның башлары һәрвакыт иелгән хәлдә, ди. Гомумән, безнең бөтен тормышыбызның шул уч төбе хәтле смартфоннарга сыеп бетүенә күңел бер дә риза түгел. Әни элек мине һаман интернетта утырасың, дип ачулана иде. Үзенә бүләк иткән идем, хәзер әнә аерып алып булмый. Вирус кебек йогышлы булып чыкты ул.

PRESSA.RU

Токтыннар саны буенча, Россия дөньяда сигезенче, ә Европада беренче урында тора. Статистика мәгълүматлары буенча, бездә һәр унынчы ир-ат төрмә шулпасын татыган. Тимер чыбыклы биек коймалар артында утыручыларның 55 проценты, чыккач та гадәти тормыш белән инде, мөгаен, яши алмаячак, чөнки сроклары озак булу сәбәпле, алар инде җәмгыятьтән аерылырга өлгерә, ди белгечләр.



ЧИРАТ

Гөлнур САФИУЛЛИНА

Супермаркетта кассага чират торам. Чират дип... Иртәнге як, кибет әле буш диярлек, сатып алучылар берән-сәрән генә. Бәлки шуңа күрәдер дә, кассаларның нибары берсе генә эшли. Чират та, әйткәнемчә, юк диярлек. Минем алда нибары бер апа гына, тик барыбер чират тиз барырга охшамаган – алган әйберләре шактый аның. Иллеләп кап чәй генә җыйган: кассир кыз аларның һәрберсен аерым саный. Чәй капларының берсе ачылган булып чыкты.

– Апа, алыштырып киләсезме? – ди кассир кыз.

– Юк, юк, сеңлем, – диде апа, ашыгып. – Мин аларны зонага алып барам, барыбер ачарга туры киләчәк...

Соңгы җөмләсен нигәдер миңа карап әйтте. Озакка тоткарлаганы өчен гафу үтенергә теләве идеме соң? Әйтмәсә дә була иде. Беренчедән, алай ук сабырсызланмыйм – вакытым бар. Икенчедән, бу апаның төрмәдә кемедер утырганын болай да аңлаган идем инде. Кайнар суда болгатып кына ашый торган бәрәңге боламыгы, стаканда әзерләнә торган аш, арзанлы чәй... Берьюлы бу кадәр күп итеп теләсә кем алмый аларны. Һәрхәлдә, миңа шулай тоела. Соңгы вакытта шулай тоела...

«От сумы и от тюрьмы не зарекайся» дигән гыйбарә бар русларда. Бар тапканын мизгел эчендә югалткан кешеләр әллә азмы? Шуңа күрә, капчык асып, беркайчан теләнергә чыгып китмәм, дип әйтмә, дип кисәтә безне гыйбарәнең беренче өлеше. Башым таш капчыкка эләкмәс, дип өздереп әйтү дә куркыныч. Хагыннан, нахагыннан үзең сакла, дигән сүзләр телгә юкка кермәгән бит инде.

...Улы төрмәдә гаепсезгә утыра дип санамый ул. (Әле ярый шулай дип санамый дип, кайчак мин аның өчен сөенеп тә куям. Югыйсә йөрәк әрнүләре тагын да күбрәк, авыррак булыр иде бит.) Ни өчен кулга алганнарын сөйләп тормыйм – анысы бу очракта мөһим түгел. Май ахыры иде ул. Күрше әбиемнең тоташ борчудан гына торган көннәре шуннан соң башланды.

Азмы-күпме җыйган акчасы адвокатка түләргә китеп бетте аның. Монысы бик тиз булды. Әбинең җыйган маясы беткәнен аңлагач, адвокат егет аңа шунда ук шалтыратудан туктады. Бу вакыт күршем дә аннан өметен өзәргә өлгергән иде инде. Әбигә исә хәзер акча башка нәрсәгә – ай саен СИЗОга «передача» илтергә кирәк иде. Ай саен бер пенсия акчасына бит ул! (Беркайда эшләмәүче килененең ире янына барып йөрмәячәге көн кебек ачык иде. Ике бала да бар бит әле. Димәк, улының бөтен ышанычы – сиксәнгә җитеп килүче шушы карт әни.)

– Бүген 2 кило прәннек алдым... Ерак базарга ук бардым.

– Пакетлы солы боткасы эзләп йөрдем. Арзанлысын тапмадым. Миңа 25 ләп кирәк...

– Ипигә май сөртеп ашап куйса, тамагы туяр, сыер мае алдым әле.

– Носкилар сораган. Бер футболка, дигән.

– Кайнар су болгатып ясый торган теге бәрәңге боламыгын таптым бүген. Бик арзан түгел икән ул... Егермене алып тордым әле.

Кич безгә кергән саен әбинең бөтен сүзе шул хакта хәзер. «Олы йортка – ни кирәк, кече йортка – шул кирәк», дип сөйләшәбез аның белән. Кишер кирәк, сарымсак, суган кирәк, сыер мае, сыр, ипи, кәбестә шикәр комы, укроп... Әни күңеле бит әле – аз-азлап булса да, барысыннан да авыз иттерәсе килә: редиска, кыяр, помидор, алма, лимон, әфлисун... Колбаса, тавык рулеты. Майонез. Каһвә. Печенье, прәннек, хәлвә...

Теш юа торган паста, теш щеткасы, бәдрәф кәгазе, кер сабыны, исле сабын, мунчала, шампунь, салфетка, кер юарга порошок, кулъяулык... Сөлгенең зурысы, кечкенәсе... Оекбаш...

Боларның барысын әби кибеттән берничек тә берьюлы күтәреп кайта алмый. Шуңа күрә ул аларны аз-азлап җыя. Кайда арзангарак саталар – шуны да табарга кирәк бит әле аңа.

Башына төшмәгән кеше генә белми: төрмәгә «передача» тапшыруның мең төрле хикмәте бар икән. Кәгазьгә төрелгән конфет алсаң, тапшырганда, аның кәгазьләрен салдырырга кушалар. Ике килограмм конфет бирергә җыенасың икән, һәрберсен сүтеп утырасың. (Әби шуңа күрә гел мармелад алырга тырыша.) Чәйне капларыннан пакетка бушатып бирәсең. Теш пастасын – пакетка сыгып чыгарасың. Ипи, колбаса, сырны урталай бүләсең...

Барган саен, гариза язып, улыма шушы-шушы әйберләрне тапшырам дип, исемлек төзү дә әби кебек олы кешегә шактый зур мәшәкать булып чыкты. Ә бер ай узып, икенчесе шундый тиз килеп җитә... Тагын авыр капчыкны җыясы, тагын чиратка барып басасы... Әби бу юлы чиратта ничәнче булган, кемнәрне күргән, ничек тапшырган – мин ул баруларның һәрберсеннән хәбәрдар. (Сүз уңаеннан. Үзем анда бер тапкыр булмасам да (булырга да язмасын!), ул чиратны күз алдыма китерәм. Дөнья мәшәкатен сөйләшә-сөйләшә, вакыты җитеп, ишек ачылганын көтә торган чират түгел бу. Монда, гомумән, сөйләшмиләр дип беләм. Һәркем үз хәсрәтенә чумган: башкаларга сорау да яудырасы, үзенең дә җавап бирәсе килми. Өч ел эчендә күрше әбиемнең сүз алышкан кешеләре бик аз булды. Бармак белән генә санарлык. «Бер хатын: «Киленем әнисен үтерде, аңа ашарга китердем», – диде», – дип кайтып сөйләгәне истә. Кышкы суыкта ирле-хатынлы берәүләр аны машинада утырып торырга чакырдылар, термостан кайнар чәй салып бирделәр. Монысы да шул вакыт эчендә бер генә тапкыр булды. Күпләр машина белән килә, сигез тулганчы шунда утырып тора. Ә әби кебекләр – урамда: карда да, буранда да, яңгырда да, җилдә дә... Карчык кешене генә сыендырырга буладыр да бит... Әмма үпкәләп тә, гаеп тә итеп булмый: башкаларны кызганырга, кемнеңдер хәленә керергә көчләре дә, теләкләре дә калмаган бугай инде ул чираттагыларның.)

Улына тапшырган әйберләр исемлегенең бер нөсхәсе, гадәттә, әбидә калып бара. Шактый җыелды инде алар. 12.700 кг., 16.044 кг., 13.860 кг., 14.240 кг., 21.435 кг... Кечкенә генә буйлы әби бу кадәр йөкне ничекләр күтәреп, тартып бара ала, кайчакта шаккатам.

Анда барасы көнне ул төнге икедә инде аяк өстендә була. Өчтә өйдән чыгып китә – «передача» тапшырырга чиратың җитсен дисәң, иртәнге дүрттән дә калмыйча, СИЗО ишек төбендә булырга кирәк. Кемдер машина белән озатып куймаса, такси чакыртмыйча чарасы юк.

...Карауга аңладым – елаган, күзләре кызарып, шешенеп беткән әбинең.

– Ни булды? – дим, ашыгып.

– ...И-и, нәнәм... *(Әби миңа гел шулай дәшә.)*

Баласы суга төшәр, анасы утка төшәр...

Кичә аның «передача» тапшырасы көне иде. Таксига акчасын кызгангандыр инде – өйдән автобуслар йөри башлагач кына кузгалган. Өлгермәгән, билгеле: чират аңа килеп җиткәч кенә, «передача» кабул итүне туктатканнар. СИЗОдан ерак түгел генә бер таныш хатыны яши аның. «Передача» тапшырган көннәрдә ул кайчак аңа чәй эчәргә кергәли. Улына алып килгән ризыкларын әби кичә аңарда калдырып торырга уйлаган. Тәгәрмәчле булса да, арбаны тартып йөрү җиңел түгел бит: бүген кире алып кайт, иртәгә тагын кил... Гөнаһ шомлыгына каршы, лифт эшләмәгән – әби авыр арбасын тугызынчы катка кадәр сөйрәп менгән. Һәм кирәк бит – танышы өйдә юк булып чыккан. Әбием арбасы белән кире җәяү төшкән. (Ничекләр менеп, ничекләр төшкән – шаккатарсың!) Бүген инде чиратка иртүк барып баскан. Иң беренче тапшырам, дип, куанып торганда, сигез тулгач кына берәүләр килгәннәр дә: «Ә без очрашуга керәбез, димәк, без, беренче тапшырабыз», дигәннәр. (Анда шундый тәртип икән: якыннары белән ул көнне күрешү билгеләнүчеләр, «передача»ны чиратсыз тапшыра.) Ике көн шушы юлда йөргән, арыган-талган әбигә бу сүз соңгы тамчы булган...

– Елый башладым... Туктый гына алмыйм, нәнәм... – дип сөйләде ул. – Инде теге чиратсыз керергә теләүчеләр дә берсүзсез мине уздырды. Барысы да юата. Ә мин елыйм да елыйм... Үкси-үкси... Нигә шулай елаганмындыр, аңламыйм... Үземне үзем җәлләвем булдымы икән соң? Өйгә кайтып җиткәч кенә тынычландым. Юл буе күземнән яшь коелды. Автобустагылар, нигә елый бу карчык, дигәннәрдер инде...

...Кассада акча түләүче апаның: «Бу чәйләрне төрмәгә алып барам», – дип әйтүе мине генә түгел, бу сүзләрне ишеткән һәркемне сискәндереп җибәрде шикелле... «Алла сакласын!» Супермаркетта чиратта бик озак та тора алам, чиратның әнә шундыена гына басарга язмасын...

Фото: Ксения Богданова

PRESSA.RU



Индонезия – бар яктан уникаль. 5 мең чакрымга сузылган әлеге ил үзендә 17 меңнән артык утрауны берләштерә. Биредә йөздән артык телдә сөйләшүче 250 миллионнан артык кеше яши. Урнашкан урыны да географик яктан кызыклы: ул Азия белән Австралияне тоташтыра, шул ук вакытта Һинд һәм Тын океаннарны аера.



ЯНГЫНЛЫ БИЛБАУ ИЛЕНДӘ

Айназ КАМАЛ

(Бэкпекер язмалары)





Кем ул бэкпекер? Башка туристлардан ул нәрсә белән аерыла? Бэкпекер (инглиз теленнән backpacking, backpack – «рюкзак») – күп акча түкмичә, сәяхәт маршрутын үзе төзеп, кыйммәт булмаган отель-хостелларда туктап, мөстәкыйль сәяхәт итүче. Соңгы 10 ел эчендә бэкпэкерлар саны артканнан-арта бара, интернетта үз социаль челтәрләре бар, алар анда аралашалар, бер-берсенә булышалар.

Казан дәүләт университетының көнчыгыш телләре факультетында укыган елларда миңа Төркия, Мисыр һәм Иранда стажировка үтәргә туры килде. Ул вакытта минем өчен барысы да: билет, маршрут, тору урыны, ашау-эчү, экскурсия оештыручылар тарафыннан хәл ителгән иде, кем әйтмешли, «әзергә бәзер» генә йөреп кайттым. Ә менә үткән елны сабакташым Мәдинә белән Таиланд, Камбоджа, Вьетнам, Лаос илләренә барырга уйлагач, беренче тапкыр маршрутны үзебез төзедек, билет, яшәү якларын да үзебез хәл иттек.

Быел исә Индонезияне сайладык. Башта интернетта Индонезиягә барган туристлар белән аралашып, фотолар карап, башкаларның маршрутларын өйрәндек. Туризмга багышланган сайтлар белән танышканнан соң, үзебез өчен иң кулай булган маршрут төзедек.

Индонезия башка илләргә охшамаган, үзенә бертөрле, контрастларга бай мәмләкәт. Монда барысы да бар: бетон биналарга күмелгән, шау-шуы көне-төне тынмый торган мегаполислар, шул ук вакытта кеше кулы тимәгән, адәм аягы басмаган утраулар; берәүгә дә охшамаган, башка милләт вәкилләреннән нык аерылучы, буыннан-буынга күчеп килгән гореф-гадәтләрне саклаучы Суматра, Ява, Яңа Гвинея утраулары кабиләләре; кеше үтә алмаслык тропик урманнар; менә-менә кабынам дип янаучы янартаулар; табигатьтә бик сирәк очраучы кош-корт, җәнлекләрне үз иткән табигый милли парклар, Һинд, Тын океан ярлары буенда урнашкан Голливуд йолдызлары мәнфәгатьләрен кайгыртучы биш йолдызлы отельләр... Индонезия башкаласы Джакартада без озакка тукталмадык. Отельдә бер көн кундык та, Джокьякарта шәһәренә юл тоттык, Прамбанан һәм Боробудур гыйбадәтханәләренә ашыктык. Прамбанан гыйбадәтханәсе вулкан ташыннан ясалган, бу комплекс Будда тормышын күрсәтүче рәсемнәр белән бизәлгән. Монда атнага ике тапкыр «Рамаяна» дип исемләнгән театраль тамаша –принц Рама һәм прицесса Шинта маҗаралары куела. Туристлар Прамбананда кояш батуын карасалар, Боробудур гыйбадәтханәсендә таң атуын каршы алалар. Боробудур буддизм динендә төп символ булып саналган мандала формасында төзелгән. Монда 1500 гә якын барельеф белән беррәттән, 500 Будда сыны урнаштырылган.

Бу, чыннан да, безгә таныш булмаган башка ил. Үз күзләрең белән күргәч, бу яшәешне аңлап була, ләкин кабул итүе авыр...

Бромо янартавында кояш чыгышын күзәтер өчен йокыдан төнге икедә үк тордык. Сәгать 5 ләр тирәсендә минивэн безне вулкан янына китереп тә җиткезде. Өч йөзләп турист җыелганбыздыр. Кемдә нәрсә бар: айфон, гади телефон, фотоаппарат, видеокамераларын чыгарып һәммәсе фотога төшерә башлады. Әйтерсең лә, Англия королевасын каршы алабыз! Дөресен әйтим, кояш чыгышына әллә ни исем китмәде. Янымдагы туристларның шулкадәр шатлануына сәерсенеп: «Безнең Шырдан авылындагы кояш чыгышын күрсәтәсе иде сезгә», – дип уйлап куйдым. Кояшны каршы алгач, вулкан кратерына мендек. Кратер кайнап торган ашны хәтерләтә. Монда инде минем хис-кичерешләр көчле иде: үз күзләрем белән чын янартауны күрдем бит!

Төшке ашны ашаганнан соң, янә юлга кузгалдык. Мәдинәгә: «Азияне күрәсең килсә, автобуска утырып Кава Иджен янартавына барырга кирәк икән», – дим. И-и, мондагы хәерчелек, ярлылык... Сөйләп бетерә торган түгел.

Автор фотолары

PRESSA.RU



■ Эшчеләр кратерга төшеп кәрзиннәргә 50–80 килограмм каткан күкерт тутыралар һәм көянтә белән 4 чакрым ераклыктагы тиешле урынга ташыйлар.

■ Укучылар бердәм формада йөри икән. Класс бүлмәләрендә бер артык әйбер юк, шыксыз.



Янартау итәгенә кичке 8 ләр тирәсенә килеп җиттек һәм шундагы отельләрнең берсенә урнаштык. Төнге сәгать 3 ләрдә янартауның үзенә юл тоттык. Башта машинада бардык, аннары җәяү. Тирә-юнь дөм караңгы, сукмакны телефон утлары гына яктырта. Беренче ярты сәгатьтә әле ярыйсы гына атладык, ә аннан инде биеккә күтәрелү авырлаша башлады, суларга авыр, сулыш кысыла... Ләкин бу әле, урыслар әйтмешли, «только цветочки» икән. Әлеге янартаудан күкерт алалар. Күкертнең үзенчәлекле сасы исе борынга бәрелә. Безгә машина мәйданчыгында ук маскалар өләшкәннәр иде, ләкин күкертнең сасы исе шулкадәр көчле – мин хәтта бу янартауга менгәнемә үкенеп тә куйдым. Авызда әллә нинди тәм, күзләр яшьләнә. Ә эшчеләр борыннарын, авызларын чүпрәк белән чорнап, бу кратерда көннәр буе эшлиләр. Ничекләр түзәләр?

Туристлар бирегә сёрфинг серләренә өйрәнергә килә. Юкка гына Кутаны «сёрфинг мәккәсе» дип йөртмиләр.

Янартаулар безне нык арытты, тизрәк кояшта ятасы, диңгездә йөзәсе килде, кыскасы, без Ловинога юл тоттык. Сезон булмагач, яр буенда ял итүчеләр бик аз, бөтен пляжга нибары 20 кеше җыеладыр. Без әле кояш күрергә өлгермәгән, тәнебез дә ак – шуңадыр барысы да бик тиз безгә игътибар иттеләр. Массаж, дельфинарийга экскурсия, снорклинг, энҗеле бизәнү әйберләре... Һәркем безгә нәрсәдер тәкъдим итә. Җирле халык Россиядән булуыбызга бик үк ышанып та җитмәде шикелле. Аралашучан булуыбыз, инглиз телен яхшы белүебез гаҗәпләндерде аларны. Россия туристлары бик сөйләшергә яратмый, инглиз телен дә ипи-тозлык кына белә, диләр.

Кояшта кызынып, диңгездә йөзеп арыгач, Индонезиядә бик популяр булган Убуд шәһәрчегенә киттек. Убуд – Индонезиянең мәдәният үзәге. Монда тукталуыбызның сәбәбе берничә – дөге террасалары; Убудтагы маймыллар урманы; рәссам Антонио Бланко (Балида аны, Сальвадор Дали белән чагыштырып, Балидан Дали дип йөртәләр) музеенда аның картиналары белән танышу; Убуд базарында төрледән-төрле кул эшләнмәләре, көмеш бизәнү әйберләре алу; дөге террасаларында урнашкан вегетарианнар кафеларында Бали каһвәсен эчеп (монда каһвәнең дөньядагы иң кыйммәтле саналган, килограммы 250–1200 доллар торучы «Копи-лувак» төрен татып карарга мөмкин. Күсе агуына охшаган каһвә орлыклары мусанг дип аталучы җәнлек ашказанында эшкәртелә), ял итү. Монда ашыгу-кабалану юк, бар нәрсә салмак кына, тыныч кына бара.

Маймыллар урманында да йөрдек. Безнең урманнардан нык аерыла ул – лианалар да лианалар. Маймыллар шулар буйлап хәрәкәтләнә. Бик җитезләр! Халыктан курыкмыйлар, авызыңны ачып йөрсәң, берәр нәрсәңне чәлдереп китәргә дә күп сорамыйлар: чак кына сумкамнан колак какмадым. Бирегә туганнарга, дус-ишләргә сувенирлар, батик яулыклар сатып алдык.

Убуд шәһәрчегендә озак тоткарланмадык, субтропик яңгырлар башланды да, тизрәк Гили утрауларына ашыктык. Тик монда да безне көчле яңгырлар каршы алды. Берничә көн кояш кыздырган арада, ташбакалар, балыклар белән су астында йөздек. Гили утравына туристлар җирнең төрле почмакларыннан фәкать диңгез ташбакасын үзенең табигый мохитендә күрү өчен генә дә килә. Мин дә күрдем! Шундый зу-у-ур алар! Тик монда булган бер вакыйга безнең кәефне әзрәк бозды. Мәдинәнең ласты сынары югалды. Аның өчен Мәдинәдән 35 доллар түләттеләр (ә яңасы 50 доллар тора). Безнең өчен күп акча булды ул. Нишләтәсең, чыгасы акча чыга инде...

Мәктәпләренә дә кереп чыктык. Кызлар көрән төсле озын итәк, әфлисун төсендәге блузкадан, башларында яулык юк (кайбер утраулардагы мәктәпләрдә яулык та бәйлиләр), малайларның күлмәкләре шулай ук әфлисун төсендә, шортыла-



■ Йортлар ярым җимерек хәлдә, җирле халык ничек булдыра, шулай көн күрә, кырда хатын-кызлар дөге утырта, скутерларына (скутер өчен бензин пластик шешәләрдә сатыла!) нәрсә генә төямәгәннәр: читлектәге тавыклар, йорт кирәк-яраклары, бамбук агачлары, капчыклап дөге... Яңгырдан пальма ботаклары белән томала790налар. Юл буйларында киптерелгән кош-корт, елан сатучылар тезелгән.



ры – көрән. Мәктәпкә кереп чыккан туристлардан «чәйлек» кебегрәк ихтыяри-мәҗбүри акча да сорадылар. Без дә бирдек, махсус журналлары бар, шунда язып куйдылар.

Алдан планлаштырганча, безне Флорес һәм Комода утраулары көтә иде, ләкин яңгырлар яву сәбәпле, диңгез тыныч түгел, диделәр – утрауларга юллар ябылды. Яңа Гвинея утравында яңа гына җир тетрәвен ишеткәч, анысына үзебез бармаска булдык: «Ходай саклаганны сакларм190ын» дигән. Димәк, киләсе тукталыш – Кута.

Бали утравының көньягында урнашкан курорт шәһәрчеге ул Кута. Аның пляжы яшьләр арасында бик популяр. Кайчандыр балыкчылар авылы булган бу урынга 60 нчы елларда хиппилар җыела башлый. Отельләр кыйммәт түгел, барлар, арзан бәяле кафелар – адым саен. Дискотекалар оештырыла, сёрфинг яратучылар өчен менә дигән шартлар тудырылган. Монда сёрфинг өчен бар нәрсә дә бар: киемнәр, махсус скутерлар, кайчан нинди дулкын, аның биеклеге күпме булуын күрсәтүче расписаниеләр... Сувенирлары да сёрфинг белән бәйле. Безгә Кута бик ошады, өстән-өстән булса да, рәхәтләнеп «сёрфинговать» иттек, Кутадан ерак булмаган храмнарны карадык, күбәләкләр паркында булдык...

Убудка туристлар тынычлык эзләп, йога дәресләре алырга киләләр.

Индонезиягә сәяхәтебез тәмам. Бер ай сизелми дә узды. Әле һаман шул тәэсирләр белән яшибез, анда күргәннәрнең бик азы сөйләнде бит монда. Ә сөйләми калганнары никадәр?! 750 нче елларда төзелгән гыйбадәтханәләргә аяк бастык, гади халык белән аралашып, аз булса да телләрен өйрәндек, субтропик яңгыр астында калдык, Һинд, Тын океаннарда йөздек, Индонезия кырларында дөге утырттык...

БЕЛМӘСӘҢ – БЕЛ.







■ **Индонезиягә туристлар менә нәрсәләр эзләп киләләр:** Кракатау, Ринджани, Бромо, Кава Иджен янартаулары кратерларына менеп, аларның кайнавын ишетер өчен; Гили, Комода утрауларында – снорклинг, дайвинг, Кута пляжында сёрфинг белән шөгыльләнү өчен; Комода утравында динозаврлар калдыкларын – вараннарны күрергә; орангутанглар белән бергә иртәнге аш ашарга; Боробудур, Прамбанан, Танах Лотта уникаль тарихи һәйкәлләрен карарга; этнография белән кызыксынучылар – Яңа Гвинея утравында тропик урманнарда яшәүче папуас халкы, Суматра утравында христиан-каннибал кабиләләре (кеше ашаучылар) көнкүреше белән якыннан танышырга; диңгез, океан ярлары буенда кызынырга яратучылар Кута, Бали, Гили утраулары пляжларында ятарга.

■ **Уңай яклар:** ашау, яшәү ягы арзан; табигый күптөрлелек (янартаулар, тропик урманнар, бай су асты дөньясы).

■ **Тискәре күренешләр:** транспорт ягы көйләнмәгән (җирле халык белән туристлар өчен билет бәяләре бик нык аерыла, алар теләсә ничек куела); ашау ярлы: яшелчәләр яки мумия хәленә китерелгән тавык ите белән дөге, соклар; Индонезияне еш кына «янгынлы билбау бәйләгән» диләр, монда җир тетрәүләр, янартау кабынулар еш була.

■ **Индонезиягә бару өчен иң кулай вакыт:** тропик ил булгач, монда ике сезон хөкем сөрә: коры һәм яңгырлы. Коры сезон – май аеннан октябрьгә кадәр, август – туристлар иң күп йөри торган ай; яңгырлы сезон – кыш көне, бу вакытта монда субтропик яңгырлар ява, туристлар аз. Индонезиядә җирле халык булышучан, аралашырга, чит ил кешеләре белән фотога төшәргә ярата; күбесе инглиз телендә сөйләшә, аңлый. Туристларга хөрмәт белән «босс», «мистер», «мой френд» дип эндәшәләр. Ләкин барыбер дөньяңны онытып йөрергә ярамый: алар туристлардан акча эшләп калырга, ыгы-зыгы ясарга яраталар.

PRESSA.RU

16+

ХАТЫН-КЫЗ БЕЗДӘН ЯКЛАУ ЭЗЛИ...



Рафаэль ШӘВӘЛИЕВ,
Республика балалар клиник шифаханәсенең баш табибы;
өйләнгән;
гаилә стажы – 20 ел;
дүрт бала атасы: кызлары – Сәйдә (КФУ студенты), Әдилә (10 нчы сыйныф укучысы), Дәлия (2 яшь), улы Самир (7 яшь).

**Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.**

1 Иң элек хатын-кызның Сез нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Ул әле һәрвакыт матур гына түгел, мөлаем, акыллы да булырга тиеш. Әдәпле дә... Тыйнак та... Юк, кайсы ягы белән җәлеп иткәнен аерым алып әйтә алмыйм.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Мин – балалар табибы. Бәлки хатын-кызларга мөнәсәбәтем шуның белән дә бәйледер. Аларга, беренче чиратта, тормышны дәвам итүчеләр, дөньяга бала тудыручылар итеп карыйм. Хатын-кыз бик көчле зат ул. Хәтта, беренче карашка, йомшак кына күренгән әниләр дә. Әйтик, «Операцияне балага хәзер ясыйбызмы, әллә көтәбезме?» – дигән сорау туса, ир-ат: «Әнисе нәрсә әйтер?» – дияргә мөмкин. «Әтисе ничек дисә, шулай булыр», – диючеләр бик сирәк. Шуңа күрәдер, хатын-кызларны һәрвакыт гафу итәргә була дип саныйм. Һәрхәлдә, гафу итә алмаслык нидер кылган хатын-кыз очраганы юк юлымда. Ә хыянәт... Тормыш кино түгел, чынбарлыкта барысы да күпкә катлаулырак. Хатын-кыз бу адымга бара икән, аны моңа нәрсәдер этәрә. Бу көнгә килеп җиткәнче, гадәттә, бик күп вакыйгалар була. Яратканда һәм яратылганда башкалар турында уйламый ул. Шулай булгач, аның бу адымын нигә хыянәт дип атарга? Мин шулай дип уйлыйм.

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Бу сорауга җавап бирдем инде. Әйткәнемчә, гафу итмәс бернәрсә дә юк! Иң мөһиме: гаиләдә агрессия булырга тиеш түгел. Ә сүзгә килү, фикерләр төрле булу һәр гаиләдә булгалыйдыр. Боларның барысын да вакытында уртага салып сөйләшергә кирәк. Күп кеше әйтмичә, эчендә саклап йөри. Бергә булырга дип хәл иткәнсең икән инде, аңлаша белергә дә өйрәнергә кирәк.

4 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Була ала! Булырга тиеш тә. Мәхәббәт янына дуслык хисләре дә килеп кушылмаса, мөнәсәбәтләр үсүдән туктый. Һәр гаилә үсәргә, алга таба барырга тиеш – моның исә чиге юк. Бер пар да: «Безнең мөнәсәбәтләр иң камил ноктага җитте: балалар таптык, үстердек, кеше иттек, ә хәзер үзебез өчен яшибез», – дияргә тиеш түгел. Кызганыч, тормышта андый гаиләләр дә очрый шул... Әмма үзең өчен генә яшәргә ярамый бит. Дөрес түгел бу! Кемгәдер җылы биреп яшәргә кирәк. Һәм ул җылыны һәрвакыт үзең башкалардан алырга теләгәннән күбрәк бирергә кирәк.

5 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Без Зөһрә белән урамда таныштык. 1 апрель иде ул. Без укыганда ул көнне яшьләр Камал театры янына җыела иде. Бер институтта белем алганыбызны, Зөһрәнең Казан кызы икәнен белдем... Ә җәен Актаныш шифаханәсендә стажировка үткәндә, аны кабат очраттым. Ул да Актанышка практика узарга кайткан. Әтисе Актанышныкы икән, әбисе монда яши, Зөһрәнең мәктәптә укыганда бөтен җәйләре бездә узган! Аның монда туганнары минекеннән дә күбрәк! Шуннан без аерылмадык инде.

Ничек тәкъдим ясаганны хәтерлим дисәм дә, махсус көнен сайлап, «минеке бул», дип әйтмәдем. Танышуга бергә буласыбызны белә идек инде, әти-әниләрнең хәерфатихасын гына алу кирәк иде. Аларның рөхсәтен алгач, бер елдан соң, 6 нчы курсны тәмамлагач, өйләнештек.

Актаныште туйларны бөтен гореф-гадәтләрен саклап үткәрергә тырышалар. Туйдан соң икенче көнне яшь киленгә су юлы күрсәттек. Безнең туйга дип, әтинең дуслары Изгеләр чишмәсен махсус яңарттылар. Бу эшләрне башлап йөргән Инсаф абый хәзер дә ул чишмәне карап тора.

6 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый...

– Гомерлек парың кем буласы күкләрдә язылып куелган, Аллаһы Тәгалә әллә кайчан хәл иткән була бугай инде. Безгә бары «очраклы рәвештә» очрашасы гына кала...

7 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Элегрәк, эшкуарлык тормышыбызга болай киң итеп кермәгәндә, шәхеснең үсеше өчен ниндидер чикләүләр булганда, тәртип, әйе, шулай иде: ир-ат малны күбрәк табарга тиеш дип саналды. Ә хәзер вазгыять күпкә үзгәрде. Хатын-кыз акчаны шактый күбрәк эшләгән гаиләләр дә байтак. Әмма шул ук вакытта ир-ат анда түбәнсетелми, кимсетелми. Безнең үзебезнең дуслар арасында да бар андый парлар. Башкалардан берни белән дә аерылып тормыйлар. Бәхетле гаиләләр хәзер матди байлыкны беренче урынга куймый, рухи кыйммәтләр аларда югарырак санала. Алар бер-берсен шуның өчен хөрмәт итә. Бер-береңә юл куярга өйрәнү, һәр мәсьәләдә дә ике якны да канәгатьләндерерлек чишелеш таба белү, үз-үзеңне үстерү, рухи яктан баю, партнерыңны шаккаттыра белү – болар акчага бәйле түгел.

Дөрес, ир-атның бу җаваплылыкны аңлы рәвештә үз өстенә алмавын мин хупламыйм. Хәзер бит ир-атлар арасында гаиләнең иминлеге, муллыгы никадәр мөһим икәнен аңламаучылар, аңларга теләмәүчеләр дә шактый. Әйе, ир-ат табучы булырга тиеш, әмма, әйткәнемчә, бу – хатын-кыз акча эшләмәскә тиеш дигән сүз түгел. Бигрәк тә аның уңышка ирешү мөмкинлекләре зуррак булса. Ә гомумән алганда, ир-атлар позицияләрен югалтып баралар хәзер. Күп өлкәдә! Бигрәк тә – гаиләдә. Балалар тәрбияләүдә катнашмыйлар. Нәтиҗәдә, балада: «Әти бернәрсәне дә хәл итми», дигән фикер формалаша. Әнә шифаханәбезнең теләсә кайсы бүлегенә, теләсә кайсы палатасына кереп, балалары белән ятучы әниләр белән сөйләшә аласыз: шактый ирләр, бала авырый башлау белән, гаиләдән качкан. Бигрәк тә диагноз җитди булганда. Мин аларның бу адымын акларлык бер сәбәп тә тапмыйм.

8 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Әйбәт карыйм. Без танышканда да беренче булып минем янга булачак хатыным үзе килде... Ак атка атланган принц килә дә мине кияүгә чакыра дип көтеп утыру әкият бит ул. Бернәрсә дә эшләмичә көтеп утырып кына торсаң, тормышыңда берни дә үзгәрмәс. Бәхет өчен көрәшергә кирәк! Аңа таба беренче адымны үзең ясау гаеп була алмый.

9 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Рухи һәм физик көч. Табигатьтән шулай килә – хатын-кыз ир-атта яклау эзли, ә ир-ат моны тәэмин итәргә тиеш.

10 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Чираттагы мифларның берсе бу. Дуслар, танышлар арасында бик чибәр парлар бар. Куркып, бер-берсенә якын килә алмый торсалар, бу гаиләләр барлыкка килмәс иде. Аннан, бу логика буенча, безнең барлык гүзәл затларыбыз да ялгыз калырга тиеш булып чыга. Алай түгел бит. Әгәр хатын-кыз кияүгә чыкмаган икән, анда сәбәп бөтенләй башкада.

11 Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар.

– Хатын-кыз йөрәге белән уйлый. Логика таләп ителгән җирләрдә дә алар йөрәк белән эш итәчәк. Эчке сиземләү аларда бик көчле һәм хатын-кызлар аны тыңлый белә. Шуңа да, безнең белән чагыштырганда, күп вакыт алар үзләрен ышанычлырак тота. Ә ир-ат үз йөрәген сирәк тыңлый – икеләнүләр дә аңарда күбрәк.

12 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.

– Яшьрәк чакта бу сорауга башкача җавап бирер идем, мөгаен... Гомер бик кыска, безгә бирелгән вакыт бик аз. Хәтта әйткәләшергә дә вакыт юк! Аннан, ниндидер бер кечкенә, юк кына нәрсә өчен хаклы булуыңны исбатларга омтылу – бу бит гомернең кыска бер аралыгында була торган хәл. (Озын дистанциядә без, әлбәттә, берберебезне аңлыйбыз!) Һәм әлеге кыска дистанцияләрнең озынлыгы кешенең үзеннән тора. Беркем дә аерылышуга барып җитәм дип башламый бәхәсне. Әмма, кызганыч, кайберәүләр бу дистанцияне тоймый кала... Менә шуның өчен дә бәхәсләшүнең мәгънәсен күрмим. Дәшми калуың хәерлерәк.

13 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән...

– Минем белән беркайчан мондый хәл булмаячак. Беренчедән, мин эштән бик соң кайтам. Икенчедән, юк, Зөһрә болай эшли алмый. Тәрбиядән дә тора бит бу... Безнең гаиләдә шундый тәртип: кем өйгә иртәрәк кайта, шул нидер әзерли. Олы кызлар да шулай, миңа кайтырга туры килсә – мин дә. Нәрсә әзерли беләмме? Камыр белән генә дуслыгым юк, башкасын булдырам болай... Якшәмбе кухняга, гомумән, мин хуҗа. Иртүк торам да әзерлим. Моны барысы да белә. Кибеткә, базарга барып, азык-төлекне дә үзем алып кайтам. Хәзер улым Самир да минем белән бара, аннары икәү пешерәбез дә.

Мин йокыдан иртә торам. Кемдер әйтергә мөмкин: «Хатын ирен эшкә озатып калырга тиеш», – дип. Тиеш түгел! Кайда язылган шулай дип?! Моны һәркем, һәр гаилә үзе хәл итә. Әйе, өйдә диктатура да урнаштырырга мөмкин. Андый диктатор хатыннар да бар. Иренә: «Эшең 5 тә бетә, син 6 да өйдә булырга тиеш», – дип таләп куючы. Мондый хатыннарның ирләре беркайчан да тормышта уңышка ирешә алмаячак. Зөһрәдән ялгыш та андый сүз ишеткәнем юк.

14 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...

– Хатыным 10 минутка соңара. Һәрвакыт! Аның белән кая гына барырга җыенсак та! Башта, яшьрәк чакта, көрәшеп карадым, билгеле, хәзер – юк: өйдән чыгып китәсе вакытка теге 10 минутны өстәп кенә әйтәм.

15 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә...

– Без бүләкләрне һәрвакыт икәү бергә алабыз. Зөһрә дә, мин дә кирәкле әйбер генә бүләк итәргә кирәк дип саныйбыз. Чәчәкләр... Әйе, аларны бүләк итәргә яратам! Бер сәбәпсез дә дия алмыйм, гадәттә, бер сәбәбе була инде аның. Кызганыч, тик бик тиз сулалар...



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз:
www.syuyumbike.ru

PRESSA.RU

УЧАКТА ПЕШКӘН ЧАХОХБИЛИ





«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Лилия ГӘРӘЕВА әзерли.

Мастер-классны Булат БӘЙРӘМОВ белән Ләйсән ГЫЙМАЕВА үткәрә. Татар тамашачысына «Татар радиосы»ның иң беренче һәм бүгенгәчә иң популяр ди-джее, шоумен, ТМТVда – «Музыкаль хит-парад» тапшыруын әзерләүче һәм алып баручы Булат Бәйрәмовны күпләр «Тәмле көрәш» тапшыруы аша да беләдер. Ә Минзәлә кызы Ләйсән Гыймаева – барыбызга да таныш җырчы, 8 мәртәбә «Алтын Барс» премиясе лауреаты. Журнал укучыларыбыз арасында аларның «Хатын+Ир» концертын тамаша кылучылар да бардыр.
Йолдызлы гаилә белән «Сөембикә» журналына мастер-класс әзерләү хакында сүз чыккач, Булат «Тәмле көрәш»тә отып алып, үзенчә үзгәрткән, камилләштергән рецептын тәкъдим итәргә булды. Гадәти генә түгел ул – кояш нурын, җәй җылысын, учак тәмен сеңдергән ризык. Әзерләп карагыз әле, тәгаен ошар ул сезгә.





Кирәк:

(4 кешелек гаилә өчен)

- 2 кг чамасындагы тавык;
- 1 кг помидор (артыграк булса да ярый);
- 1 баллы борыч (тәм өчен генә, яратмасагыз, салмаска да мөмкин);
- 1 кг суган;
- ярты лимон;
- 1 чәй кашыгы «Хмели-сунели» аш тәмләткече;
- 1 чәй кашыгы аджика (кыркурак яратучылар күбрәк тә сала ала);
- берәр тотам рәйхан, кинза, петрушка (кинзаның тәме көчле, саграк булыгыз);
- 6 тырнак сарымсак;
- тәменчә тоз;
- үсемлек мае.

Эш барышы:

■ Тавыкны зур булмаган кисәкләргә турыйбыз (бик вак та булмасын).

■ Казан төбенә үсемлек мае салып, эрерәк кенә итеп туралган суганны алтынсу төскә керә башлаганчы кыздырабыз. Булат белән Ләйсән чахохбилины учакка асылган казанда пешерә. Андый мөмкинлек булмаса, газ өстендә чуенда да пешерергә була. Ул очракта итне ваграк итеп турасаң яхшы.

■ Суган өстенә ит салабыз һәм болгата-болгата кыздырабыз. Капкачын ябмый торабыз. Ит ике яклап кызарырга тиеш.

■ Аннары ит өстенә туралган помидор белән туралган борычны салабыз, сарымсак өстибез. Барысын бергә болгатып, помидорның суы чыкканын көтәбез. Әгәр дә помидорлар бик сусыл булып, чыккан суы итне күмәрлек булса, башкача су салырга кирәк түгел, әгәр кимрәк икән, итне күмәрлек итеп кенә кайнаган су салабыз һәм казан өстен капкач белән томалап торабыз. Учакны да бераз сүрәнләтергә кирәк. Йомшарганчы талгын гына пешсен ул шулай.

■ Казанга аджика белән «Хмели-сунели» тәмләткечен салабыз, аннары тәменчә тоз сибәбез. Учактан алырга 5-10 минут чамасы калгач, туралган яшел үләннәрне кушабыз, ярты лимонның сутын сыгабыз.

■ Әзер чахохбилины зур тәлинкәгә түшәлгән салат яфраклары өстенә өеп, табынга бирәбез, янына ярып кына пешерелгән бәрәңге тезеп чыгарга була. Ә инде шулпасын, һәркем итне үз тәлинкәсенә бүлеп алганнан соң, ит өстеннән сибәләр. Ашларыгыз тәмле, җәйләрегез ямьле булсын!



PRESSA.RU

Укучыларыбызга узган мастер-класслар буенча инде таныш Наилә МЕДВЕДЕВАның интернет сәхифәсендә бу күлмәкне күрдек тә, аһ иттек. Салават күпере төсләреннән, күз явын алырдай итеп, нәкъ менә җәй өчен бәйләнгән ул. Бераз гына тырышканда, аны һәркем бәйли ала. Теләсәгез, Наилә үзе дә бәйләп бирергә әзер.
Без бәйләгән күлмәк 2 яшьлек кыз балага тәгаенләнгән.
Буе – 98 см;
күкрәк әйләнәсе – 54 см;
күлмәкнең озынлыгы – 48–50 см.





ТӘТИЕМӘ – ТӘТИ КҮЛМӘК


Кирәк:

• бәйләм җебе – 50 г / 240 м;
• коралл төслесе – 3 йомгак;
• сары, ачык яшел, ачык зәңгәр төслеләре – берәр йомгак (төсләрнең үзегезгә ошаганын сайлый аласыз);
• ыргаклар: № 1,75 һәм № 2;
• 3 данә вак сәйлән (күлмәк төсенә ярашлы булсын, диаметры 6-7 мм).


Эш барышы:

■ Күлмәк өстән бәйләнә башлый. Гәүдә өлешен һәм воланнарны бәйләү өчен ыргакның 1,75 санлысын алабыз. Бәйләм – реглан принципы белән башкарыла. Күзләр саны дүрткә бүленергә тиеш. Әмма алгы якка тагын бер күз өстәлә. Безнең очракта: 136 күз + 1 = 137. 137 күздән чылбыр үреп, кокетка схемасы буенча күлмәкне бәйли башлыйбыз. Чылбыр үргән рәт ноленче булып санала, ул исәпкә керми. Беренче рәткә күчү өчен башта 3 буш күзле багана үреп, 17 күзне чалулы багана белән бәйлибез. 17 нче багананың төбеннән тагын бер багана бәйләп алып, ике буш күз өстибез. Шул рәвешле, реглан җиң өчен почмак формалаша. Арткы яктан, киеп-салырга уңайлылык өчен, төймә ерымы калдырыла. Бәйләм әлегә уңнан-сулга, сулдан-уңга бәйләнә.


■ Схема буенча бәйләмдәге күзләр санын арттыра барып, 13 рәт бәйлибез һәм бәйләмне боҗрага тоташтырабыз. Кокетканы баланың үзенә кидереп карарга кирәк. Күкрәге таррак булса, җиң төбеннән 4-5 күз өстисе булыр. Хәзер инде бәйләмне әйләнә буенча бәйлибез, күзләр санын башкача арттырмыйбыз. Якынча 17 рәт бәйләнә.



кокетка схемасы



күбәләк схемасы



волан схемасы




муен уемы



буш күзәнәк

чалулы багана

бергә тоташтырылган чалулы ике багана



чалусыз багана

пико (өч буш күзне беренче күзәнәккә чалусыз багана белән тоташтыру)

■ 18 нче рәттән сары төсне кушып, волан схемасы белән беренче воланны бәйлибез. Игътибар: һәр төс арткы якның уртасыннан кушыла башлый. Воланның һәрберсен 8 рәт итеп бәйлисе.

■ Беренче воланны төгәллләгәч, аның астына сары төстән сетка бәйләнә. Бу юлы инде 2 нче санлы ыргакка күчәбез (сетка бушрак булсын өчен). Ул да, коралл төсеннән бәйләнгән гәүдә өлешенең иң соңгы рәтенә ялгап, шулай ук 8 рәт бәйләнә.

■ Сетканың соңгы рәтен чыккач, аңа яшел төстән икенче волан ялганып китә. Аның астына яшел төстән шулай ук 8 рәт сетка бәйлисе.

■ Яшел сеткага зәңгәр төсле волан ялгана, аннан зәңгәр төстән сетка үрелә.

■ Иң соңгы волан – коралл төсеннән. Әмма аның астына инде сетка бәйлисе юк, ул итәк очына тотылган челтәр кебек торачак.

■ Арткы яктагы уемның уң ягына чалусыз багана белән 3 рәт бәйлибез, бу – планканың төймә тага торган ягы. Сул яктагысында төймә тишемнәре калдырыла. Аның беренче рәте чалусыз багана белән бәйләнә.

■ Икенче рәт: 5 күзне чалусыз багана белән бәйләп, 3 буш күз үрәбез, аннары 3 күзне «сикертеп», кабат 5 чалусыз багана, 3 буш күз бәйләнә. Шулай – рәтне чыкканчы кабатлыйбыз. Өченче рәт чалусыз баганалар белән бәйләнә.

■ Муен һәм җиң уемнарын бер генә рәт итеп, «муен уемы» схемасы буенча бәйләп чыгабыз. Сәдәфләрне тагабыз.

■ Күлмәкне бизәү өчен сары һәм зәңгәр төсле җептән күбәләк тә бәйлик әле, куансын кызчыгыбыз.

■ Сары төстәге җептән 6 күзле чылбыр үреп, боҗрага тоташтырабыз, аннары бәйләмне схема буенча дәвам итәбез. Икенче рәт тә сары төс белән бәйләнә.

■ 3 нче рәттә зәңгәр төскә күчәбез. Соңгы 4 нче рәт чалусыз баганалар белән сары төстән бәйләнә. Нәтиҗәдә, 8 таҗлы чәчәк барлыкка килә (иләмсезрәк күренер, борчылмагыз, үтүкләгәч, урынына ята ул). Юеш тукыма аша үтүкләп, урталай бөклибез.

■ Зәңгәр төстән күбәләкнең уртасын бәйлибез. Моның өчен башта 12 күздән чылбыр үреп (монысы гәүдәсе өчен), аннары, тагын өстәп, 8 күз җыябыз – монысы мыегы өчен. Шушы сигез күзне чалусыз багана белән кирегә таба бәйләп килеп, шул урыннан икенче мыек өчен янәдән 8 күзле чылбыр үрәбез. Анысын да чалусыз багана белән бәйлибез. Гәүдә өлеше дә 1 рәт чалусыз баганалар белән бәйләп чыгыла. Аннары аны юеш тукыма аша үтүкләп, күбәләкнең канатлары уртасына җөе күренмәслек итеп кенә тегеп куябыз. Күбәләкнең үзен дә аскы канатының читләреннән күренми торган җөй белән тегеп, күлмәккә беркетәбез.

PRESSA.RU



Июнь – бакчада чүп үләннәргә һәм корткычларга каршы көрәшә торган ай. Суган һәм кишер чебене, кәбестә күбәләге, кырмыскасы дисеңме... Болар бер көн дә ял итми, көн дә төн дә «эштә». Агулы химикатларсыз алардан котылырмын да димә. Әмма... нәкъ менә агуларсыз үстергән яшелчә дип казынабыз түгелме соң инде бакчада?

БАКЧАЧЫ АПТЕКАСЫ

Корткычларга каршы химиясез дә көрәшергә була. Аптекада сатылучы нашатырьны гына алыйк. Аның бакчада алыштыргысыз ярдәмче булуын белә идегез микән?

Беренчедән, ул өйдәге кырмыскаларны бик яхшы куркыта. 100 мл нашатырь спиртын 1 литр суда сыеклап, идәннәрне, тәрәзә төпләрен, җиһазларны сөртсәгез, тегеләр бик тиз «табан ялтыратачак».

Икенчедән, ул бакчадагы вак бөҗәкләр – гөбләләрдән (тля) булыша. 2 аш кашыгы нашатырь спиртын 1 чиләк суда сыеклап, шуңа 1 аш кашыгы сыек сабын салып болгаталар да, үсемлекләр өстенә бөркиләр.

Өченчедән, суган һәм кишер чебене дә аның исен яратмый. Моның өчен 1 аш кашыгы нашатырь спиртын 1 чиләк суга салып, рәт араларына сибеп чыгалар, җир кипшергәч, туфракны йомшарталар.

Күпләр, яшелчәгә аю чикерткә – медведка зыян сала, дип зарлана. Аннан котылу өчен, 1 чиләк суда 10 мл нашатырь спиртын сыеклап, һәр үсемлек төбенә 0,5 литр сибеп чыгалар. Аю чикерткә нашатырь исен яратмый. Гомумән, аю чикерткә генә түгел, чебен-черки дә өнәми аның исен. Бакчада эшләгәндә алар һөҗүменнән саклану өчен, тән тиресенә тигез күләмдә су белән сыеклаган нашатырь спиртын сөртеп карагыз. Черкиләр тешләгәннән соң тәннең кычытканын да баса ул.

Нашатырь саклык чарасы гына түгел – үсемлекләр өчен ашлама да. Аеруча аны кыяр, яран, лилия, клематислар ярата. 10 литр суга 8 аш кашыгы нашатырь спирты салып болгаталар да, куакка 1 литр исәбеннән сибәләр. Шушы ук ысул бүлмә гөлләре өчен дә яхшы. Әле, өстәвенә, гөл балчыгында яши торган вак чебеннән дә котылырсыз.

Яисә менә барыбызга да яхшы таныш йодны алыйк. Ул ашлама да, чирләргә каршы тору чарасы да.

Көннәр салкын һәм дымлы торса, кыярда ончыл чык авыруы барлыкка килә башлый. Әле авыру башланганын көтмичә, 3 литр суга 1 тамчы йод тамызып, үсемлекләрнең өстеннән бөркеп чыксагыз, чирне кузгатучы гөмбәләр юк булачак. Шушы ук сыеклыкны помидорларны фитофторадан саклау өчен дә кулланалар. Бу чиргә каршы тору өчен тагын бер чара: 1 чиләк суга 1 литр сыек сөт һәм 10 тамчы йод салып, шушы сыеклык белән үсемлекләрне коендырырга. Ә инде фитофтора «әләктереп алса», 1 чиләк сыек сөткә кушылган 40 тамчы йод ярдәмгә килә.

Бакча җиләге дә йод белән сыйлаганны бик ярата. Чәчәк аткан чорында 1 чиләк суга 10 тамчы йод тамызып, өстеннән бөркеп чыгалар.

Роза, яран, глоксиния, миләүшәләр шулай ук йод белән ашлаганга бик сизгер. Туфрагына йод керткәннән соң, аларның чәчәкләре эре була, төсләре җетеләнә. Чәчәкләргә сибү өчен, 2 литр суда сыекланган 2-3 тамчы йод җитә.

Бор кислотасын да игътибарсыз калдырмыйк. Үсемлекләргә ул да кирәк. Туфракта бор җитешмәсә, бакча җиләгенең яфраклары бөгәрләнеп килә, читеннән корый башлый. Бор кислотасы җиләкләрнең төмен дә яхшырта: 1 чиләк суга 1 г бор кислотасы белән 1 г калийлы марганец (марганцовка) алына. Бу 30-40 төп җиләккә җитә. Игътибар: бор салкын суда бик начар эри, башта аз гына күләмдә алынган кайнар суда эретергә кирәк.

Борның җитешмәве помидорларда да нык сизелә. Аларның үсү ноктасы, каралып, кибә. Тамырыннан бик күп янтармаклар чыгара башлый, яфраклары тиз сынучан була, помидорларның өске ягында көрән кутыр барлыкка килә. Авырый башлаган томатларны бор эремәсе белән тукландыралар (1 чиләк суга 10 г бор кислотасы). Болай ашлаганнан соң, помидорлар тагын да тәмләнеп, балланып китә.


Кучкар. Тормышыгызны гына түгел, дөньяга карашыгызны да үзгәртердәй вакыйгалар көтелә. Барысын да тиз хәл итәргә күнеккән Кучкарлар бик күпкә өлгерәчәк. Айның беренче яртысында хәлиткеч карарлар кабул итү, яңа эшләр башлау өчен яхшы вакыт.


Үгезбозау. Искиткеч яхшы ай. Язмыш сезне дусты дип кенә түгел, якын туганы итеп күрә, диярсең. Нәрсә уйласагыз, шул булыр, ни теләсәгез, шуңа ирешерсез. Эшләгән эшләрегез белән рухи дөньягыз арасында – тулы гармония.


Бизмән. Уңышлы ай. Нәрсәнедер үзгәртәсе иде, дип йөрүчеләр, ниһаять, теләкләренә ирешер. Нindидер бер эшкә тотынырга куркып торган булсагыз, хәзер менә нәкъ вакыты – иң авыр эшләрне дә җиңел генә хәл итү мөмкин.


Кысла. Йолдызлар борчуларсыз рәхәт ай вәгъдә итә. Эшегез күп булса да, алар сезгә рухи ләззәт бирәчәк. Әмма бу көчегезне файдасыз гамәлләргә сарыф итәргә дигән сүз түгел, гәрчә алар бик ымсындырса да.


Арыслан. Бернигә дә карамый, ял итеп алыгыз. Бер дә ял итү мөмкинлеге юк икән, кешеләр белән мөмкин кадәр азрак аралашырга тырышыгыз – көчкуәтегезнең кимеп киткән мәле. Планеталар торышы низагка этәрә торган. Сүзләрне уйлап сөйләгез.


Сөмбелә. Тормышыгызда үзгәрешләр булыр. Бу – яңа мавыгу, яңа эш тә булырга мөмкин. Яңалыклардан курыкмагыз, алар сезгә файда гына китерер. Начар энергиядән арыныр өчен бик кулай вакыт.


Бизмән. Актив тормыш рәвеше, вакыйгаларның тиз-тиз чиратлашуы көтелә. Ай башында кабул ителгән карар ел азагына кадәр тормышыгызны билгеләячәк. Зур әйберләр сатып алу өчен яхшы чор.


Чаян. Нәрсәгә сәләтле булуыгызны күрсәтәсе килү теләге уяныр. Тирә-юньдәгеләрнең үзегезгә карата ихтирамы артуын тоярсыз. Теләк-ниятләрнең чынга аша торган чагы, аз гына тырышлык күрсәтсәгез, күптәнге хыялыгызга ирешерсез.


Укчы. Ыгы-зыгылы ай. Гел каядыр ашыгу, нәрсәдер эшләү, кем беләндер очрашу – гомумән, иркенләп кенә йөрү җае күренми. Борчылмагыз, бу тырышлыклар бушка түгел, тиздән әҗере дә насыйп булыр.


Кәҗәмөгез. Очрашулар, танышулар, кызыклы вакыйгалар көтелә. Күңелегез яңа тәэсирләр тансыклар. Белүегезчә, кем эзли, шул таба. Гомумән, ай уңышлы булыр, эшегезнең нәтиҗәсен күрерсез.


Сукояр. Тиз һәм җитезлек сорала торган ай. Вакыйгалар бер-бер артлы алышынып торып, карарларны тиз кабул итәргә туры килер. Хаталанудан курыкмагыз, бу айда күңел сизгерлеге искиткеч яхшы, ул сезгә дөрес юнәлешне сиздерер.


Балык. Бик көчле энергия дулкыны көтелә. Илһам кабына торган уңышлы ай. Теләк теләр, хыялларны чын итәр өчен моннан да яхшырак вакыт тагын кайчан булыр икән? Моның өчен күңелегезне богаулап торган уйлардан гына арынырга кирәк.

ИЮНЬ *дә кабынган йолдызлар*

Татарстан



Нурдия Җүрәева (2.06.1937) – **Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык артисты.**

Казанда туа. 1964 елда Казан консерваториясен тәмамлый. Казан музыка училищесында укыта. 1981 елда аны Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрына баш хормейстер итеп чакыралар. Бер елдан соң Татарстанның мәдәният министры урынбасары итеп куялар. 1985 елның ноябреннән башлап, тоташ егерме ел ул кабат опера театрында – баш хормейстер вазыйфасында, аның җитәкчелегендәге хор театрда куелган барлык операларда гына катнашып калмый, аерым концертлар да куя. 2006 елдан Нурдия ханым театрның баш хормейстер вазыйфасыннан китсә дә, театрга тугры булып кала, хормейстер булып эшли. Театрдагы эше белән бергә, педагогик эшчәнлек белән дә шөгыльләнә – Казан дәүләт консерваториясендә укыта.

Россия



Наталья Варлей (22.06.1947) – **Россиянең атказанган артисты.**

Румыниянең Констанца шәһәрендә туса да, балачагы Мурманскида уза. 4 яшеннән шигырьләр яза, музыкага өйрәнә, рәсемгә һәвәс була. 1950 елда алар Мәскәүгә күченә. 1965 елда Цирк һәм эстрада сәнгате училищесын тәмамлап, Мәскәүнең Цветной бульвардагы циркында эквилибрист буларак эшли башлый. Моңарчы беркем белмәгән кызны союз күләмендә таныткан фильм – «Кавказская пленница» (1966). Нина роленә дәгъва кылган күренекле актрисалар арасыннан Гайдайны беркатлылыгы белән җәлеп итә ул. 1971 елда Б. Щукин исемендәге театр училищесын тәмамлый, кырыклап кинокартинада уйный. 1992 елда үз сүзләренә язылган җырларыннан беренче грампластинкасын чыгара. 2010 елда «Дуслык ордены» белән бүләкләнә.

Чит илләр



Николь Кидман (20.06.1967) – **актриса.**

Американың Гавайя штатында туа. Кызга 4 яшь тулганда әти-әнисе үз ватаннарына – Австралиягә кайта. Бәләкәйдән балет белән шөгыльләнә. Австралиянең яшьләр театрында, соңрак Филипп Стрит театрында чыгышлар ясый. Экранга беренче тапкыр 15 яшендә чыга. «Рождество в лесу» фильмына ремейк була ул. Тамашачыга аны 80 нче елларның «Бандиты на велосипедах», «Ночь танцующих теней», «Оседлавший ветер» фильмнары таныта. Дөньякүләм танылу исә «Бангкок Хилтон» һәм «Мертвый штиль» фильмнарыннан соң килә. 2003 елда «Часы» фильмындагы роле өчен «Оскар» премиясенә лаек була.

PRESSA.RU





АЛМАЛЫ ИҖАТ

Алланып пешкән зур-зур алмалар, алмалар... Һәм каядыр артта, икенче планда, башка яссылыкта – башка дөньяда яулыгын артка чөеп бәйләгән хатын-кыз сыны. Алма җыючы хатын-кыз... Мин генә күрәмме аны, әллә башкалар да күрә микән? Киндер тукымага төсле буяулар белән төшерелгән картина – мизгелне төп-төгәл чагылдырган фотосурәт кенә түгел шул. Монда рәссамның үз кичерешләре – алмалы балачакны сагынуы да өстәлгән.

Рәссам Гөлназ ӘДҺӘМОВАның иҗади эшләре беренче карашка бик хыялый, хәтта әкияти кебек. Әмма шунысы кызык – аларның һәрберсенең гап-гади тарихы бар. «Беренче чәчәкләр»дәге умарталык та, әнә, уйлап чыгарылган түгел. Вазага куелган чәчәкләр – күңел түренә салынган бер якты хатирә: әтиләре җәй хәбәре итеп ел саен урманнан беренче чәчкәләрне җыеп алып кайта торган булган. Шушы ике истәлекне бергә кушкач, нинди сихри күренеш килеп чыккан. Умарталык еракта, әйтерсең лә, томан артында. Ә чәчәк бәйләме яп-якында – анысын үрелеп алырга да булыр сыман. Шушы үзенчәлек – ике яссылыкта эшләү – рәссамның күп картиналарында чагылыш тапкан.

Икенче үзенчәлек – Чаллы кызы булса да, Гөлназ иҗатында авыл тематикасы күп.

– Минем рәссам булып китүем дә табигатькә якынлыктан, – дип сөйли Гөлназ. – Җәйне гел авылда үткәрә идек без. Ә бабабыз (исеме дә гадәти түгел – Заман бабай!), ышанасызмы, айга карап, һава торышын фаразлый белә иде. Менә шундый – табигать белән бербөтен булып яшәүче кешеләр...


Гөлназ Әдһәмова 2005 елда Татарстан һәм Россия рәссамнар берлегенә кабул ителә. 2011 елда Чаллыда «Ел рәссамы» булып танылa. Аның эшләре Төркиядә узган Чаллы рәссамнары күргәзмәсендә дә урын ала. Бүген үзенчәлекле иҗаты белән ул Россиякүләм, Халыкара күргәзмәләрдә даими катнашып килә. Педагог буларак, шәһәрдәге рәсем сәнгате белән бәйле уку йортларында булачак рәссамнарга белем бирә.

Гөлназ Әдһәмова – реалист-рәссам. Яраткан эш алымы – күзе күргәнне тукымага төшерү, ягъни натурадан язу. Хәер, күзе күргәнне генә дисәк, дөрес тә булмас. Күңеле тойганны, башкалар күрмәгәнне дә, ягъни мәсәлән. Рәссамнар телендә бу «сурәткә стиль бирү» дип атала икән. Чынбарлыкны аз гына үзгәртеп, мөһим санаган элементларны күпертебрәк бирү, дип аңларга кирәктер инде моны.

Гөлназның иҗат эшләре арасында кәгазьгә ясалган график хезмәтләр дә күп. Кайберсе үзенчәлекле алым белән – юеш кәгазьгә ясалганнар. Кәгазь кибеп беткәнче (бу күп булса ике сәгать эчендә), рәсем ясалып бетәргә тиеш! Мондый хезмәтләр үзенчә матур! Рәссамның һөнәри осталыгын, ягъни башкалардан өстенлеген хезмәттәшләре төсләрне сайлый, алар белән «уйный» белүдә дә күрәләр икән.

Гомумән, иҗат кешесе һәрвакыт эзләнүдә, һәрвакыт үзгәрүдә. Гөлназның быел октябрь аена планлаштырылган чираттагы шәхси күргәзмәсенә декоратив бизәк-орнаментлар белән бәйле хезмәтләре тупланачак. Бу аның иҗатында яңа этап. Һәм монысы, һичшиксез, тагын да кызыклырак!

Ризидә ГАСЫЙМОВА








ГӨЛНАЗ ӘДҺӘМОВА

PRESSA.RU


Языл һәм телевизор от!



1 Языл
30.06.2017 кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә 3 басмасына языл ***(акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласың)***

2 Җибәр
язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәр ***(телефон номерыңны күрсәтергә онытма):*** 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 От
Телевизор, фотоаппарат һ.б. бүләкләр!







Акцияне үткәрү вакыты: 15.05.2017 - 20.09.2017

Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында
Оештыручысы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте
Белешмәләр өчен телефон: (843) 222-09-84 өстәмә номер - 1261

16+
Реклама